РЕНАТ ХАРИС

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

Избранные произведения
В семи томах

**Том 2**

*Стихи*

# РЕНАТ ХАРИС

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2006

Сайланма әсәрләр
Җиде томда
**2 том**
*Шигырьләр*

# РЕНАТ ХАРИС

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Х33

Җыентыкны төзүче, текстларны хәзерләүче, кереш сүз авторы — филология фәннәре кандидаты, ТДГПУ доценты *Фәридә Хәсәнова*

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Харисов Р.М.**

Х 33 Сайланма әсәрләр: 7 томда / Ренат Харис; Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Хәсәнова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5-298-03912-X

2 т.: Шигырьләр (1980–2000). — 2006. — 463 б.

ISBN 5-298-03914-6

ISBN 5-298-03914-6 (1 т.)
ISBN 5-298-03912-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Харисов Р.М., 2006



# Төзүчедән

Ренат Харис биографиясендә 1980–2000 елларга мәдәният министры урынбасары, «Казан утлары» журналы һәм «Татарстан хәбәрләре» газетасы редакторы, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, халык депутаты булып эшләү вакытлары керә. Шагыйрьнең егермеләп китабы да шушы елларда чыгарылган. Шуларның алтысы — рус телендә, берәрдән — башкорт һәм чуваш телләрендә һәм тагын балалар өчен өч китап, калганнары — татар телендә. Әлеге 20 еллап вакыт шагыйрь иҗатында зур әһәмияткә ия чор. Боларга өстәп тагын 21 поэманы да кушсак, бер кеше өчен гаять киң колачлы, зур күләмле иҗат килеп чыгар. Р.Харисның әлеге чор иҗаты шигырьләрендә лиризмның көчәюе, жанрлар төрлелеге, поэмаларында тарихи темаларга тартылуы белән билгеләнә.

Бу томда шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы зур урын алып тора, һәм бу табигый да, чөнки Р.Харисның андый шигырьләре сан ягыннан да, ихласлылык ягыннан да татар әдәбиятында күренекле урын били.

1981 елда шагыйрьнең фәкать мәхәббәт шигырьләреннән генә торган «Көзге мәхәббәт» исемле шигырь җыентыгы чыга. Анда лирик герой: «Мин яшьлеккә кабат кайттым, тормыш нәрсә икәнлеген белгән ир булып», — дип белдерә. Әлеге шигырендә шагыйрь үткән елларына нәтиҗә ясый: лирик герой, гәрчә хыянәт газабы белән очрашса да, мәхәббәт назларын да татыган, тормышында шатлык-хәсрәтләре дә булган, — тик хәзер ул аларның барысын да онытырга тели. Лирик геройга таныш юлны тагын бер кабат үтәргә мөмкинлек туган: аңа көзге шашкын мәхәббәт килгән. Шагыйрь бу «көзге мәхәббәт»не илаһи ташкын дип атап, яңа хиснең кешене яңача янып туңарга, яңача көнләшергә, иске сүзләр белән булса да, яңача сөйләшергә мәҗбүр итә торган хис итеп сурәтли. Шулай да кеше үзенең үткәнен тулысынча сызып ташлый алмый. Шигырьдәге төп фикер әсәрнең исемендә һәм соңгы юлларда чагылыш таба: барысы да яңа кебек, тик үкенечләр генә элекке.

Шагыйрь үзе дә никтер иҗатындагы бу чорны киртәләп алган кебек. «Күзле җәйме, җәйле күзме мин кичә торган бу чик?» — дип сорап куя ул. Көзге ел фасылы лирик геройның табигатенә туры килә. Шуңа да ул: «Көз булып дөньяга чыгам», — дип раслый, үзен көз исе сеңгән яфрак итеп хис итә, бер үк вакытта күңеленең тыныч түгел икәнлеген белдерә.

Р.Харисның мәхәббәт шигырьләре нигезендә эшләнгән «Шашкын мәхәббәт» дигән телевизион фильм ун елдан артык уңыш белән, елына берничәшәр тапкыр, зәңгәр экраннарны бизәде.

Р.Харис иҗатындагы «Үз-үземне озак эзләдем мин» исемле шигырь лирик геройның тормышта үз юлын табарга тырышып, эшчәнлекнең төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп каравын тасвирлый. Лирик «мин» бәхетен, печән чабып, балта тотып, капка ясап, — авылдан да эзләп карый; аннан соң кулына пумала ала, кара тактаны, мәктәпне дә үз итә, спортта да көчен сынап карый — һаман үзен таба алмый. Тик ни тотса да ихлас эшләвенә дә карамастан, илаһи ләззәт таймый. Һәм көннәрдән бер көнне Аны очрата — шул көннән башлап теләкләре тормышка аша: олы хис тулы лирик шигырьләр яза башлый. Шулай итеп, иҗат эшен мәхәббәт нәтиҗәсе итеп бәяли. Лирик геройның хәзер үз-үзенә ышанычы нык, шигырьләрендә матурлык көчле.

Кыскасы, Р.Харис шигырьләре укучыдан билгеле бер актив рухи халәткә көйләнгән булуны таләп итә. Мостай Кәрим билгеләп үткәнчә, «шагыйрь үз сукмагын салды, үз «Баскычлар»ына баса-баса югары үрләде һәм татар әдәбиятында «Ренат Харис шигърияте» дигән үзенчәлекле күренеш барлыкка килде».

*Фәридә Хәсәнова*

Шигырьләр

1980–2000

## Әлегә хушлашмыйбыз...

Яшьлек белән әлегә хушлашмыйбыз.
Булдыра алса — үзе хушлашыр.
Тик яз гына үтте,
Алда — җәй, көз,
Ерак әле бездән кыш башы.

Чәчтек кенә әле,
Үстермәдек,
Кизәндек кенә,
Әле сукмадык...
Зур олаулар сыйдырырлык юлга
Әйләнмәде гомер сукмагы.

Дуамаллыкның әле кыюлыкка
Әверелүен шактый көтәсе...
(Кыюлыкның шәплеген белсәк тә,
Дуамаллыктан килми китәсе...)

Кичәге көн белән хушлашкандай,
Җиңел генә итеп хушлашып
Китәр идек,
Ләкин алдыбызда
Без белмәгән озын юл башы...

## Алтын төрән

Җир сөрәм...
Гасырлар катламнарына үтеп керәм...
Туфракта Киек Каз Юлының тузанын күрәм...

Җирнең бәгърен кояш нуры белән кавыштырам,
ерак тарих серен бүгенгегә таба авыштырам,
ашлык тамырын космик токым белән таныштырам.

Континенттан континентка дуслык буразнасы сызам,
халыклар каһарманлык кылган юллар аша узам,
акыл һәм хис арасына Җир әйләнә сукмак сузам.

Мин чәчүгә кыр әзерлим,
тынычлыкка җыр әзерлим,
Җиргә тыныч чор әзерлим!

Миндә — Киек Каз Юлының ак төсе,
даһи маңгаеның яктысы,
бәхет учагының чаткысы.

Миндә — Җирнең иң мәрхәмәтле аңы!
Ышанычлы — мәхәббәтнең миңа таянган таңы!
Миндә — кешелекнең газиз җаны!

Мин җир сөрәм —
кеше язмышын буразнага һәм кояшка кушып үрәм.
Мин — мәңге тутыкмас алтын төрән!

## *Даһи хис*

Уңдырышлы планета мин үземә күрә,
миңа тигән һәрбер нәрсә шытым бирә:

көн нурыннан — терелеге тән-бәдәннең,
Ай нурыннан — бөек хисем-мәхәббәтем.

Йолдыз нуры тудыра хыял, серле өмет...
Мин бит орлык көткән язгы туфрак кебек.

Беравыктан бөтен нурлар кинәт сүнә...
Миңа космик караңгылык шулчак сеңә.

Һәм барлыкка килә иң чын даһи хисем —
«Мин аң чиксезлеген тойган бөек җисем!»

* * *

Һәрбер кеше — Җир-тәгәрмәчнең бер теше,
күк тәгәрмәче тешенә тигән төше!

Кайчак мин дә башым белән йолдыз этәм,
хәтта кара бушлыкларга тиеп үтәм.

Җир-тәгәрмәч алга таба минсез күчми —
Галәм механикасында олы көч мин!

Уем тулы тере йолдызлар ялкыны...
Ә йөрәктә фанилыгымның салкыны...

Ул эреми... Эремәсен... Кирәкми дә...
Җир хакына һәрбер кеше Җирдән китә:

кайберәүләр юл ташына — башы белән...
Ә кайсылар йолдызларга бәрелеп үлә.

## *Бар тырышканым*

Карга бассам, кыш булам мин,
җәй булам, чәчәк тотсам.
Чор-дәверләр тамырына
әйләнәм, юлга чыксам.

Күзем йомсам, төн булам мин,
күз ачам да — аяз көн:
җылытамын, яктыртамын
Җир өстен һәм Ай астын.

Тын алам да һава булам,
металлны очырырлык.
Тынсыз калсам — үле бушлык,
хәтта таш тончыгырлык.

Чыкка кагылсам — Идел мин,
Иделгә тисәм — диңгез.
Бер карасаң — миллиардтан бер,
бер карасаң — һич тиңсез!

Яшәүнең һәр мизгелендә
тылсымга юлыгыла —
үземнең бар тырышканым
чын Кеше булу гына...

## Renatus [1]

Инде мин дә артка борылып карыйм —
үткән юл бар,
заман өлеше.
Ә башыма Киек Каз Юлының
төште инде салкын көмеше,
сүнгән йолдызларның көле төште...
Миллион еллар элек суынган...
Терелмәсләр, дидем.
Терелделәр
хәтеремнең терек суында!
Алар белән җаным, әй, сөйләште
аңлашылмый торган бер телдә...
Кайдан миндә Йолдыз телен белү?
Әйтә алмас Җирдә беркем дә!..
Нигә миңа андый бөек ачкыч,
мәңгелекнең ачкач ишеген,
үзең кералмагач,
күрәлмагач
аң-зиһеннең ерак бишеген?
Нигә миңа андый бөек көймә —
дәверләрне урап кайтырлык —
үлемсезлек диңгезенә кертеп
үтергәчтен мине батырып?!
Ә шулай да кеше булу — бәхет!
Мин — Йолдызның җанлы күмере —
кабат кайтып яшим...
Әйләнештә
хәтеремнең чиксез гомере!

[1] Renatus — яңадан туган, дөньяга кайткан *(латин.)*.

* * *

Кайчандыр Ай
галәмнең ромашкасы булган бугай...
Таҗ яфракларын өзеп тарата-тарата,
кемнеңдер мәхәббәтен сынаган Җир
үзенә карата:
    яратмый...
        ярата...
            яратмый...
                ярата...
Ай шәрә калган диләр
    шулай...
Шулай
кемнең мәхәббәтен сынаган соң Җир,
кемнең хисен?
Кешелекнекен түгел микән?
Син ни дисең?..

* * *

Кан тамырындагы тынлык
уйдагы давыл аша
кайвакытта галәмдәге
тын тынлыкка тоташа.

Шул вакытта сеңә миңа
дивана зирәклеге...
Сызлана-сызлана аңлыйм
тын көрәш кирәклеген

Җирдәге зур чиргә каршы,
ә чир һаман үр менә —
кешенең тынлыкка булган
мәхәббәте сүрелә...

## *Хәбәр*

Йолдызлардан Җиргә бик аз якты.
Йолдызлардан якты — акылга.
Әнә берсе минем күзләремә
керер өчен төбәп атылган.
Тик әлегә безгә күренми ул,
йолдызлыклар аша үткәндә,
минем өчен мөһим хәбәр җыя —
бөек хәбәр көтәм күптәннән.
Йә «бар!» дисен,
Йә «юк!» дисен Йолдыз,
тынычлансын күңел бу хакта.
Йолдызларда кардәш эзлибез шул,
кеше булып җирдән тусак та.
Ул хәбәрдән, бәлки, безнең яшәү
үзгәрмәс тә,
калыр шулай ук...
Ә кешелек аңы,
тәне кебек,
ике аякка басып
тураер.
Күктә
хәбәр
янды...
Аңламыйча
калдым...

## *Анда, космонавтлар янында*

Аларның һәр яклары идән,
һәр яклары түшәм.
Мин һәр көн алар катына менеп төшәм.
Билгеле, яннарына кермим,
иллюминаторларыннан гына карыйм.
        Җирдә
        ике
        кеше җитми —
шуларны барлыйм.
Кояш батареяларыннан сөртәм космос тузанын,
кул уңаеннан һәрбер җөйне капшап узамын —
метеорит бәрелеп салмаганмы яра?
Борчылырсың да —
кешене сөймәс космоста
тере кораб.
Күңелемне сүрү итәм дә
корабны төрәм.
Тынычланам.
Әверелеп Галәм иренә
кайтам ыгы-зыгы тулы Җиремә...

* * *

Күңел минем ничек тыныч булсын?
Төне буе диңгез котыра —
бернинди җил!
Күктән, ахры, Айдан
чиный-чиный ялгыз эт өрә.
Илаһилар мәллә сугышалар?
Айны мәллә Йолдыз үтерә?
Мине мәллә уятмакчы булып,
ярдәм сорап,
диңгез үкерә?..
Баткан чакта, салам да ышаныч —
илаһилар ябыша адәмгә!
Мин, күрәсең, салам гына түгел,
мин, күрәсең, кораб
Галәмдә!

## *Тырышты Җир*

Кичә
барлык дуслар җыелдык та
әй сабынладык,
әй ышкыдык,
әй юдык без Җиребезне.
Һәм чайкадык
иң кайнар хискә,
иң саф теләккә,
иң пакь өметкә салып.

Шундый удык,
шундый юдык —
түзмәде Җир,
чистарасы, пакьләнәсе килде аның,
теләгенә хәтта кан сауды.
Безгә кушылып,
безгә булышып
әй тырышты,
әй тырышты Җир,
тик бар булдыргany —
бүген иртән ап-ак кар яуды...

## *Гасыр яшьтәшләре сөйләшә*

— Күк гөмбәзе харап булган...
— Кайсы төштән?
— Рәкит тиеп киткән, диме...
— Алайса тишкән.
— Рәките безнеке, ди бит...
— Йә, кит!.. Йә, кит!..
Шул дәрәҗә башсыз булмас
безнең рәкит.
— Башсыз, ди, шул... Башсыз, ди, шул.
— Җитте, тик тор...
— Ай ахырында ябыштырган
тыранзистыр
эләккән, ди, шул рәкитнең
супласына —
күк гөмбәзен дә тишкән, ди,
үзе дә сынган.
— Сыныклары кая киткән?
— Өстә оча.
Космонавтлар чүплиләр, ди,
шуны өч ай,
төйиләр, ди, грузовикка...
— Ярый, шуннан?
— Һич кичекми озаталар металлоломга.
— Күк гөмбәзе шулай тишек кала, диме?
— Тишек, ди, шул, сизәсеңме —
һава кими.
Кичә картым чабынырга мине
кыстый —
өченчегә меналмадым,
сулу кысты...

## *Бала турындагы уйлар*

Бала турындагы уйлар йөдәтә башны...
Җирнең киләчәген күрәсе килә башлый —
балаң өлешенә тиячәген.

Шундый чакта син — тылсымчы, кыю фантаст.
Йөрәгең аша чор-гасырлар
эфир булып исә.
Син балаң гасырында.
Үз гасырыңда яшәвең, билгеле, истә...

Берсен берсе әйләндергән ике шестерня күк,
Ай кагылган Җиргә...
Һималайлар Ай кратерына кергән...
Ишелә таулар...
Сытыла шәһәрләр...
Диңгезләр ташалар шаулап...

Аһ, бала турындагы борчулы уйлар
әйләнәләр, ахры, чиргә...

Мин бүгенге —
янашулардан янартаудай кызган Җирдә!

Балам турындагы уйлар
әверелдерә мине
нык йөрәкле,
матур теләкле,
изге ниятле
көрәшче иргә!

## *Казанның кызыл түбәсе*

Йолдызларга төбәлеп,
горур тора «Сөембикә» —
Казанның кызыл түбәсе.

Кичер,
аның безенә эләгеп,
эчеңне ярдырган авыр болыт,
син үтәсе юлдан
тайпыла алмаган ул,
чүгә алмаган мескен булып.

Рәнҗемә,
аның очына юлыгып,
түшеңне тырнаткан ярсу вакыт,
калкып яшәргә дип баскач,
калмаган ул ятып.

Кичерегез,
рәнҗемәгез —
күптән төзәлде ярагыз!

Сезне ишетергә дип сузылып,
янтаеп тора
Сөембикә манарасы.

* * *

*И вечный бой! Покой нам только*
*снится*
*Сквозь кровь и пыль...*
*А.Блок.*

Һәр халыкның үткәнендә
дан яулаган кырлары бар.
Кан һәм уттан шул кырларда
сыкрап туган җырлары бар.
Йөрәкләре каберендә
алар, ләкин мәңге исән,
өсләренә йөзләгән кат
дуслык төсе — гөлләр үскән.
Күршеләр рәнҗемәсен дип,
табында җырланмый алар...
Һәр халыкның да чит кан һәм
уттан туган җырлары бар.
Җырга каршы җавап итеп
шартласа дарылы җырлар,
рәнҗерләр,
гафу итмәсләр
Туган ил дә,
кыр да,
чор да!..
Бер халык та җырсыз тормый —
җырсыз үткән гомер әрәм.
Җырлар күмәк.
Алар туган
йөрәктәге тәхетләрдән!..

## Бәхет Аем

Һәр кешенең үз маягы,
үз сукмагы,
үз җае.
Берәүнең — бәхет Йолдызы...
Ә минем —
бәхет Аем!..

Ул ярала, арта, тула,
инде күзгә чак сыя.
Бәхет тулы Ай булганда,
мин Кояштай нур коям.

Ул шунда ук кимгә китә —
күнекмәсен тулыга!..—
Бәхеткә күнеккән кеше
хәсрәткә еш юлыга.

Кими,
кими
һәм юк була...
Күгем кара нур коя...
Бәхет күренмәгәндә дә
аның барлыгын тоям...

# *Италия дәфтәре*

*(Цикл)*

## 1. Шаккаттыңмы?

— Шаккаттыңмы?
— Шаккаттым...
Ә аннары Әдрән диңгезләрен ташлап,
Бомбаларына эләкми,
Исән килеш
Чак кайттым.
Аудым дымлы кырларыма...
Җәй бездә авыр иде —
Тамырдагы бодайларны
Череткеч яңгыр иде.
Италия кояшына
Күнегеп беткән тәнем
Туган илнең салкынын да
Сеңдерде рәхәтләнеп...
Ямьле яклар җыр тудыра,
Ә миндә күпме заман
Италия җырлар булып
Туалмый газаплана.
Әллә инде сагынуларның
Сусыны түзәрлекме?
Сагыну хәтта таяктан
Җыр сыга, диләр иде,
Ә кулымда минем каләм...
Күз алдымда карлы кыр.
Кәгазь кебек...
Җыр һаман юк —
Илгә кайту шатлыгыннан,
Бәлки, айный алмыймдыр?..

## 2. Колизей күзләре

Колизей күзләре белән күзәтә мине тарих —
Күзем аша Заманамның җанына кереп карый.

Акыллылык, кешелеклек, матурлык конкурсына
Көтмәгәндә йә ялгышып эләккән мәхлук сыман
Сиздем мин үземне шулчак Колизей каршысында —
Рим чоры күзләре белән тарих карый бит сынап!
Мин Заманымнан бер вәкил, илемнән һәм халкымнан.
Җирдә нәрсәне мандым соң акылым алтынына?
Кешелегемнең җылысы нинди ташны эретте?
Аһым, җаным матурлыгын кайсы дәвер җыр итте?
Мин үземнән үзем сорыйм. Аһнан җавап эзләтәм.
Мин Җир алдында җаваплы. Мине тарих күзәтә.

### 3. Олы Канал

Олы Янау булып дулкынлана Олы Канал...
Кыршылып беткән катерлары,
Турист, кесәсенә төяп,
Акча ташый.
Тозлы мазут,
            азып,
                    мәрмәр ашый,
Көрән тапларын Венециянең
Гәүһәр йөзенә төкерә...
Олы Янау булып дулкынлана Олы Канал...
Дулкынына кунмый акчарлаклар.
Ап-ак акчарлаклардан ара-тирә
Суга сузыла
Свастика-тәре.
Шаулыйсы килә, шаулыйсы,
Олы Каналның тынлыгын ярып...
Ләкин без — кунаклар...
Безгә монда
Күңелдән генә
Шауларга ярый...
Олы Янау булып дулкынлана Олы Канал...
Кемгә яный?
Венециягә генәме?

## 4. Тынычлык сиңа

Тынычлык сиңа, Марк, евангелиячем минем.

*Венеция гербындагы язу*

Тынычлык сиңа, изге Марк!
Барлык изгелекләреңне кичерәбез.
Тагын бик күп гасыр җиргә төшмичә,
Собор кыегында исән-сау тор!

Тынычлык сиңа, шофер Антонио!
Бай абыең машинасы сиңа да бәхет китерсен.
Туристлар йөген ташый-ташый,
Бәлки, бер баеп китәрсең.

Тынычлык сиңа, тәрҗемәче Изабелла!
Совет туристларын бик күп еллар
Италия буйлап сәяхәт иттер.
Тизрәк теләгеңә иреш —
Туры килсен блондин ир,
Кыз тап, аңа Катюша дип исем бир...

Тынычлык сиңа, әкияти Венеция!
Диңгезеңнең төбе нык булсын.

Тынычлык сиңа, гүзәл Италия!
Кыяфәтеңә күз тимәсен,
Комга терәлмәсен язмышыңның
Күпне күргән көймәсе.

Тынычлык сиңа, изгеләр кебек гөнаһлы,
Безнең барыбыз кебек изге Җир!
Сиңа таянып калыккан һәрбер корылмага,
Шул исәптән изге Маркка да,
Мәңге җиргә егылып төшмичә
Исән-сау торырга ирек бир!

## 5

Мине кемдер кинәт буды...
Авызга тулды мазут...
Шаркылдап көлделәр миннән:
«Йә, шәпме яңа азык?..»
Шартлап ачылган күзләрем
Берни дә күрми. Бары
Алкалар, сырлар, сызыклар —
Күгелҗем-кызгылт, сары...
Мине әллә нишләтәләр.
Калмады уйлар көчем.
Партизан Полетаевтан[1]
Ала алмаган үчне
Миннән алалар, ахрысы,
Бүген туган фашистлар...
«Ә, шулаймы?! Бер бүренең
Ун көчеклек көче бар.
Буар газда тончыктырып
Үтермәкчемени сез?
Юк, көчекләр, сез татарның
Кем икәнен белмисез —
Атсаң да үлми, ассаң да,
Яралымы, тоткынмы?..»
Йодрыгымны гөрзи итеп,
Бер китереп суктым мин
Һәм... уянып киттем шунда.
(Беренче таң ят илдә.)
Миланда, алтынчы катта,
Зур зиннәтле отельдә.
Карасам — минем этажда,
Тәрәзәгә тәрәз куеп,
Гараж тора.
Шуның исен
Иснәгәнмен төн буе...

---

[1] Федор Полетаев — Италия азатлыгы өчен һәлак булган совет партизаны.

### 6. «Әй дусларым, дусларым!»

Җыр тавышы үлмидер ул, —
Куерадыр, йөздер...
Төер яки болыт булып,
Шәт, Җир шарын гиздер...
Әллә бүген тыным белән
Шундый болыт тоттыммы? —
Күкрәгемдә таныш бер җыр
Яңгырарга тотынды:
«Әй дусларым, дусларым ла,
Дусларым, дус-ишләрем...»
Искә төште Италия...
Тозлы зәңгәр кичләре...
«Унита» бәйрәмендә ул
Һәр кешегә хуш килде.
Киң күңелле җыр дип, аңа
Итальяннар кушылды.
Безнең җырлар хөрмәтенә
Корылдылар табыннар...
Башка телдә яңгырап, ул
Ялтырап китте тагын да.
Дуслар безгә тостлар әйтте...
Без дә әйттек тостларны:
«Катюша»,
«Бандьера росса»,
«Әй дусларым, дусларым!»

### 7. SOS!

Космостан да күренерлек итеп,
Күкрәгенә Италия плакат аскан.
Плакатта — SOS!
Беренче хәреф булып бөгелеп ята
Венециянең Олы Каналы.
Икенче хәреф булып түгәрәкләнеп каткан
Мәшһүр Колизей калдыклары.

Өченче хәреф —
Альда Мороны* урлап качкан
Бормалы юл.

Ә якыннан
Италия көлә,
Италия гөрли,
Кояш автострадасы буйлап
Каядыр чаба...

## 8. Дуслык турында

...Урындык ватылгалады —
төзәттек тә утырдык.
Өй ишелгән чаклар булды —
сипләдек, янә тордык.
Юллар өзелеп калганда,
күпер салып үтәсең...
Ә менә Дуслык өзелсә,
бетәсең!

---

* Альдо Моро — Италия премьер-министры.

* * *

Агачларда еллар сыры
күзгә күренә кискәч кенә.
Сагышы да йөзгә чыга
яшел сарыга күчкәч кенә.
Күз яшен дә яшерми ул —
өз дә кара бер бөресен...
Табут йә тәре ясасаң,
үпкәләгәнен күрерсең.
Утка салсаң, нәфрәтеннән
чатный-чатный янар, көяр...
Ә серләрен
исән килеш
бары тик
шагыйрьгә сөйләр.

* * *

Кабат
каләмемә үсә яңа канат.

Нинди кошка әверелер ул, нинди кошка?
Куркып кыштан,
җылы яклар эзли торган булыр булса,
йә салкынга күнегеп бетеп
яз барлыгын онытса,
тавышы гел чырай сытса,
канаты, сизми ялгышып,
халык ярасына сукса,
ат та төшер каләмемне,
тот та сындыр!

Каләмдә җаным булса да —
үзем сорыйм!

## *Юл читендәге үлән*

Тау түбәсендәге үлән
йолдызларга сүз дәшәдер.
Елга ярындагы үлән
диңгез белән сөйләшәдер.
Имән төбендәге үлән
беләдер карурман телен...
Мин тауларда,
урманнарда,
ярларда
яшәргә телим,
чөнки мин — гасырлар салган
юллар читендәге үлән —
кешеләр маңгаендагы
сырлар серен генә беләм...

## *Коктебель*

Кара Дагтан ап-ак болыт
диңгезгә шуышып төште,
шулпага тоз төшкән кебек —
ап-ак күбек диңгез өсте...

Без, адәмнәр, болгатабыз
диңгез суын, шашып-шашып...
Берәү әнә чуен булган...
Мин әлегә көмеш кашык...

Мин дә тиздән бакыр булып
болгатырмын балык ашын...
Минем баш та хәтерләтер
ялтырап беткән кашык башын.

Кояш ялый... Ашы тәмле,
тозы таман — сизеп торам...
Ә мәшәкать диңгезенең
суы бик күпкә тозлырак.

# *Җен бармагы*

Җир йөзендә мондый бармак
бармы тагын?! —
Кара Дагны тишеп чыккан
җен бармагы.

Бу таш бармак җеннең, шәт,
баш бармагыдыр,
бармакның: «Шәп яшисез!» — дип
тормагыдыр.

Яшибез шул! Әллә вакыт
җитмәгәнме?
Газапларны без җитәрлек
чикмәгәнме?!

Хакыбыз бар! Яулап алдык
бәрелешләрдә,
юлыбызга сала-сала
фәрештәләр.

Шәп яшибез! Бәһаң дөрес —
баш бармагың!
Моңардан да төгәл бәһа
бармы тагын?!

## *Алтын капка*

Тирә ягы чиксез диңгез,
юк коймасы —
су эченә кыя-капка
кем куйган соң?

Кыя зурлык шаяруның
мәгънәсе ни?
Кем яңа Хуҗа Насретдин —
беркем белми.

Үзем йөздем ары-бире
аның аша,
һич күрмәдем гаҗәпләнерлек
тамаша.

Бары тик шул: капка аша
чыккан саен,
чиксез ирек хисе тоям —
күңел байый!

# *Шторм*

1

Дулкыннар китереп бәрә дә
тау-кыяларны ега.
Ватылган чакта ташлардан
суда да чаткы чыга.

2

Диңгез кайнап тора шаулап,
пары җиткән болытка.
Болыт шаккаткан — диңгездән
йотыласын оныткан.

3

Маңгайга-маңгай килгәннәр
күк явы, диңгез явы...
Халыкларга, ахры, шуннан
күчә болгану шавы.

4

Диңгезгә сыймый дулкыннар —
Җирдә, Күктә су тора...
Кем соң мин? Шушы давылны
күкрәгемә сыйдырам.

## *Давылдан соң*

Давылдан соң чыккан кояш
көндәгедән кадерлерәк.
Аны күргәч кан җылына,
ышаныбрак тибә йөрәк.

Миндә мең һөҗүм чигереп
исән калган батыр хисе —
тоям, тоям, тоям, тоям
кояш нурының хуш исен!

Чоңгылда калган өметләр
кояшның ак нурларына
ябышып өскә калкалар
һәм чыгалар җырларыма.

Алар көчле, алар якты,
аларны кем танымасын —
давылдан соң кояш булып
чыккан яшәү тантанасын!

* * *

Дулкынга арканны бирмә,
дулкынга күкрәк терә —
ир-егетнең йөрәгенә
менә шулай көч кирә.

Арттан килеп капласа, ул
тончыктыра, батыра.
Улым, безгә иртә диңгез
төпләрендә ятырга.

Дулкынны авызлыкларга
тырышма — булма әрәм:
аларны җил генә түгел,
аларны Җир күтәрә.

Без тормыш дулкыннарында
икәү хәзер, янәшә...
Дулкыннарга каршы дулкын
җибәрә белү — яшәү!

* * *

Акчарлаклар, мине күргәч,
нәкъ кешечә кычкыралар.
Әллә инде азык җитми,
әллә инде көч сорыйлар?!

Минем күңел кечелекле.
Барысы да ярдәм көтә —
җанлыны да,
җансызны да
туганым дип игълан иткәч!..

Кемгә балык,
кемгә бодай,
кемгә акча,
кемгә бакча...
«Тагын!» — дип кычкырган идем,
тавышым чыкты акчарлакча.

* * *

Кораблар диңгезгә китә,
хыялларны өстерәп.
Ә хыялдан калышырга
әллә нинди көч кирәк.

Ярда ялгыз басып калдым...
Офыкта соңгы кораб...
Чынбарлыктан югалып, ул
әкияткә кереп бара.

* * *

Кояш баеганда җил туа...
Җил дулкыннар кубара.
Дулкын,
явыз язмыш булып,
ярны ялмарга бара.
Ә ярда синең белән мин,
          халык,
                    дәүләт,
                              киләчәк...
Киткән кояшның дулкыны
безнең өскә менәчәк,
          болгатачак,
                    кузгатачак,
                              үз эзенә салачак...
Ярый —
          йөрәк,
                    нигез,
                              иман
үзгәрмичә калачак!

## *Юл да юл*

Алдымда юл да юл...
Көн аша, төн аша...
Кичәсе елгалар күзләрдән башлана,
үтәсе урманда һәр агач — бер түрә,
коп-коры күңелләр дәвамы ут-чүлләр,
чөелгән борындай мин-минлек таулары,
түгелгән гайбәттән җыелган баткаклык,
кесәдән ясаган капкалар, ишекләр...

Эшемне, намусны, идеалны,
атамнар, бабамнар үткәнен,
баламны, дусларны, өемне
күтәреп үтәсе юл ята!
Аһ, ничек үтәсе?!
Эстафета көткән буынга
бер көнгә иртәрәк җитәсе?..

## *Йөрәк белән капшап*

Аяк белән көпшәк карны капшап,
Йөрәк белән капшап тормышымны,
Тотрыклы юл эзлим —
Батасы килми сулы карга,
Каласы килми суыкларда!..
Адым саен
Хыялдагы якын җәйнең,
Җылы җәйнең,
Тыныч җәйнең
Бәһасе арта.
Дуамал күңел дулап тарта —
Ә мин,
Аяк белән көпшәк карны капшап,
Йөрәк белән капшап бу тормышны,
Тотрыклы юл эзлим...
Һәр яз,
Менә-менә рәхәт җәйгә чыгасың дип,
Сак булырга өйрәтә безне...

## *Болыт күләгәсе*

Болыт күләгәсен күреп,
«Харап — черек тап!..» — диеп,
Җирне тиргәүче, сүгүче,
каргаучы да табылыр.
Күләгәдә кала калсак,
без дә кимен куймабыз:
«Гавам белә — кушылыйк», — дип,
телебезне тыймабыз.
Җил исәр дә болыт тузар!
Күләгәләр вакытлы.
Шулчак ничек сипләрбез соң
намустагы ватыкны?

## Тәмуг сүнгәч

Тәмуг
сүнде
миндә...
Янгын утта янасылар
таралдылар җәннәт сахралары арасына...

Тагы да баебрак китте кебек миндә җәннәт...
Шаять, бетте, дидем янучыларны яшәү җәлләп.

Тәхет мендердем, дип, тагын зур бер дәреслекне,
күкрәгемә сугып, горурлыкны дер селкеттем.

Таптый-таптый сулар сиптем тәмуг учагына...
Баксам —
җылы җитми
сүзләремә,
кочагыма...

* * *

Әйбәт кеше иртә китә...
Әллә «әйбәт» калкансызмы?
Һәр кайгының утлы угы
аңа кагылмыйча узмый.
«Әйбәт»нең җаны тырнала,
тамчы-тамчы көя каны...
Әйбәт кеше иртә китә —
әллә әйбәт булмаскамы?
Яшәргәме калкан тотып,
көбә киеп бер кальгада,
якты чырай күрсәтмичә
ни олыга, ни балага,
бер дәрәҗә юлны ачып
һәм дөрескә, һәм ялага —
кагылмый гына үтсеннәр,
кертмичә генә бәлагә?
Бәлки, озаер да гомер...
Ә булырмы соң мазасы —
ак тәнеңдә ал кан булып,
шул каның һич сызланмаса?..

# *Моң*

— Нәрсә ул моң?
— Ул — җете көз: купшы урман,
Шәрә кыр,
Болытлар томанлы тавыш
Белән җырлый торган җыр.
Кавышу куанычының
Аерылу ачысына
Кушылуыннан килеп чыккан
Гаҗәеп халәт сыман
Бер халәттер.
Аны хәтта
Булмый төгәл билгеләп...
Йә, аңлатып кара шуны —
Күңел елый, күз көлә...
Нәрсә ул моң?
Ул — кочакта
Елаган сылу ярдыр...
Ә бәлки, моннан башка да
Моңның мең яме бардыр...

* * *

Ничаклы кош!
Ничаклы кош безнең җырларыбызда!
Йөрәкне ачып,
күңелнең эчкәрегесен күрсәтергә
ярдәм иткән ничаклы кош!..

Ничаклы кош,
Ничаклы кош тавыш бүләк иткән
скрипкага, курай, кубызга!

Ташларына чәчәк куйыйм дисәң —
кошларның кабер ташлары
безнең җырларыбызда...

* * *

— Иртән кем елый?
— Яслегә барасы килмәүче сабыйдыр.
— Көндез кем елый?
— Эше уңмаган, вәгъдәсе уалган кешедер.
— Кичен кем елый?
— Ялгызлык караңгылыгыннан куркучыдыр.
— Төнлә кем елый?
— Мәхәббәтен югалткан бер бәхетсездер.
— Таңда кем елый?
— Гөнаһы исенә төшкән бер бәхетледер...

## Хата!

Дулкын тынмый —
дулкын туңмый,
дулкын катмый,
суыкка ядрә ата,
бозларны бәреп вата.
Эшеннән канәгатьләнә,
ачуы бераз кайта,
әкрен генә тынычлана,
ял итәргә дип ята...
Һәм
ката!

* * *

Якты аңга да килә кара уй.
Аңа үзең үк тозак корып куй.
    Ә тозакны
    өскә асма —
    кара уйның
    башы аста!

## Дәвам

Үбә-үбә озатып калды улын ялгыз ана.
Аркасыннан сөеп сыйпады җыерчыклы кулы белән —
Иреннәре дәвамы булды аның кулы.
Кулы җитмәгәч,
Күз карашы белән сыйпады ул аркасыннан —
Күзе кулының дәвамы булды.
Күздән югалгач,
Хыялында үпте, сыйпады, иркәләде ана улын —
Бар нәрсәнең дә дәвамы — хыял...

## *Көлкегә калса*

Күз көлкегә калса,
кешегә оят төс алдында.

Борын көлкегә калса,
кешегә оят ис алдында.

Колак көлкегә калса,
кешегә оят җыр алдында.

Кул көлкегә калса,
кешегә оят җир алдында.

Аяк көлкегә калса,
кешегә оят юл алдында.

Баш көлкегә калса,
кешегә оят ил алдында.

## *Ага*

Сулар ага...
Сулар ага...
Сулар сыек, шуңа ага.
«Гомер ага!» — дип әйтәбез,
ага
утка яга-яга...

Гомер ага.
Аны бетон сайгак итеп,
йә бер корыч кадак итеп
җиргә кага алмаучының
үзен бөтереп алып ага.
Сыеклыклар гына ага...

* * *

Ah!..
Хушлашырга иртә әле, иртә...
Әти, әни!
Сез бит минем белән үлем арасында
иң нык калкан,
иң биек киртә.
Мин тылда —
рухым тыныч.
Бераз гына чирләсәгез дә,
миңа куркыныч —
беркөнне көтмәгәндә
алгы сызыкка чыгармын күк...
Кызым, улым!
Сезнең хакка
күп давылны егармын күк...
Чыдармын күк...

* * *

Оясыннан егылып төшкән кош баласы белән
Шаяра адәм баласы.
Мәхлук кошның каурыйлары сынып беткән.

Оясыннан егылып төшкән адәм баласы белән
Шаяра язмыш.
Ул мәхлукның канатлары нишләр микән?

## *Ау чоры*

Яфракка сары керде...
Мылтыкка дары керде...
Җитте хушлашу чоры.
Агач — яфрак озатты.
Егылып төште киек үрдәк —
Аучы аңа төз атты.
Үле яфраклар өстендә
Канга буялган киек —
Үлгән фиргавен янында
Япь-яшь хатыны кебек...

* * *

Көз керә.
Кыз-кыркынга төс керә.
Йөзләренә — көн төсе,
Күзләренә — төн төсе.
Сүзләренә тәм иңә,
Кызыктыргыч ямь иңә.

Көз керә.
Егетләргә көч керә.
Тәннәренә — ир көче,
Аңнарына — җир көче.
Уяу килеш төш күрә,
туйга охшаш эш күрә.

Көз керә.
Һәм шагыйрьгә шатлыгын
Иленә җиткерерлек
Төгәл, тыгыз сүз керә.

Көз керә...

## *Ашыгып бәхеткә ашкынганда*

Сулы шешәдә
бәсле тәрәз төбендә
бөре төртә тал ботагы...
Тамыры юк...
Юк туфрагы...

Ашыгып бәхеткә ашкынганда
кирәкмидер, бәлки, туган туфрак,
ныклы тамыр?..

Башка ботаклар әнә тышта —
салкын кышта.
Ул — җылыда.
Бары
яфрагын гына бер айга иртәрәк ярыр...

## *Тыныч көзләр*

Инде күптән
кырларда ыгы-зыгы беткән.
Күренми инде күзне сискәндерерлек
җете гөлләр,
урман шәрә —
азындырмый күңелләрне,
кызыктырмый инде салкын күлләр.

Кайнарлана кочаклар...
Кайнарлана иреннәр...
Ягымлылана төшә сүзләр...

Ниһаять, җитте
кешене кешегә генә бүләк итә торган
тыныч көзлар!

## Август

Инде август.
Тагын август.
Җәй җиткән ахыр чиккә.
Инде тагын кояш нуры
яфракка тамып кипкән.
Инде тагын күзгә тула
купшы, көр, шат чуарлык,
ә күңелдә төссез уйлар —
тик теш кысып чыдарлык.
Дөньяда да, күңелдә дә
борчылу катыш каушау...
Бармаклар да ак чәчләрне
табалар хәтта капшап.
Китәргә җыенган кошлар
йөрәккә килеп куна...
Әле август,
бары август,
нибары август кына.

## Теберда, октябрьдә

Алтын көзне быел күрми калам —
диңгез дулкыннары саргаймый...
Ә ярдагы төрле пальмаларда
еллар буе җылы май ае.

Күнегелгән инде елына бер
сары яфрак таптап йөрергә...
Төнне ташлап, яшел дулкыннарга,
сары көзгә җаным йөгерә.

Һәрбер агач хакыйкать күк шәрә!
Һәр агачның уе югары:
«Ботакларым — тамыр... Зәңгәр күктә.
Ябалдашым хәзер — Җир шары...»

Анда хәзер һәрбер агач — хаким,
һәрбер яфрак әзли варисын.
Килә икән кайчак хәтта яфрак
варисы да булып карыйсы.

## *Коньяктагы курортта*

Ил күләме басуларда
арыш, бодай бетте көеп...
Тугарылып бии халык,
тугарылып бии!

Безнең теплоходлар чит портларда
ашлык төйи...
Халык бии,
тугарылып бии!

Эче тулы борчу күтәреп
бии ала тугарылып!

Төшми,
тетми
ачлыкларны,
сугышларны
кичкән рухи югарылык!

## Алмагач монологы

Әллә инде ят тамырга
береккән бер агачмы мин?
Алма биргән өлешем генә
минем әллә алмагачмы?

Алмаларымның сутында
тамырымның тәме бармы?
Үзем актарып чыгарып
тамырымны тешләп карыйм —

алмамда да, тамырда да
бер тәм, чөнки бер кан ага!
Ә канымның чишмәләре —
Идел, Нократ һәм Камада.

* * *

Син хаклы, диңгез дулкыны,
хәрәкәттә — бәрәкәт!
Җил туктаса исүеннән,
аның өчен һәлакәт.

Син хаклысың, тау кыясы,
селкенмәү — ныклык көче.
Ава калсаң — ватыласың,
һәлакәт синең өчен...

Анысы белән дә килешәм,
бусын да хуплый күңел —
каршылыклар сыйдырмыйча
яшәүләр мөмкин түгел!

* * *

Минут саен гашыйк булып
йөрер көннәр бар, диләр.
Һәр очраган — гаҗәп гүзәл,
баш бирмәле яр, диләр...

Мин, ахры, шундый көннәрдә...
Шакката күңел күзем:
һәр очраган — пешкән хөрмә,
ал персик, кара йөзем.

Дөрестән дә баш бирмәле...
Бирәм — буйсынам көнгә...
Ә йөрәк башны үз буем
җитмәслек биек чөйгән!

## *Җир һәм Газазил*

— Кыныга тык кылычыңны —
кояш нуры киселмәсен!
Түк дарыны гранатадан —
тимер-томыр исермәсен!
Водородны суда калдыр —
ут һәм һава сугышмасын,
нейтроннар, котырынып,
Газраилгә булышмасын!
Винтовка көпшәсен төйнә —
очрашмасын кан һәм үлән!..

Җир
Газазилга
боера,
ә Газазил
Җирдән
көлә.

## Полигон

Җир — Кояшның полигоны.
Җылылыгының куәтен,
яктылыгы хасиятен
Җирдә сыный Кояш —
сулар ага,
туфрак яши,
канда җан,
үлән тере,
тере таш.
Җир — Кешенең полигоны —
уяу бул, Кояш!..

## Үтерергә өйрәнәләр

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Манекеннар әнә йөзтүбән
тузан көртләренә капланганнар —
күкрәкләре инде йөз көйгән.
Кулларында әлегә япьле таяк.
Меңәрләгән учта ышкылып,
ул шомарган. Ул тик йөрәк күзли —
гади таяк түгел, мушкалы.

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Өйрәтәләр күндәм тимерне...
Тимер көпшәләрдән чыккан әҗәл
күпме мишеньнәрне җимерде...
Алар безнең канны агызмакчы
мишеньдәге кызыл йолдыздан.
Ә йөрәкләр безнең мишень түгел,
тамырларда ага алсу таң.

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Галимнәрнең миен савалар,
атомнарны фетнәгә өндиләр,
нейтроннарга коткы салалар.
Һәр агуга дуслык кулы сузып,
микробларга тотып тәлинкә,
ясамакчы алар бергәләшеп,
безне үтерә торган ярминкә.

Без яшәргә Җирдә өйрәнәбез!
Безнең максат авыр, катлаулы.
Аңа бәрелеп инде ничә үлем
өс-өстенә ничә кат ауды.
Кызганычка каршы, айныдылар...
Сытып булмады шул бер орып.
Хәзер бездә әзер — Кояш кебек,
Җир шары күк ныклы йодрык!

## Бокс

Китереп сукты...
Барып төштем һәм аунадым —
н о к д а у н !
Судья саный:
бер... ике... өч...
Таптым көч —
торып баса алдым.

Тагын да аның гөрзиен
мин кире кага алмадым —
китереп орды —
һәм н о к д а у н !
Судья саный:
дүрт... биш... алты...
Аңыма килдем...
Сикереп тордым...
Бер раундтта өч нокдаун
була калса —
ул н о к а у т,
ул оттырыш...

Бер гасырда ике Сугыш!
Өченчесе яный янә...
Анысына ирек бирсәк...
Ул вакытта
Җир эләгер
н о к а у т к а.

## *Кара таракан*

«Сугыш» сүзе керсә,
шигыремнең
җыерылып куя юллары.
Сулыш алсаң, эчкә «сугыш» үтә
бигрәк тә бу соңгы елларны.

Ул үзе юк,
ләкин кемдер аның
Җир буйлата рухын тарата...
Планетаның ул аш өстәленә
килеп төшкән кара таракан.

Барысы да аңа суга:
кашык,
пычак,
сәнәк,
махсус шапалак...
Үлде дисәң — исән. Йөгереп китә
антеннасы белән кабалап...

Ә өстәлдә затлы тәлинкәләр,
хрусталь ваза,
фамиль фарфорлар
чәлпәрәмә килеп өелеп кала,
табын ямен урлап, аш хурлап.

Ә шигырьнең пакь, саф асылына
үтә алмагандыр таракан...
Рифма белән мин рифмага суктым —
чәчрәп керде сүзгә кара кан...

## Күгәрченгә бәрелеп

Машиналар
күгәрченнәрне таптый...
Мәче асфальттан курка — аңа ятмый.
Эт стеналар ышыгыннан атлый,
үз оясына сыерчык кайтмый,
инде кеше җанына тынычлык тапмый —
төрле сурәт килә борчулы башына:
«Күгәрченгә бәрелеп үлгән машина...»

## *Замана яктысы*

Замана яктысы
Намусның ак төсен
Сугышлар сөреме астыннан
Актарып чыгарды,
Күрсәтте...

Һәм безнең
Бер тапсыз,
Пакь дигән намуслар
Үрелде тешләргә терсәкне...

* * *

Барысы алдан билгеле,
килеп тора көткәнең...
Көткәннәр гел килә торгач,
мин бозылып бетмәмме?
Көтмәгәнчәрәк иссә җил,
йә кар төшсә иртәрәк,
акылда да, алдымда да
калкып чыга киртәләр.
Бәрелеп һушымнан язсам,
яңгыраса сыбызгы,
торалырмынмы Замана
санаганчы тугызны?..

* * *

Мин хуҗасы да Җирнең, колы да —
кулымда
тузганак таҗыннан да тотрыксызрак,
нәфисрәк Җир шары.
Хәтта кирәгеннән артыграк кыймылдарга да,
кискенрәк суларга да кыймыйм —
«Тузгыр!.. Югалыр!..» дигән борчу
җанымны кыйный.

Без шулай —
беребездән беребезне булмый аерып —
йөрәгемә беркетелгән мәңгелек чылбыр,
очында
диңгез минасыдай Җир шары.

## *Мин ул*

Мин ул — инде Айга аяк бастым!
Мин ул — Океан төбен таптадым!
Мин ул — Суны Утка әйләндердем,
эзләгәнем ләкин тапмадым...

Бар кылганым — бәхет хакына тик!
Һәм ул арта! Шуңа яшим мин.
Бәхет арткан саен, борчулар да
йөрәгемдә ешрак яшенли.

Җанга тынычлык мин кайдан алыйм?
Гөлләр, күлләр, хезмәт, мәхәббәт
ирегендә ничек онытылыйм?
Бер үк сорау һаман. Мең кабат.

Ядрәләрдән туган кара утлар
борчуларны тота сүндерми...
Фетнә Җиргә ничек итеп Күкнең
олы тынычлыгын сеңдерим?

## *Янган йөрәк*

Йөгереп кил дә син диңгезгә ташлан —
ялкыныңны биреп, ал дымын...
Әй йөрәгем, яргаланып бетеп,
ачык яра булып калдың син.

Яраларны ерта заман җиле...
Үтеп акыл чиген-ызанын,
салкын сугыш төкереге аша
тула синә нейтрон тузаны.

Сиңа кереп аңны агулый ул,
һәм канымның боза телен үк.
Җаным белән мин аңлаша алмыйм,
ялгызлыкта калам бүленеп.

Кара төндә кайчак атлап узып
уйларымның кара сызыгын,
мин шулай да табам бу дөньяда
кеше булып яшәү кызыгын.

Без көчлерәк барлык яралардан,
барлык сугышлардан... барыбер...
Син, йөрәгем, янып яргаландың,
диңгезеңә таба бар, йөгер.

Барып җит тә дулкыннарга ташлан —
тоз ачытыр бераз... Ачытсын!
Агуланган яраларны саклап
кеше булып ничек яшик соң?

## *Сурәтләшүләр*

I

Мин Заманамны сурәтлим.
Буяуларым рухи буяу —
тизлекне, төсне, тавышны —
барысын беркетеп куя.
Кызыл төс каннан, иманнан.
Намусымнан алам агын.
Ә кара төс өметемнең
өзегеннән чыга агып.
Зәңгәрләре — мәхәббәттән,
сагыш — сары серен белә...
Калган төсләр — нәфрәтем һәм
ярсуларым сөременнән.
Бер төстән дә мин баш тартмыйм,
Һәммәсе дә бик кирәкле.
Күргәнемчә, аңлаганча
Мин Заманамны сурәтлим.

II

Замана мине сурәтли...
Ә ул гади рәссам түгел —
сынчы. Тәнемә тутыра
суын, утын, җирен, күген.
Күзләремә Ай аръягын
күрә торган караш бирә,
сүземә сөю җылысын
һәм үлем суыгын өрә.
Күзәнәкләремә яңа
көч яшәрлек оя уя,
аң-акылыма иңдерә
галәмәт галәми уйлар.
Шактый кискен, шактый кырыс,
тыныч, моңлы һәм йөрәкле —
күргәненчә, аңлаганча
Мине Заманам сурәтли.

* * *

Көймәмә әле Заманның
Чоңгылыннан су керми —
Беткән баш әйдә бетсен дип,
Упкынына сикермим.

Нык әле көймәм, нык әле —
Бара ул давыл ярып...
Ә менә йөрәккә авыр,
Йөрәгем, ахры, ярык.

Йөз тарафның йөз кайгысы,
Әйтерсең лә йөз энә,
Каннарыма кадалалар,
Үтмәкчеләр сүземә...

Миннән моң-зар сыкмакчылар,
Миннән — ир уртасыннан!
Ачудан үзем үземнең
Күкрәгем ертам сыман.

Сыкмый торсыннар әлегә —
Үз көймәмә су кертмәм.
Су «йотам!» дигәндә, дулкын
Күккә таба сикертә.

## Бирмә

Бер яулап алдыңмы — бирмә,
яу белән килсәләр дә,
тау белән килсәләр дә,
башларын исәләр дә,
алтыннар чөйсәләр дә...

Яулап алынган һәр басма
биегрәк барлык таудан,
ныклырак бар тәхеттән,
бар тизлекләрдән тизрәк
җиткерә ул бәхеткә.

Бер яулап алдыңмы —
бирмә!
Нәрсә генә булса да!

## Тынычлык таләп итәм

Кышын да, язын да, җәен дә, көзен дә,
бала тапканнан соң беренче тапкыр
йоклап киткән ана йөзендәгедәй,
тынычлыкны күрәсем килә күк йөзендә.

Мин Тынычлык таләп итәм!

Мәһабәт йөзсеннәр болытлар,
тигез карасын туры кояш
җанлыга да, җансызга да...
Тоташтырып җирне болытларга,
иген кырлары өстендә
аллы-гөлле булып балкып торсын
бәхет билгесе — сәйлән дага!

Мин Тынычлык таләп итәм!

Вакыты җитеп кенә эресен кар
һәм җырласын ерганак булып.
Шытсын бөре, төртсен үлән...
Кызган табага тамган тамчыларны,
буранга юлыккан бөреләрне
шундый язмышлы кешеләрне
күреп беләм.

Мин Тынычлык таләп итәм!

Өзелгән имән яфраклары
ятсын имән тамырына,
тал яфрагы — талныкына,
каенныкы — каенныкына...
Кайгыларын тамырына җыйган
һәм сеңдергән агач үлми —
халык кебек — ныгый гына!

Мин Тынычлык таләп итәм!

Сайрасын былбыл, аккош каңгылдасын,
чыр-чу килсен чыпчык, песнәк,
күгәрченнәр гөлдерәшсен...
Һәрберебезгә иң кадерле үз җырыбыз,
җырларыбыз барыбызның да —
чор тиңдәше!

Мин Тынычлык таләп итәм!

Җанлыбыз да, җансызыбыз да
имәбез ич һава дигән илаһи сөт!
Күкнең йөзе шатлыклы да, борчулы да —
беренче тапкыр күкрәк биргән ана йөзе кебек.
Мин Тынычлык таләп итәм,
таләп итәм тимердән, таштан,
таләп итәм кулдан, баштан,
үземнән, сездән,
күреп арыган һәм ачылып
беренче тапкыр шаккаткан күздән,
илдән илгә китәчәк,
халыктан халыкларга җитәчәк
һәрбер сүздән,
яңгыр тамчысыннан, җилдән,
һәр фиркадән, һәрбер илдән,
кыштан, яздан, җәйдән, көздән
Тынычлык
таләп итәм
Җиргә!

## *Ныклык бар!*

Көненә мең утлы хәбәр
үткәрәм йөрәк аша.
Һәр хәбәр кан тамырына,
әйтер сүзгә тоташа.

Башта — янгын...
Канда — ялкын...
Кагылмагыз, ут каба!
Шулай да Җиргә: «Яратам!» —
дип әйтергә көч табам.

Чөнки мин үзем мәхәббәт
назларын татып яшим.
Шомлы утларны сүндерә
шатлыктан туган яшем...

Кешедә, димәк, бәхеткә
ышаныч зур!
Ныклык бар!
Шуңа, күрәсең, сүзләргә
саркымый шомлы утлар...

## *Рәмел тактасы*

Алдым рәмел тактасын...
Карыйм — Язмыш капкасы!
Салдым Вакыт нуктасын:
күримче гасырымның
ахыр чиген, ноктасын.

Ачтым Язмыш капкасын...
Бәхеткә ут капмасын —
Замана нинди кызган,
яшәүнең тамырына
утлы кисәвен сузган!

Кисен акыл нуктасын
яман ялкын! Туктасын!
Җир тамырын сакларга
кешеләр йөрәгендә
калыкты нык калканнар.

Күрдем мин гасырымның
иң ахыр маңгай сырын.
Ул сыр мәңгегә йотты
кешелеккә янаган
иң олы яман утны.

Куйдым рәмел тактасын...
Яптым Язмыш капкасын...
Җеби Сугыш чакмасы —
бәхетенә ышанып
кеше тыныч атласын!

# *Яралар*

*(Цикл)*

## 1. Кереш

Яралы авыллар,
Яралы калалар,
Яралы халыклар һәм илләр!
Яралар турында сөйләргә хакым бар —
Сез минем хакыма дәлилләр.
Мин беләм,
Яраны онытып яшәргә
Тырышу — кешегә хас гадәт,
Ләкин бу шәп гадәт
Кешегә һәм илгә
Китерә аламы сәгадәт?
Күрәм дә яраны,
Хурланам мин кайчак,
Ә кайчак уяна горурлык.
Мин сизәм — аңыма, җаныма, рухыма
Иңә дәрт, иңә көч һәм зурлык.
Ил өчен, җир өчен көрәшкә әзер мин
Һәр секунд,
Һәр минут,
Һәр сәгать...
Аларны ярадан сакласам калкандай —
Сәгадәт бу!
Һәм мин канәгать!

## 2. Вакыт ярасы

Сау-сәламәт килеш килә Вакыт,
Бер дә булмый аның ярасы.
«Гасырлар» дип, «Чор» дип исем алган
Вакытларга бүген кара син.
Учакларда китап, шәһәр, кеше
Белән бергә яна, яна да
Яман дан ала ул. Илләр, җирләр:

«Аһ, килмәсен, — диләр, — яңадан».
Үткән вакыт кайтмый. Бусагада
Өметлесе аның, яңасы.
Безнең аша тавыш-тынсыз гына
Әйтерсең лә агып ята су.
Һәм шул суда балык кына түгел,
Шартлаталар кинәт халыкны.
Һәркайсы бер зур җәрәхәт булып,
Күпме халык инде калыкты!..
Кешелекнең ярасы ни зурлык —
Вакытның да шуның зурлыгы...
Җәрәхәтле вакыт китә... Кешелеккә
Яра булып кала хурлыгы.

### 3. Җир ярасы

Континентлар тоташ булган, диләр,
Хәзер океан алар арасы.
Шушы микән әллә Җир шарының
Иң олы һәм тирән ярасы?
Җир өстендә гүли янар таулар,
Шартлап туа һаман яңасы.
Әллә шулар микән планетаның
Иң олы һәм тирән ярасы?
Сау акыллы беркем, бернәрсә дә
Яраламый үзен... Көтмәгез!
Эзләгәндә яралаучыларны
Үзегезне читләп үтмәгез!
Яраларны кемдер, нидер сала.
Тарих шаһит моңа. Бу — канун.
Кешеләргә, җанвар, үләннәргә
Җир бетергән биреп үз канын,
Ә кешеләр кешеләргә ата,
Кешеләрдән ага Җир каны...
Без соң Җиргә «кемдер», «нидер»мени?
«Ана» димибезме без аны?..
«Сакланыгыз — шартлыйм!» — диеп, таулар
Хәбәр итә алдан ничек тә.
Континентлар континентка якын,

«Исәнме!» — дип сузсаң — кул җитә.
Бернәрсә дә тоташтыра алмый
Үле белән тере арасын...
Кеше кулы белән киңәйтелгән
Шундый ара — Җирнең ярасы.

## 4. Илемнең олы ярасы

Һәрвакыт башка һәм йөрәккә
Чамалый ядрәсе катыйльнең,
Төбиме үз җирең дошманы,
Төбиме күзләре ят илнең.
Һәрвакыт башка һәм йөрәккә...

Аттылар Ленинга — йөрәккә...
Ул чакта ил әле нарасый.
Һәм илем нарасый килеш тә
Күтәрде бу олы ярасын.

Халыклар түзмәсә — ил түзми,
Ә илгә озын юл барасы.
Рухыма һаман да көч бирә,
Үч өсти илнең шул ярасы...
Халыклар түзмәсә — ил түзми!

## 5. Төсләрдәге яралар

Һәр дәүләтнең байраклары төсен
Ихтирамлый һәркем берсүзсез,
Байрак илне, чәчәк җирне бизи,
Бу җәһәттә алар бертигез.

Байракларны төрле төсле куллар
Күтәрәләр илләр исеменнән.
Йә, әйтегез, кайсы байракларга
Төс йоккан бар куллар төсеннән?

Куллар төсе Җирнең кайсы төшен
Таплаганын әйтә аласың?!
(Ап-ак тәнгә поскан кара җаннар,
Җавап табарга сез чарасыз.)

Байракмы ул, тәнме — төсләр тигез.
Бу тигезлек кемгә ярамый?
Кемнәргәдер ярамаган өчен
Җирдә хәтта төсләр яралы...

### 6. Гадәт ярасы

Сугыштан ул чулак булып кайтты.
Сыңар кулын ядрә йолыккан.
Дөбердәтеп эшли. Теге кулын
Әллә кайчан инде оныткан.

Тик кайвакыт көрсенгәләп куя —
Була аның шундый чаклары:
Татарчалап, ике кулны сузып
Күрешә алмый менә татарың.

Һәм ялт итеп кулларыңа бага.
Көрсенмичә түзеп кара син...
Кулыннан да бигрәк гадәтендә
Аның мәңге сыкрар ярасы.

### 7. Яралы өйләр

*Сталинград өйләренә*

Буйсынмаучаннарның йорт-җирләрен
Җимерәләр явыз, үчлеләр.
Карусызның өен җимермиләр,
Үз өендә үзен көчлиләр.

Буйсынмаучаннарның йорт-җирләре
Бомбалардан ала яраны.
Карусызлар өе мәсхәрәдән,
Мыскыллардан кала каралып.

Буйсынмаучаннардан йорт-җирләрен
Сипләү өчен михнәт сорала...
Карусызлар бу газаптан азат,
Тик йөзләрен каплап торалар...

### 8. Яралы җыр

Җирдә җыр бар — мең макталган,
Мең атылган, тапталган,
Мең тапкыр канга батып та,
Икмәк кебек саф калган.
Революционерлар Җирдә күпме —
Шулчаклы яраланган.
Йөрәге мең тишелеп тә,
Һава күк исән калган.
Патшалар киртә күтәргән,
Дәүләтләр аяк чалган,
Җир буйлап хәрәкәтендә
Җил кебек даим калган.
Аңа арттан ташланганнар
Хыянәт, яла, ялган,
Ул үзенең тумышына
Дуслык күк тугры калган.
Күпме илнең гимннары
Аңа бәрелеп уалган...
Шундый көч була торып та,
Диктатор булмый калган,
Ул тыйнак булып калган.
Җирдә җыр бар — иң күп яра,
Иң зур дан, шөһрәт алган.
Капиталларга кадалып,
Ирек булып яналган!
Ул — Интернационал!

### 9. Коммунист ярасы

Ул яралы килеш әсир булды.
Гаепләрсез микән сез аны?
Күкрәгеннән каны саркыса да,
Сау-сәламәт иде иманы.

Кыйнадылар аңын югалтканчы,
Тырнадылар күкрәк ярасын...
Иман түзәр, тик тән түзә алмас,
Коммунист та — адәм баласы!

— Мин тагы да чыдый алмыйм, — диде, —
Кыйнамагыз артык, сукмагыз,
Каләм, кәгазь, кара китерегез —
Сызам партизаннар сукмагын.

Бу күзләрем аны яхшы белә,
Кулларның да көче үзендә...
...Һәм каләмен карасына манып
Кадады ул... үзенең күзенә.

### 10. Яралы намус

Әйтелергә тиеш хаклык сүзең
Очмый кала икән ук булып,
Үзеңнең үк намусыңа төшәр
Мәңге өтә торган ут булып.

Әйтелмәскә тиеш яла сүзең
Бер ычкына икән телеңнән,
Үз намусың синең гомер буе
Телем-телем булып теленә.

### 11. Ике төрле яра

Батырның ярасы бар икән —
Күкрәктә инде ул ярасы.
Куркакның ярасы бар икән —
Яшерер яралы аркасын.

Орденга, һич югы, медальгә
Тиң була батырның ярасы.
Куркакның ярасы — хурлыкның
Вөжданга ягылган карасы.

### 12. Чагыштырма

Үз батыры һәрчак иң зур батыр
Теләсә генә нинди халыкның.
Ул көчлерәк диеп чагыштырма
Муромецны яки Алыпны...

Һәр икесе халык күңеленнән
Хыял булып калкып чыкканнар.
Һәр икесе газиз иле өчен
Ат менгәннәр, кылыч тотканнар.

Илләр уртак булмаганда алар
Бер-берсенә каршы калыккан.
Күңелемдә бүген алар тигез —
Илья Муромец та, Алып та.

Чагыштырма! Чагыштырулардан
Бары рәнҗер генә батырлар.
Зур дуслыкка яра сала торган
Күтәралмас ташлар атарлар.

Үз батыры һәрчак иң зур батыр
Теләсә генә нинди халыкның...
Алар тигез, чөнки Ватан уртак
Илья Муромецның, Алыпның...

### 13. Хыянәт ярасы

Нәрсә соң һәрчакта
Иркәләп, кочаклап
Үтергеч яралар салучы?

Килер дә кыямәт,
Терелер үлеләр,
Әйтерләр: «Хыянәт! Хыянәт!»

Нәрсә соң һәрвакыт
Юатып-юатып
Үтергеч яралар салучы?

Килер дә кыямәт,
Терелер дәүләтләр,
Гүләрләр: «Хыянәт! Хыянәт!»

Нәрсә соң һәрьяклап:
«Бай, гүзәл», — дип мактап,
Үтергеч яралар салачак?

Булмас та кыямәт,
Җир әйтер, су әйтер,
Күк әйтер: «Хыянәт! Хыянәт!»

### 14. Илләр парады

Куанасы килде, ахры, Җирнең,
Ясады ул илләр парады.
Саф-саф булып торган дәүләтләргә
Гашыйк күзләр белән карады.

Кинәт кенә кәефе кырылды...
«Барыгыз дамы?..» — диеп сорады.
Аннан әйтте: «Яралылар күрәм,
Яралылар! Алга бер адым!»

Һәм буйсынып Җирнең әмеренә,
Барлык илләр алга атлады.
Ә аларга бары берничә ил
Ияргергә кирәк тапмады.

Һәм аларга карап, Җир эндәште:
Сез соң ничек исән калдыгыз?
Җавап бирде илләр: «Без яралы,
Хәтта адым атлый алмыйбыз...»

Күз алдында булган бу эшләргә
Җир чирканып, өтеп карады.
Һәм уйлады: «Кайчан ясап булыр
Бәхет тулы илләр парады?..»

### 15. Җан онытмас

Тән оныта,
Җан онытмас яраны.
Җан оныта,
Кан онытмас яраны...
Сәясәттә яки туплы фронтта,
Каһарманлык билгесе ул —
Онытма!
Һәм куркаклык шаһиты да —
Онытма!
Карап безнең яраларга,
Оныклар
Тарихларын бәһаләрләр,
Онытма!
Тән оныта,
Җан онытмас яраны.
Җан оныта,
Кан онытмас яраны.
Кан оныта,
Аң онытмас яраны, —
Көрәш эзен
Беркайчан да
Онытырга ярамый!..

## *Баскычлар*

Без,
Нәрсә генә ясасак та,
Нәрсә генә эшләсәк тә,
Үзебезгә баскыч төзибез.
Басмалары буйлап
Йортлар, юллар сала-сала,
Хәнҗәр безенә баса-баса,
Күкрәк белән дотлар каплый-каплый,
Шахталарда шартлый-шартлый,
Космик корабларда яна-яна,
Ак кәгазьгә канлы шигырь булып тама-тама,
Әкрен генә
Өскә ашабыз,
Тырыша-тырмаша,
Хыялыбызга якынлашабыз.
Без калдырган
Агач, таш, сүз, нур баскычлардан,
Безнең эзләргә баса-баса,
Безнең варисларга төшә
Табигатьнең ачылып китеп
Бәхеткә әверелгән сихри сере.
Без баскыч басмаларында гына
Бәхет белән очрашабыз!
Баскыч басмаларында гына
Кеше тере!

* * *

Җанлының да, җансызның да
Җаны сыза —
Җырлыйсы килә.
Утның җыры — ялкын,
Суның җыры — дулкын,
Һава җыры — зилзилә.
Кешенең
Ут булып та,
Су булып та,
Һава булып та җырлыйсы килә.

* * *

— Шагыйрьләр
Заманнарын сүгеп шагыйрь булган,
Заман барган юлга
Алар читтән карый алган,
Аларның гына йөрәкләре
Заман өчен ачынып янган...

— Ялган!
Сүгүчесе дә ялган,
Мактаучысы да ялган.
Еллар аша үтеп,
Мәңгелек хискә кагыла алган,
Үзенә ияртеп елмайткан,
Үзенә ияртеп елаткан,
Менә бүген миңа
Сүгенергә үз сүзен биргән,
Менә бүген миңа
Мактанырга үз сүзен биргән
Кеше заманында шагыйрь булган,
Калган!

## *Җай таба*

Бөек халык бәхәсләшми,
Бөек халык юл саба,
Мылтык көпшәсендә
Ядрә белән очрашмаска
Җай таба!

## Тарихи тамаша

— Әһ-һә-һәй!
Ике илнең бер нияте эшкә ашты:
«Союз» — «Аполлон» очрашты,
«Союз» — «Аполлон» тоташты!
Кешеләр җирдә кул кысышканга
Күктә тимерләр кочаклашты,
Күктә тимерләр кочаклашты,
Кешеләрчә җылы итеп.
Кешеләрчә җылы итеп,
Ихлас кочаклашкан көе,
Җырлашып йөрде космоста
Ике илнең берәр өе,
Ике илнең берәр өе!

* * *

Галилей хаклы булганда,
Бөтен башка кешеләр,
халыклар,
илләр
Хаксыз булган.
Хак сүз туганчыга хәтле
Җир турында
Шулай да нахак сүз туган...
Кеше
Җиргә сеңгән нахак сүзне,
Бруно,
Пушкин,
Җәлил булып,
Каны белән юа.

## Чөйсәләр...

Чөйсәләр мине күкләргә шоңкар итеп,
Табыныбызга өелер куян ите...

Чөйсәләр мине күкләргә бөркет итеп,
Ил базына төяп куям кәҗә ите...

Атомлы самолет итеп, — мине — күккә...
Җир дә, күк тә тыгылыр безнең иттән...

## Йомшак бәгырьләр

Эрер өчен бер җылы сүз җиткән
Йомшак бәгырьлеләр!
Яратам сезне!
Хатын-кыз алдында
Куанычтан елый алган ирләр,
Иркәләүгә түзә алмыйча
Күз яше койган хатыннар,
Беренче үптергәннән соң
Елый белгән кыз-кыркыннар,
Безнең спортчылар җиңгәндә
Бугазларында шатлык төере
Тойган егет-оланнар!
Сезнең йомшак күз яшегез —
Ватанның ныклы нигез ташы.
Сез генә —
Йомшак бәгырьлеләр генә —
Кайгыларга каты буласыз,
Нык торасыз.
Сез
Эретеп
Йөрәгегезгә
Ватанны тутыргансыз!

## *Менә шулай*

Тарафыбызга карап:
— Дуслары кем,
Дуслары белән дуслашасы иде, —
Диючеләр белән өебез тулды.

Ягыбызга ымлап:
— Дошманнары кем —
Дошманнары белән танышасы иде, —
Дип теш кайраучылар да булды.

Менә шулай яшәдек без —
Дусларыбызның кемлеген белеп,
Дошманлашырга теләмәде
Беркем!

Дошманнарыбызның кемлеген белеп,
Дусларыбыз артты
Һәр көн!

## *Шипка монастыренда*

Чыкларын коя-коя,
Шипка монастыренда
Казан полкы каберенә
Гөләп куям...

Салкын ташка чәчәк куюдан да
Авыррак эш юктыр йөрәк өчен.
Гасыр элек булган эшләр аркасында
Бүген йөрәк даруы эчтем.

Күрше хакына, дуслык хакына
Кая килеп, кая менеп сугышканнар,
Баш салганнар!
Минем Казаным исеме мәңгелек ташта,
Казан полкы каны
Минем канда.

## *Пумала*

Шәп тә нәрсә рәссам пумаласы —
Ачык итеп, төсле итеп
Туктата да куя мизгелне!
Кизәнгән куллар мәңге-мәңге сукмый,
Каргарга ачылган авыздан
Бер аваз да чыкмый,
Качарга җыенган дошман
Атлый алмый адым...
Ләкин
Кочарга теләгән кочак та
Мәңге буп-буш,
Үбәргә теләгән ирен дә
Мәңге ялгыз,
Йөкле хатын карынында
Ничә йөз яшьлек тумаган бала...

Пумала
Аптырап калган...

* * *

Гаҗәп!..
Күк күкрәүне хәзер
Бернигә дә санамыйбыз,
Хәтта күтәрелеп тә карамыйбыз —
Үтеп барадыр дип самолет кына.
Яшен яшьнәп
Кинәт яңгыр тотына...
Юа чәчне,
Юа башны,
Үтеп кермәк була аңга —
Күзәнәккә бәреп керә.
Юллар ябык —
Машиналар тыгылышы анда.

* * *

Аткан таң алга дәшә.
Язны без үтеп китәбез,
Кар суы булып яшәп.

Аткан таң алга тарта.
Җәебезне үткәрәбез
Чәчәкләрдә, яфракта.

Аткан таң алга өнди.
Көзне кичәбез һәм — кышка...
Керәсе килми инде.

Аткан таң алга сөйри...
Шаккатырга өлгермисең —
Китереп җиргә тери.

* * *

Аптырагач,
Маңгай учка ята —
Акыл җыерчыклары
Тоташа хезмәт җыерчыкларына.
Кинәт кеше
Хәлсезлектән арына,
Күтәрелә,
Күзен кыю ача,
Аягын тәвәккәл баса.
Кешенең нияте кулына килеп җитә...
Аптырау кача...
Һәм ул
Яңадан хуҗа
Җир шарына!

## *Оялар*

Җирдә тишек.
Аңа корт йә бөҗәк кенә сыя,
Ләкин бу — оя.
Менә бу күчне
Кырмыскалар җыйган —
Ул да оя.
Агач кәүсәсендә куыш.
Аңа тиен сыя я зуррак кош.
Имән башында карга утыра.
Имән үзе кыяда тора.
Болытка кагылып оча бөркет.
Көне буе оча,
Бер дә утырмый.
Аның оясы кайда?
Кыяда түгел —
Карга утырган кыяга бөркет
Оя кормый...

* * *

Бер дусымны уң җилкәмә күтәрдем,
Бер дусымны менгердем сул җилкәмә.
Икесе ике иңемә бастылар,
Аяк тибеп әрләштеләр иң әүвәл,
Җиң сызганып алыштылар аннары,
Кылыч алып сугыштылар бик яман.
Кылычка кылыч чаптылар.
Чаткылар
Чәчрәде дә минем чәчне көйдерде.
Кизәнеп тә төгәл чапмаган чакта,
Кылычлары кадалды минем башка.
Сугыштылар...
Арыдылар...
Тындылар...
Тотындылар, аумаска, минем башка —
Куллары минем каныма буялды.
Чиркандылар...
Төштеләр иңнәремнән.
Икесе бер үк инешкә киттеләр.
Кул юдылар, хәл алдылар бергәләп...
Ялгыз калдым яу үткәргән кыр кебек.
Күңелемә канлы-яшьле җыр тулды...

## *Алтын сүз*

Җаннан кан сыгып
Бәхәсләштек
Без, ун егет,
Бишкә биш түгел,
Гаскәргә гаскәр килгән кебек,
Ә аксакал күзәтеп торды, сүз әйтмәде.
Әйтелмәгән сүзе аның
Әйтелмәгән саен кыйммәтләнде.

Авызын ачты...
Соңгарып чыккан алтын сүзе
Салкын чылтырап ташка бәрелде.
Салкын сүзе аяк астында
Бер тиенлек бакырга әверелде.

* * *

Чигәдәге һәр чал чәчне саный китсәң,
Һәр чал чәчкә берәр эшне сәбәп итсәң,

Һәр сәбәптә гаеплене торсаң барлап,
Күңелеңнән сүксәң аны каргап-каргап,

Барып җитсәң атасына, бабасына,
Аның туган авылына-каласына,

Туып үскән йорт нигезен ватсаң вак-вак...
Чигәң түгел, бөтен башың булыр ап-ак.

Ә йөрәккә кара төшәр шунда тап-тап...

## *Бозлавыклар*

Кешегә кешедән,
Илләргә илләрдән
Җылы сүз кирәк иде!..

Эфирда күпме бозлы пычрак —
Кеше күңеленә дә,
Илләр күңеленә дә,
Җир күңеленә дә, ахры,
Күз тиде...

Әллә инде йөрәкләрдә
Башландымы бөек бозлавыклар вакыты —
Минем җылы сүзем
Берәүнең күңеленә
Боз өстендә саңагы каткан
Балык кебек ятты.

Әллә инде Җир әхлагында
Бөек бозлавыклар Вакыты?..

## *Ике гөл*

Чүлмәктәге гөл
Бакчадагы гөлгә
Тәрәзә аша әйтте:
— Бел,
Мин кышын да яшел торам,
Аркамны да, ян-ягымны да
Кояшка борам,
Теләсәм,
Башка тәрәз төбенә дә күчеп утырам.
Миңа төшми кырау...

Бакчадагы гөл әйтте:
— Бәйләнмә!
Менә минем тирәмдә
Кояш үзе әйләнә,
Миңа сандугачлар оя кора!..

## *Исле гөл*

Тәрәзә төбем исле гөл,
Исерәмен исенә...

*Татар халык җыры*

Исле гөлләр исен сибә
Искән җилләргә генә.
Тәрәз төбен сагыш сарды —
Җилләр исмиләр менә.

Тәрәзләр чартлап ябылды —
Көз килүен сизделәр.
Җилләр бүлмәм белән барлык
Элемтәне өзделәр.

Янәсе, ул ирегеннән
Баш тарткан үзе теләп...
Әнә сары яфрак бездән
Баш селки-селки көлә.

Исле гөл иссез утыра.
Кагып җибәрдем генә —
Бүлмәгә хуш ис таралды...
Җил юкмы бездә? —

Менә!..

## *Сагындырган*

Сагындырган,
Ай-һай, сагындырган
Көзге шәрә урман —
Нечкә бармакларын
Башлары өстендә күккә сузып,
Малайлар күк бии торган
        Юкәләр.

Толымнары болытка чолганып,
Һавада эленеп торган
        Каеннар.

Туфрак дип белеп, кара болытка
Тамыр җәергә җыенган
        Таллар.

Күк ватылып җиргә атылса,
Тотып калырга кочак ачкан
        Имәннәр.

Җил елаганда җырлый торган
        Усаклар.

Сынмаска ант эчкән карт кебек
        Карамалар...
Сагындырган!
Һәркемгә дә аңлашылган,
Һәркемнең дә күңеленә хуш
        Үтә күренмәлелек,
        Ачыклык,
        Киңлек!
Купшылык туйдырган —
Урман барлык серен сөйләп бетергән
Кеше күңеле кебек булып куйган.

Сагындырган,
Ай-һай, сагындырган,
Күкне җиргә тартып төшереп,
Җибәрмичә тоткан,
Шул шатлыктан
Кеше кебек кулын изәп,
Тугарылып бии торган
Шәрә урман.

* * *

Күргән күпме ак болытның
Бары берсе хәтеремдә,
Бары берсе күз алдымда —
Гигант кеше,
Җиргә карап, тавыш-тынсыз
Әллә көлә,
Әллә елый,
Тиздән тавышы ишетелер күк.
Каһкаһә генә булмасын!
Кызгану гына булмасын!

* * *

Ләйсән яңгыр быел төнлә яуды.
Нигә яшеренде икән бездән?..

Яумыйча да, китмичә дә бер күк болыт
Аптыраткан иде безне үткән көздә.

Әллә нәкъ шул болыт тагын килде микән?
(Булыр да икән кеше гадәте!..)

Гаебеннән ояла белгән кеше кебек,
Сайлый белгән бит төнге сәгатьне...

* * *

Утыз ел авызлык тешләгәннән соң,
Авыр йөк тарта алмый башлагач,
Айгырны ялга озаттылар —
Нәсел арттырырга.

Сикерүе тәбәнәкләнгәч, ямьсезләнгәч,
Утыз алты яшьлек балерина
Ялга китте —
Алмаш әзерләргә.

Алтмыш яшьлек шагыйрьне
Озаттылар «лаеклы ялга» —
Ул яңа гына
Иң акыллы шигырьләрен башлады...

## *Кайсына тиң?*

Бозны тишеп чыккан умырзая,
Ташны күтәреп чыккан гөмбә,
Кырлар аша суга шуышкан еланбалык,
Океан аша очып чыккан кошчык,
Абзарын ватып бия янына чыккан айгыр
һәм
Кырын ятып,
Хыял диңгезенә батып,
Заман битенә пычрак атып,
Озаклаган бәхет турында
Сафсата сатучы син.
Син,
Илаһи зат,
Шул мескеннәрнең кайсына тиң?..

## *Иң көчле кул*

Таштан су сыгучы дисеңме?
Үгезне мөгезеннән тотып егучы дисеңме?
Тәхеткә патшалар куючы дисеңме?
Җиргә үлем яңгыры коючы дисеңме?
Юк!
Дөньяда иң көчле кул —
Картның
Оныгы иңендә
Тыныч кына яткан кулы,
Егетнең
Сөйгәне билендә
Хәлсезләнеп яткан кулы!
Сабыйның
Анасы күкрәгенә баткан кулы!

## *Йодрык һәм бармак*

Йодрык башлаган сугышның
Беркайчан да илләр чиген узганы юк,
Җирнең битен бозганы юк.
Ахыр чиктә,
Авыр чиктә
Авыл читенә барып җиткән,
Тешлене тешсез иткән,
Кан түкерткән...
Разбой салдырып йөгерткән дә —
Беткән.

Бармак башлаган сугышлар —
Курок тартып,
Кнопкага басып,
Каләм тотып боерык язып,
Бармак башлаган сугышлар
Җир шарының
Янбашын өткән...

Ә йодрык
Шул ук бармаклардан хасил.
Көч алдында билен бөккән,
Оятыннан башын игән,
Әмма һәрчак боерык көткән
Бармаклардан.

* * *

*Мәңге егет булып калган яшьтәшләргә*

Яшел яфракларны кар каплады.
Яшел килеш
Үлде
Яфраклар...
Яшел гимнастеркаларга явып-явып,
Эремичә калды
Кәфен-кар...

## *Арагызда*

Иделне йөзеп чыгучы, тик тор!
Шаулы диңгез кичкән егет, утыр!
Масайма,
Океан убаларыннан исән чыккан батыр! —
Тирә-юнегезгә карагыз —
Арагызда
Хәтта күз яше ташкыннары аша
Кичүчеләр бар!

* * *

Күк моңайса,
Кеше кебек — күз яшен коя;

Җир моңайса,
Кеше кебек — ярсуын тыя;

Су моңайса,
Кеше кебек — тар ярга сыя;

Кеше моңайса,
Күк кебек төссез,
Җир кебек сүзсез,
Су кебек эзсез
Була да куя.

## *Ул көн уза*

Һәркемгә дә бер көн килә —
Күңел күзен киләчәккә төбәткән көн,
Моңарчы ничек яшәлгән,
Моннан соң ничек яшисе, дип әйткән көн,
Ул көнне күңел,
Бар дөньясыннан читләшеп,
Яшәү хакында
Үз-үзе белән киңәшә...
Ул көн уза,
Һәркемнән дә ул көн уза!

* * *

*Р.Г-инга*

Беркайчан да сезгә күрсәтмәмен аны,
Аны — мәхәббәттән шашкан чакны.
Күзләремә күл булып җыелган чаткы,
Йөземә ирен булып яткан ялкын,
Күкрәгемдә йөрәк булып типкән дулкын
Артык ачык,
Артык шәрә...
Гашыйк чагымны күрәсегез килсә,
Нәфрәтем эченә кертеп җибәрәм.

## *Төн*

Төн
Пыяла аркылы
Бүлмәгә агып керде дә,
Түшәктәге яшь парны күрде дә
Куерды, куерды, куерды һәм
Чыбылдыкка әверелде.

Төн
Пыяла аркылы
Бүлмәгә агып керде дә,
Ак түшәктә ялгыз карчыкны күрде дә
Уңайсызланды,
Бүзарды һәм
Тизрәк көнгә әйләнде.

## *Сүнмәгән ут*

Үткән гомер — сүнгән күмер.

*Татар мәкале*

Үткән гомер — утлы күмер —
Эретә йөрәк маен...
Яна бит, яна һаман да
Серемне белгән каен.

Калтыранган тезләр, сүзләр...
Синең миңле иңбашың...
Син — шаһинә, мин — бер малай...
Бер канатлы аңлашу...

Мин, шәт, иркен сулар идем,
Шул каен сүнсә-тынса...
Аһ, ул чакта үбеп сине
Елата алган булсам!..

«Еламаса, яр — яр булмас» —
Дөрес сүздер, мөгаен.
Күз яшеңнән сүнмәгән ут
Көйдерә йөрәк маен.

## *Кесә көзгесе*

Беркөн кибеткә кердем,
Кесә көзгесе күрдем.
Кибетче аны төрде,
Төрде дә миңа бирде,
Үтереп мактый-мактый.
Теләмәсәм дә алдым,
Алдым, кесәмә салдым,
Салдым да уйга калдым:
Нигә кирәк ул миңа —
Мыек йөрткән егеткә?!
Уйга батып беткәнмен,
Урам буйлап киткәнмен,
Күл буена җиткәнмен.
Карасам — бер кыз тора,
Елмаеп, каш сикертеп.
Әйтсәм әйтим сүз ара:
Баш әйләнми кызлардан,
Моны күрсәм — кызарам
Гаепле малай кебек.
Зиһеннәрем чуала.
— Энҗе-мәрҗән таптыңмы,
Әллә куркып чаптыңмы,
Әллә юлдан саптыңмы? —
Күз карашларың таркау —
Гашыйк булдыңмы әллә?
— Әйе, — дидем, — мин гашыйк,
Шуңа күрә саташып
Йөрим менә адашып,
Әкияттәге кебек
Берәр могҗиза көтеп.
— Кем ул юньсез кыз бала?
Кем сине утка сала,
Ә үзе читтә кала?
Күрсәт үзен, бәлки, мин
Сиңа ярдәм итәрмен.

— Ул булмаса, мин үләм,
Сурәте үзем белән,
Теләсәң — кара... Менә...—
Кызыкайга суздым мин
Теге кесә көзгесен.
Кызый күрде дә үзен,
Яшерде миннән күзен.
Чайкаган булып бүзен,
Теге кесә көзгесен
Күл төбенә ташлады.
— Бары икебез генә
Карадык бу көзгегә,
Анда безнең йөз генә.
Көзге өчен бу сурәт
Мәңге бердәнбер булсын...

## *Кызыл маяк*

Без очраштык,
Кыз елмая...
Кулын тоттым —
Кыз елмая...
Күтәреп алдым —
Кыз елмая...
Кысып кочтым —
Кыз елмая...
Эңгер төшкән Идел тып-тын.
Уртасында ялгыз утрау,
Ләкин керергә ярамый —
Каршысында кызыл маяк.
Кочагымда кыз елмая...
Иреннәре —
Кызыл маяк.

## *Көндезге Ай*

Күренер-күренмәс көндезге Ай...
Минем сиңа әйткән сүзем,
Көндезге Ай кебек,
Сизелер-сизелмәс булды бугай.
Тиздән кояш түшәккә чумар...
Яктырып китәр әлеге Ай.

Хисемне сиңа җиткерергә
Кояш комачаулый бугай...

* * *

Бер-беребезгә шундый якын идек,
Арабыздан бер кош үтсә,
Бер канаты сиңа тия,
Берсе миңа тиеп китә.
Хәзер инде бик якын чак...
Арабыздан тик
Сак-Сок оча...

* * *

Очрашканнар.
Шатлыгыннан кызы елый —
Күз яшьләре
Чишмә булып агып чыга да
Җиргә тама.

Әнисе елый —
Күз яшьләре
Елга булып агып чыга да
Йөзендәге җыерчыкларда югала.

* * *

Вәгазь укырмын дип куркам.
Димәк, яшь, көчле, димәк,
Сүз белән түгел, эш белән
Йорт салам, игәм икмәк...

Вәгазь укырмын дип куркам...
Димәк, мин әле көчсез,
Димәк, минем юк әлегә
Яшьләрдә яшьнәрлек сүз...

## Таң алды

Таң алды...
Таң алды...
Таң кара төнне җыеп алды,
Томанлы офык артына салды.
Беравыктан офыкта
Кара болыт түгел,
Кызыл кояш калыкты.
Таң калдым.
Таң алды.

## *Бер дә юшкынсыз*

...Шулай да саф, тонык, ахры,
Тормышның һәр манзарасы —
Күз карасы
Бер дә юшкынсыз,
Күз карасы
Һаман нарасый.

## Бизәк

(Цикл)

### 1. Бизәк җимшәне

Такталарда, ташта, ефәкләрдә
Еллар кичкән сурәт, кул эше
Үлгәнче үк бездән тартып алган
Җаныбызның матур өлешен.

Ә гомерләр, бәлки, кыскаргандыр,
Ә җан ләкин һаман баеган...
Бизәктәге гөлләр арасында
Адашканнар безнең кайгылар.

Бизәктәге гөлләр арасында
Өмет, хыялларның иң шәбе...
Һәр кешегә һәрчак җимеш биргән
Бизәктәге гөлләр җимшәне.

Еллар, юллар аша килеп җитеп,
Бәхетемә тигән көмешем
Ялтырамый,
Бары тик яктырта
Юлларымның авыр өлешен...

### 2. Итекләр

Җирне рәнҗетмәсен адымым дип,
Үкчәләргә шунда бал сыла —
Итек кисәң әгәр, барыбер бит
Җир өстенә каты басыла.

Итек матур булса, җир рәнҗемәс,
Дигәннәрдер безнең бабалар —
Кунычларга алар төшергәннәр
Тамчы гөлләр, кызыл алмалар.

Сәйраннарда бизәк нурын сипкән...
Ачылып киткәч низаг йозагы.
Җир рәнҗегән — итек бизәкләрен
Каплап киткән сугыш тузаны.

Аһ ул тузан!..
Кайбер капкаларга
Мөһер суккан дегет сыман ла —
Сикереп-сикереп биегәндә дә хәтта
Коелып калмый,
Ныграк сылана.

Тузанлымы, тузансызмы итек,
Бизәклеме, әллә гадиме —
Җиргә эзен сала, ә эзләрдә
Аяк түгел,
Тарих адымы.

### 3. Урыс капка

Татар йортларында урыс капка.
Җилне сизә киләсе —
Ачылырга гына тора, белә:
Дуслар гына керәсен.

Капкаларда безнең һич булмаган
Тешен ыржайткан җанвар.
Имән баганада имән кояш.
Шул кояшта ямь, җан бар.

Капкалардан безнең кергәндә үк
Урап ала җылылык...
Шәп капкалар күптер Җирдә, ләкин
Моңардан да чыны юк.

Татар йортларында урыс капка.
Сынаган аны вакыт.
Йомшак җил дә керә ала хәтта,
Ә кереп булмый ватып —
Кояшы җимерелә!..

## 4. Тәрәзә йөзлекләре

Тәрәзәләр — өйнең якты күзләре.
*Ш.Анак*

Пешерә кояш, җебетә яңгыр,
Куыра суык, каера давыл.
Ә йөзлекләрдә — канат җәйгән кош,
Курыкмый да ул,
Куркытмый да ул!

Сандугач та ул,
Күгәрчен дә ул,
Җир яралгысын тапкан үрдәк тә,
Беркатлы да ул,
Мәгънәле дә ул —
Башы барларга үзе бер мәктәп.

Тәрәзәләргә, безнең йөрәккә
Менә шундый кош оясын корды.
Хөррият сөйгән күңел символы —
Ул — һәр кешегә елмаеп торды.

Ә тәрәзәләр — өйнең күзләре,
Күзе яктының өмете якты...
Әлегә кадәр безнең тәрәзне
Күңеле якты кешеләр какты.

## 5. Беләзек

Бернинди дә бизәк булмас
Богау беләзегендә...

I

Беләкне беләзек буса,
Куллар нык була, диләр...
Авыр эшкә тотынганда
Беләзек кигән ирләр.

Ирләрнең беләзекләре —
Җитен йә киндер тасма...
Кулга ураган тасманың
Очына гына басма —

Кылычка тотындырырсың
Чалгы тотасы ирне.
Кылыч бизәсә дә кулны,
Ул кул бизәмәс Җирне.

II

Биле нәзек, биле нәзек,
Беләгендә беләзек...

*Татар халык җыры*

Кул бизәге беләзек лә,
Алтыннан һәм көмештән...
Кызларның бөтен гомере
«Бәлки»дән һәм «имеш»тән.

Көмеш беләзек тә безгә
Ярап тора әлегә,
Егетнең алтын куллысы
Кагылыр беләгемә.

Басты заман, басты дошман,
Басты тасма очына.
Кыз беләге түгел, кылыч
Ятты егет учына.

Яу кырында бүз егетнең
Алтын куллары талды...
Беләкләремдә нибары
Көмеш беләзек калды...

## 6. Хәнҗәр һәм сука

Сука буразналар ярган...
Хәнҗәр фетнәгә барган...
Сука мөгезен кара да
Хәнҗәр сабына кара.

Хәнҗәр хуҗасы исеме —
Көмештә алтын белән,
Ә сука хуҗасыныкын
Безнең кайсыбыз белә?!

Илләргә афәт китергән
Җирдәге һәрбер явыз
Тарихка мәгълүм. Аларны
Һәрчак истә тотабыз.

Йә, нәрсә дип аңлатырга
Тарихның шушы эшен?
Яшәтүчесен онытып,
Үтерүчесен кеше

Ихтирамлый төшә кебек...
Мин, бәлки, ялгышамдыр.
Хәнҗәрләр сабы — дәлилле,
Сука сабы, ышандыр!..

## 7. Калкан

Матурлыкның көч икәнен
Күптән белгән кешеләр...
Күзенә матурлык керсә,
Кулыннан кылыч төшәр
Дошманның, дип уйлаганнар,
Бизәгәннәр калканны...
Күзгә бизәк чалынамы
Күргәндә аккан канны?

Калкандагы бизәгенә
Кеше ышанган юкка —
Аны сөңге тишеп кергән,
Аны гөрзиләр сыткан.
Бизәген күргәч, куллардан
Гөрзи төшәрлек итеп,
Калканны түгел,
Җир йөзен
Бизисе икән ничек?..

## *Кыр уртасы*

Кыр уртасы...
Бар көчемә җырлап йөрим мин —
Ир уртасы.

Тавышымның болытларга җитүен тоям.
Болытлардан минем тавыш яңгыр коя.

Мин дым сулыйм,
Су сеңдерәм.
Мин үзем болыт.
Мин үзем әзер явып торырга
Яңгыр булып.

Шундый рәхәт! —
Күңелемә
Тула өмет тамчылары,
Гөрли шатлык дәрьялары —
Сүнә сагыш шәм-чырагы.

Тирә-юнь — иркен,
Тирә-юнь — ашлык,
Тирә-юнь — чиксез...

Кайдан алыйм
Халәтемне аңлатыр сүз?..

Кыр уртасы...
Ир уртасының менә кайда
Җир уртасы,
Җыр уртасы.

## *Әгәр шатлык җитешмәсә...*

Әгәр шатлык җитешмәсә
Һәм баса калса сагыш,
Аксакаллар киңәшен тот —
Кешеләр белән таныш.

Алай да разый булмасаң,
Син ысулны алыштыр —
Үзеңнең шәхесең белән
Кешеләрне таныштыр.

Санардай эшләрең булса,
Карап кеше күзенә,
Үзең белән таныштыру
Шатлык өстәр үзеңә.

* * *

Башны учка куйдырырлык гаҗәеп бер заман бу.
Миләргә өр-яңа сырлар уйдырырлык заман бу.

Тар күңелле кешеләргә сыя алмас заман бу.
Ә көрәшче йөрәкләргә таман килгән заман бу.

Күз — күкләрдә, күңел — җирдә. Каршылыклы заман бу.
Илләр илнең кулын кыса — шәп холыклы заман бу.

Кемдер әрли, кемдер мактый — бик тәэсирле заман бу.
Кешелекнең бик күп чире ачылып киткән заман бу.

Хөрлек, пакьлек пьедесталга менә торган заман бу.
Мылтык урманына кошлар оя корган заман бу.

Бер үк бизмән, бер үк метр һәм термометр биреп,
Галәм, Җир, йөрәк хакында кайгырттырган заман бу.

* * *

Дөньяны җил, суны дулкын,
Кешене сүз болгата...

*Татар халык җыры*

Кояш тыныч кына чыга
Һәм тыныч кына бата...

Кемдер кемгәдер «сөям» ди,
Кемдер кемгәдер ата.
Берәү гайбәт чәчеп йөри,
Икенчесе үстерә.
Берәү эт белән шаяра,
Икенчесе өстерә.
Ана кызга бармак яный,
Юмаган өчен битен.
Илләр бер-берсен куркыта,
Бармагын мылтык итеп.
«Көймә килә — эзе юк», — дип
Җырлыйбыз әле җырлар.
Эш кылабыз — һавада да,
Суларда да эзе бар...

Ә кояш тыныч чыга да,
Шулай ук тыныч бата...
Һаваны — җил, суны — дулкын,
Дөньяны ни болгата?

## Әйләнеш

Бар шатлыгын, бар кайгысын
Җир җилләргә сөйли икән,
Җилдән һава отып ала,
Ә һаваны без сулыйбыз:
Һәм көләбез,
Һәм елыйбыз...

Елаулар да,
Көлүләр дә
Кая китсен — сеңә җиргә,
Ә җир аны сөйли җилгә,
Җилдән һава отып ала...

## *Даимилек*

Йөрәгеңә наз тутырып бакканда да,
Күзләр зәңгәр.

Моңлы күлдәй мөлдерәшеп ятканда да,
Алар зәңгәр.

Янар таудай, нәфрәт уты атканда да,
Алар зәңгәр.

Өметсезлек томанына батканда да,
Алар зәңгәр.

Чишмә булып, илһам нуры акканда да,
Алар зәңгәр.

Мәңге-мәңге ачылмаска япканда да,
Күзләр зәңгәр!..

* * *

*Р.Ф.*

Мин Җир буйлап сәяхәттә:
Кичәм,
Үтәм,
Ашам...
Әллә исәнләшеп йөрим,
Әллә саубуллашам.
Сокланырга өлгерә алмыйм —
Йөрим бары санап.
Бер килеп чыгармын кебек
Булган җиргә кабат,
Кошлар әйләнеп кайткандай.
Аһ син, күңел, күңел...
Кош ел саен китә,
Кайта...
Кеше — алай түгел.

* * *

Яшен яшьнәп, күкләр күкрәп яуды кар...
Табигатьнең кәефендә нидер бар бит,
Нидер бар.

Әллә үпкә,
        Әллә ачу,
                Әллә соң...
Белмим, белмим... Аңсыз эшен
Аңлы кеше
Нәрсә диеп аңласын?!
Мөгаен, уятканбыздыр
Җенен, әллә алласын...

Яшен яшьнәп, күкләр күкрәп яуды кар...
Кешеләрнең кылганында нидер бар бит,
Нидер бар.

* * *

Бу тойгыдан да ләззәтлерәк ниндие бар?

Гомеремдә беренче тапкыр
Нигез ташы салам...
Җылы кулымны аласы килми салкын таштан —
Менә градусниктагы кызыл сызык кебек
Күтәрелер сыман
Утыз алты катлы кызыл дивар,
Йөрәгемнең сәламәт кайнарлыгын күрсәтеп...

Бу тойгыдан ләззәтлерәк ниндие бар?..

## Кышкы болыт

— Кышкы болыт кар бирмичә нәрсә бирсен?
Син аңардан башка әйбер өмет итмә...

— Алай димә... Бездән китеп, шул ук болыт
Язга чыккан кешеләргә ләйсән илтә.

## *Кочак тулы чәчәк*

Кочак тулы чәчәк.
Сарыларын җыймадым.
Өйдәгеләрнең һәммәсе
Шатлансын дип уйладым.

— Әни, менә сиңа агы.
— Чәчем ак булгангамы?
— Алайса... (Кызылын суздым.)
— Кызылга кызыгу узды.
— Күзең төслесен — зәңгәрен...
— Булдыра алсаң әгәр син,
Бир, улым, миңа яшелен.
— Яшел чәчәк буламыни?
— Яшеле шул яшьлегем!..

Кочак тулы чәчәк.
Сарыларын җыймадым,
Ә яшеле булмады.

## Ике тамчы

Икесе дә күк суы...
Күләдер язгы тамчы,
Елыйдыр күзгә тамчы.

Икесе дә җиргә сеңә...
Күләдер язгы тамчы,
Елыйдыр күзгә тамчы.

Нинди көннәрнең киләсен
Беләдер язгы тамчы...
Көләдер язгы тамчы...

Андый көннәрнең үтәсен
Уйлыйдыр күзгә тамчы...
Елыйдыр күзгә тамчы...

## *Хат көткәндә*

Борчылу, шәт, вакытсыздыр,
Килеп җитәр,
Алдадыр.
Шатлыктан мин ун хат яздым,
Бер җавап та алмадым.

Шатлыгымны уртаклашыр
Бер дус та калмаганмы?
Көннәр мине алдаганмы,
Еллар да алдаганмы?

Мин кайгырып бер хат яздым,
Йөз җавап килде кинәт.
Шатлыкка күз йомган дуслар
Кайгыга уяу, димәк.

* * *

Рәнҗетелгәннәр ярсымый.
Түземе беткән чиктә,
Биттән киткән алсулык күк,
Тотып үзләре китә.
Кырны бодай ташлап китә,
Җырны ташлап китә көй.
Нигез ташын рәнҗеткәнне
Ташлап китеп бара өй...
Сөеклеләр китеп бара,
Ташлап китә туганнар.
Китә безнең битне, кулны
Тәүге тапкыр юганнар.
Рәнҗетүче берни сизми...
Ә менә ахыр чиктә
Рәнҗетүчене үзенең
Йөрәге ташлап китә...

## *Ияр һәм тәхет*

Борын-борын заманнарда
Патша һәм җирән Чичән
Ияр һәм тәхет турында
Бәхәсләшәләр икән.

Чичән әйткән:
— И падиша,
Күпне белдем, күп йөрдем,
Тәхетләрнең иярдән мин
Бер аермасын күрмим.

Туры сүзем өчен, белмим,
Ни котә: чапан, ләхет? —
Тәхет ил өстендә ияр,
Ияр җайдакка тәхет.

Патша әйткән:
— Чичән, Чичән,
Ерымны сай ерасың.
Тәхеткә утырып кара,
Күрерсең аермасын.

Тәхет менеп, Чичән әйткән:
— Аермасы бар икән —
Ияр атны дәүләт итә,
Тәхет илне ат итә...

* * *

Башлаган эш — беткән эш дип,
Тикмәгә әйтми картлар.
Күрәсең, иң бәхетле чак —
Эшне башлаган чаклар.

Күз алларыңа килә дә,
«Саламы җыйган» килеш,
Ләззәт бирә
Өйгә, көйгә,
Юлга әверелгән эш.

Син биектә, рухың уйный,
Күзеңнән шатлык оча...
Бу синең бәхетле чагың—
Ялгышсыз, хатасыз чак.

* * *

Балыксыз күлдә
Төнге тынлык.
Янган урманда
Төнге тынлык.

— Төнге тынлык,
Син ник дымлы?
Төнге тынлык,
Син ник моңлы?

Төнге тынлык:
— Җирне тыңлыйм —
Моңланмыйча
Һич тә булмый.

Ният кулга
Бик тиз җитә,
Аңыгызга
Никтер соңлый...

* * *

Өйгә җил генә кертсә дә тәрәзә,
Ачылганда пыяласын зыңлатып куя —
Ишетсен дөнья,
Белсен безнең кем икәнне!

Өйгә кунак кына кертсә дә ишек,
Ачылганда keләсен бер чыңлатып куя —
Ишетсен дөнья,
Белсен безнең кем икәнне!

Каршысында олау гына торса да, капка
Ачылганда тупсаларын җырлатып куя —
Ишетсен дөнья,
Белсен безнең кем икәнне!

Дөнья кадәр дөнья алдында күз ачыла,
Ник кенә бер тавышы чыксын!..

## Әбиләребезнең берсе

Күлмәгеннән чыгып качармыни
Нәни тән —
        кыршау,
                кыршау,
                        кыршау!..

Караңгы өй...
        Өй эчендә
                камаган аны чаршау.

Ак тәнендә татлы яңалык —
        балигълык
                тыпырчына ятьмә күзенә
                        саңагы эләккән
Көмеш балык булып...

Чаршау эчендә инде чыбылдык!..

Кызыл мәрҗәнле ак муенына
Чап-чал сакал чар булган...
Беләзеге белән
Тәрәзәнең бәсен кырып,
Янган йөрәгенә кар уган...
        Өй,
            өй эчендә чаршау,
                чаршау эчендә чыбылдык,
Чыбылдык эчендә... чардуган.

* * *

Дым әйткән, ди, улына:
— Һичкайчан томан була
Күрмә — нахакка каргалырсың.

Дым әйткән, ди, улына:
— Кар бөртеге юлыннан
Йөрмә — файдасыз тапталырсың.

Дым әйткән, ди, улына:
— Яңгыр тамчысы юлына
Кермә — тамарсың, тапланырсың.

Улы әйткән, ди, Дымга:
— Су дигән исемемне
Мин ничек акლармын соң?

* * *

Бөтен нәрсә — гади...
Тәрәзләргә әнә тузан кунган —
Исәбе, күрәсең, күккә ашу булган.

Җир астында
Тамыр сулый —
Тирәнгә таба һаваның юлы.

Өстәге — аска,
Астагы — өскә ашкына никтер...
Шуны аңлап булмый.

## *Озатканда*

Без җырлашып аерылабыз.
Өйдән җырлап китәсең.
Күңелеңдә җыр сау булса,
Максатыңа җитәрсең.

Күңелеңдә җыр сау булса,
Кайда да үз итәрләр.
Җырың үлсә, күңелеңне
Ятлар мәхбүс итәрләр.

Җырны тарат, син юмарт бул,
Ләкин аны туздырма...
Җырлап чыгып киткән йортка
Җылап кайтырлык булма!

## *Казанда яз*

Казан урамында хатыннар күп,
Казан урамында агачлар аз.
Шуңа сине агачларга түгел,
Хатыннарга карап күрәмен, яз!

Алар әнә урам тулып йөри,
Әнә алар пальтоларын салган...
Бәби табар вакытларына да
Бер-ике-өч атналары калган.

## *Сезнең исем*

Кая барсам да,
Яңа танышлар
Минем аша сезгә, дуслар,
Сәлам әйтә.
Нинди әйбәт!

Яшәгез, яшә, дусларым,
Сезнең хакта беркайчан да,
Беркемнән дә
Ишетмәдем кара гайбәт.

Киләсе көннәр,
Нарат урманында,
Диңгез ярында алган сулу кебек,
Җиңел булыр!
Киләм сынап —
Сезнең исем
Җирдә дуслар арттыра торган
Тылсым сымак.

## Өч тәрәз

Иртәнге өч...
Төне буе
Өч тәрәздә утлар сүнмәде.

Бер тәрәздә
Кызыл табут торды.

Бер тәрәздә
Яшь киленнең ак туй күлмәге.

Бер тәрәздә
Беркем күренмәде,
Төне буе беркем күренмәде.
Ә ут сүнмәде...

Бер тәрәзнең пәрдәсен ябасы килде,
Икенчесен
Тутырып ачасы килде,
Өченчесе аша менә керәсе килде.
Креслога утырган килеш йоклап киткән
Бер сылуны күрәсе килде...

Иртәнге өч...

* * *

Күңелемдә кайчак гаҗәеп сурәт була,
Күзләремнән ташып чыгып,
Тирә-юньгә тула.
Гадәттә, ул язгы урман була.
Ә мин көзне яратам.
Әкияттәге тылсымчы күк,
Ул урманны әкрен генә саргайтам,
Сөеклем белән кавышкандагыча итәм,
Таныш сукмак буйлап китәм,
Баксам — берүзем икән.
Һәм күңелне кинәт көзге моң баса...
Юып ташлыйм бу сурәтне мин тизрәк...
Күз алдымда
Фасылларга бирешми торган гөлле тәрәз,
Таш урамнар,
Ыгы-зыгы тулы таш Казан...

## *Куера бара*

Зәңгәрлекнең ике очы да — кара.
Менгән саен зәңгәр һава
Карага таба куера бара.
Төшкән саен зәңгәр сулар
Карага таба куера бара.
Үткән саен зәңгәр яшьлек тә
        Куера бара,
        Куера бара,
        Куера бара...
Кеше барыбер җырлап бара,
        Җырлап бара!

## Җыр

*Илһамга*

Мин җыр тыңлыйм... күңелемне минем
Айкый-чайкый җырның агышы.
Уйлыйм:
Ничек җырга әйләнгән соң
Кешеләрнең гади тавышы?

Йөрәгемә һаман тула бара
Ил-халыкның моңы-сагышы.
Шуны, ахры, үлмәс итәр өчен
Җырга әйләнгән
Кеше тавышы.

Җыр китерде минем йөрәгемә
Зур өметләр канат кагышын.
Шул өметләр мәңге сүнмәсен дип,
Җырга әйләнгән
Кеше тавышы.

Ялгыз теләк белән күмәк теләк...
Ялгыз ук һәм садак — чагыштыр.
Ялгыз теләк күмәк булсын өчен
Җырга әйләнгән
Кеше тавышы.

## *Карга бураны*

Карлар оча, карга оча.
Ак һәм кара җирең-күгең...
Март ахырлары бураны —
Буран да, буран да түгел.

Туңдырырлык салкыны юк,
Юк эретерлек җылысы...
Кайчак күздән яшь агыза,
Килмәгәндә дә җылыйсы.

Һәммәсе куба урыннан:
Шатлыкларың, кайгыларың,
Өметләрең, шөбһәләрең—
Кайсы карга, кайсы кары...

Болганалар, чолганалар
Шушы гаҗәп буран кебек.
Апрель ташкыннарын көткән
Күңелләрне сәерсетеп.

* * *

Һәр көзнең моңы бар, көе бар...
Өзелгән яфраклар
Гармун бармакларын баса алса,
Дымлы җилнең булса
Гармун күреген тартырлык көче,
Бер генә моң,
Бер генә көй яңгырар иде
Бөтен нәрсә өчен.
Бөтен нәрсә
Бер генә көйгә җырлар иде...
Ярый әле
Өзелгән яфракларның
Гармун бармакларын басарлык
Көче калмый.
Ярый әле
Дымлы җилләр
Гармун күреген тарта алмый...

## *Кычыткан*

Данда, санда, горурлыкта
Күп асыл гөлне откан
Үткер тел кебек яфраклы
Уктай туры кычыткан.

Үсемлекләр арасында
Ул — усал даһи сыман.
Тимәсәң — тими, ә тисәң...
Анысын үзең сына.

Әзер түгел, вакыты юк,
Ялгыз чакта да — егет.
Үсемлек мәмләкәтендә
Ул — чик сакчысы кебек.

Чага икән — димәк, тиеш,
Ул сиңа сабак бирә.
Барганга йә карамыйча,
Йә ярамаган җиргә...

Әрсезлектә, чыдамлыкта
Күп егетләрне откан
Үткер тел кебек яфраклы,
Уктай туры кычыткан!

## *Күздән яшь сыкканнан соң...*

Килде болыт,
Турсаеп,
Каш җыерып,
Йомшарды да
                яңгыр булып коелды.
Әйтерсең лә күздән яшь сыкканнан соң
Ачу китте,
Йөзгә шәфкать җыелды...

* * *

Еллар узган саен,
үкенечләр арта...
Күпме матур ният
эшкә ашмый калган!
Күрәсең, зирәклек
җитеп үк бетмәгән —
Кылыч буласы да,
булынган тик калкан.

Акыл арткан саен,
ысуллар да арта,
Юллар арта бара,
тик җай кабатланмый...
Кайгыларга каршы
көрәшеп тузабыз,
Үкенечкә каршы —
дәрт-дәрман калмый.
Вакыт та калмый...

* * *

Үпкәлим дә юлга җыенам,
Ләкин чыкмыйм...
Елга булырга теләгән
Таңгы чык мин.

Елмайсагыз — кояш чыга,
Үпкәм бетә.
Сезне ташлау ниятләрем
Үтеп китә.

Уйлап куям: елга булып
Кая таба
Агар идем? Елга кайда
Бәхет таба?..

Һәр көн иртән юлга җыенам,
Ләкин чыкмыйм...
Мин бары чык... Мин җыенам...
Барып чыкмый.

* * *

Аякны гына
Чага елан —
Елан янына
Баш егыла...

### *Зөя ярые*

Сөзәк ярны, юаш ярны
Кар күмгәнне кем күрмәгән,
Кем белмәгән?!

Ә текә яр, ә усал яр
Беркайчан да күмелмәгән!

* * *

Артка карап алга кача
качак.
Алга карап артка чаба
куркак...
Ике якка төбәлсә дә
сукмаклары,
Юл башлары, максатлары
уртак.

* * *

Син ничек яшисең?
Дусың кем? Дошманың?
Ник дәшмисең?

Яшисең син ничек?
Күрмимен күзеңдә
Ни чаткы, ни чык.

Эндәшмәде...
«Яшәде»...
Тфү!..

## *Киткәннән соң...*

Яңгырдан соң,
Бар табигать рәхәтләнеп,
Күкрәк киереп
Сулу ала.

Агым су
Киткән юлына,
Ашлыкларга аш булырдай,
Ләм сала.

Кешедән,
Оныгы онык күргәнче,
Матча башы күгәрмәслек
Өй кала!

* * *

Бураннарга каршы басып тора.
Ач кочагың һәм җый хәзинә!

Карны себереп-себереп җил исә...

Алдын күрүчеләр: «Фәкыйрь!» — дияр,
Ә артында аның көрт үсә.

## *Кем алданрак!*

Кем алданрак күрә таңны,
Кешеме әллә таумы?

Тәүлек таңы гына булса,
Алданрак тау яктыра.

Яңа дәвер таңы туса,
Кеше сәламли: «Саумы!»

## *Вакыт ага*

Минем аша
Вакыт ага.
Дулкыны кага.
Кая таба ага Вакыт? Дулкын кая чаба?

Чәчләремдә — карадан акка,
Мәхәббәттә — җөптән такка,
Йөрәгемдә — туфракка таба ла,
аһ, туфракка таба...

## *Көзге*

Һәрвакыт кеше
Берәр нәрсәгә охшаш:
Елмайганда — калачка,
Елаганда — болытка,
Җырлаганда — җилгә,
Кайвакытта хәтта берәр илгә,
Ел фасылына, чорга...
Шуңа күрә бар нәрсәне — җанлыны, җансызны —
Кеше белән чагыштырып була.
Кеше йөзе — иң бөек көзге,
Һәм табигать кеше йөзендә
Үзенең хаталанганын да күрә,
Уңышларга ирешкәнен дә.

## Кайтавазлар кайта

Яфраклар этәрде:
        Бар, кайт!
Күк гөмбәзе гүләде:
        Бар, кайт!
Кыя тибәрде:
        Бар, кайт!
Елга сузды:
        Бар, кайт!
        Бар, әйт!
        Айт, айт!
Үзе тудырган тере аваз
Әйләнеп кайтты кешегә,
Үле яңгыраш булып,
Үле яңгыраш.
Һәрвакыттагыча...
Көрәш!..

* * *

Озындырмы, кыскадырмы үткән юлым,
Һич бәхәссез, чамама ул минем таман —
Саубуллашкан дусларымның кул җылысын
Каршылаган дусларыма җиткералсам.

Мин сәламнәр ала китәм, һәм аларны
Әлегәчә югалтмадым һәм югалтмам...
Озындырмы, кыскадырмы үткән юлым —
Кайчагында артып кала кайбер сәлам.

Озындырмы, кыскадырмы... Каян белим...
Үзең сана, үзең үлчә, үзең кара —
Сәлам юллап калучылар һаман арта,
Сәлам кабул итүчеләр кими бара.

## *Көз килү*

Үткән юлына сары яфрак элә-элә,
Көз килә.
Өченче көнерактагы урманда иде,
Кичә — безнең урамда.
Бүген — тәрәз каршындагы юкәгә кунган.
Дерелдәп тора.
Күрәсең, туңган.
Кызыгып,
Хәтта ачкүзләнеп,
Өстәлемдәге гөлләремә
Тәрәзә аша карап тора...
Мин
Шул гөлләрдән бераз гына
Арырак утырам...

* * *

Мин балконга чыгам да
Кочаклап алам нарат башын...
Болан үгезенең
Мөгез араларын кашыган күк,
Ботак араларын кашыйм.
Әллә кытыкланып,
Әллә ләззәтләнеп,
Әллә җилдән
Тетрәнеп куя нарат...
Башка әллә нинди уйлар килә,
Мөгердәргә җыенган наратка карап...

* * *

Юл тузанында
Һәммәбездән эз кала.

Ил юлына
Сирәгебез эз сала.

Җир тарихы
Сирәкли илләр юлын...

Ә кеше кала бирә
Барлык юл башы булып!..

* * *

Ир уртасы кешеләргә
Таяна дөнья һәрчак —
Аек акыл, ул кушканны
Башкарырлык көч бар чак.

Картлардан киңәш ала ул,
Яшьләрдән өйрәнә ул.
Шуңа күрә дә биектә,
Шуңа да тирәндә ул.

Тотса — кулы ычкындырмый,
Басса — аягы таймый.
Шуңа да, күрәсең, дөнья
Аның җилкәсен сайлый...

## *Шавы миндә үлмәс кайтавалдай*

Шавы миндә үлмәс кайтаваздай.
Дулкыннарын ярып уйнадым.
Акчарлаклар көтүенә кушылып,
Әллә кая китте уйларым.

Сыек гәрәбә күк алтынланган
Тыныч киңлекләрне үтте дә,
Беркайчан да безгә килми торган
Давылларны куып җитте дә,
Давыл белән дулкын арасында
Бөтерелде — үзен сынады...
Канатының иңе артып кайтты,
Акылыма минем сыймады.

Яңа тойгылардан мин, диңгездән
Туймагандай, мәңге туймамын —
Ап-ак акчарлаклар булып китә,
Давыл булып кайта уйларым.

* * *

Төссез уйны — күккә атам.
Зәңгәр уем — суда ага.
Кара уем — җирдә ята.
Ә ак уем — чәчәк ата.

Төссез уйдан томан калка,
Зәңгәр — хисләрне яңарта,
Кара уем җирдә ята,
Ә ак уем чәчәк ата.

Төссез уйны җил тарата.
Зәңгәре — яшьлеккә тарта.
Кара уйны сез таптыйсыз.
Ә ак уем чәчәк ата.

Ак уй, дуслар, сезнең хакта.

## *Әйт син, баш!*

Күзләр — күлләр,
Ә инде каш
Күл камышына охшаш.

Ник каш ауган,
Ник күздә яшь?
Әйт син, баш!

* * *

Нигә син, яңгыр, күзләремә качтың —
Күзем сине җирдән дә нык көтәмени?

Нигә син, яшен, сүзләремә качтың —
Миннән кеше сине өмет итәмени?

* * *

Бар ваклыклар калды Иделдә.
Диңгез тулды хәзер күңелгә.

Ак балыклар уйный төбендә,
Акчарлаклар оча күгендә.

Анда инде зәңгәр упкын бар,
Кораб чайкалтырлык дулкыннар.

Бик авыртып күңел киңәйде —
Озак сызлар әле, сулкылдар.

* * *

Кара гына урман,
Зәңгәр генә диңгез!
Куәтегез тигез,
Тавышыгыз игез,
Нигә шаулыйсыз сез?
Нәрсә эзлисез сез?

Кара гынай урман,
Зәңгәр генәй диңгез!
Икегез дә ни сез,
Икегез дә ни сез?
Минем шатлыкмы сез?
Минем сагышмы сез?

Минем күңелемнән
Чыккан тавышмы сез?

Минем йөрәк белән,
Минем теләк белән
Күптән танышмы сез,
Күптән танышмы сез?

* * *

Күптән түгел тып-тын иде,
Хәзер дулкын чаба буй-буй...
Бер диңгезгә карап торып,
Башка килә мең дә бер уй.
Бик күбесен мин аларның
Хәтеремә язып куйдым.
Күрәсең, комга язганмын —
Дулкын юды. Җуйдым, җуйдым.
Калганнарын алып кайтам
Дусларыма, ишләремә —
Көч бирмәсә, терәк булыр
Нияттәге эшләренә.
Дошманнарга алып кайтам —
Теләсәләр бәйләнерләр.
Хаклык җиңәр — уйларымның
Юлдашына әйләнерләр.
Алып кайтам беркайчан да
Белешмәгән җиде ятка —
Уем аша танышырбыз,
Таныш артыр җиде якта —
Улыма да, кызыма да
Уем — киңәш, уем — теләк...
Сөяклемә кайтам үзем,
Аңа үзем иң зур бүләк.
Күптән түгел бик вак иде,
Дулкын хәзер нинди үсте!..
Диңгез, диңгез! Хисләргә уй,
Уйларыма ул хис өсти.

## *Конфет, алма, чәчәк*

*Саласпилс концлагеренда фашистлар*
*җиде мең баланы ачтан үтергәннәр.*
*Сабыйларның күбесе имчәк баласы булган.*

Сезгә
        бездән
                чәчәк,
Йөз мең корбан.
Тере чәчәк сезне терелтсен
Безнең хәтерләрдә.
Хатыннарны ана итсен,
Ирне ир итсен.

Сезгә
        бездән
                чәчәк,
Олы ирләр.
Сез тормышның чәчәк икәнен
Белә генә башлаган булгансыз...
Сизәм сезгә чәчәк җитмәвен.

Сезгә
        бездән
                нәрсә,
Җиде мең бала?
Кайсыгыз имчәк көткән, кайсыгыз
Яңа гына ачылган тел белән
Конфет сорагандыр кайгысыз...

Яныгызга килгән
            һәрбер ана
Әзер сезгә күкрәк бирергә.
Хатирәгез булып калыккан таш
Имә белми.
Шуңа биредә

Сезгә
        бездән
                конфет,
Җиде мең сабый,
Шоколадлар сезгә, балалар.
Нәни курчак,
Соска ташыгызда,
Ә янында кызыл алмалар...

* * *

Суыгызны беләм —
Суыгызны эчтем.
Җирегезне беләм —
Аның аша кичтем.
Һавагызны беләм —
Мин аны суладым.
Халкыгызны беләм —
Йөрәген тыңладым.
Бер кыз күкрәгеннән,
Бер егет җырыннан,
Бер карчык рәхмәтеннән,
Бер карт киңәшеннән.

## *Акчарлаклар*

Аермасы аз икән бит
Зурлык, аклык ягыннан
Елга акчарлакларының
Диңгез акчарлагыннан.

Икесе дә давылларны
Алдан, ерактан сизә.
Кайнап, кыйнап давыл үтә,
Ә акчарлаклар исән.

Икесе дә кунмый икән
Дулкынның зурысына.
Икесенең дә канаты
Ярга бәрелсә сына.

Аермасы аз булса да
Зурлык, аклык ягыннан
Елга акчарлакларының
Диңгез акчарлагыннан,

Аермасы бар икән шул,
Аермасы бар икән —
Берсенә бер яр, берсенә
Ике кысан яр икән.

## Балыкта

Кичә шулай җыендым да
Балыкка диеп чыктым...
Кояш балкый,
Балык уйный,
Күл өсте уртада тын,
Ә ярда зур-зур дулкыннар
Калкавычны кыйнады.
Бу — гайре табигый диеп,
Әлләниләр уйладым.
Тирән урында дулкыннар
Тирәнгә посып бара.
Сайга килеп чыккач кына
Үкерә дә чалара...
Нәкъ күңелдәге дулкын кук,
Эчтән килә дә дулап,
Кулга кереп йодрык була,
Тел очында сүз була...

Ул көн минем шундый булды —
Күл чиста,
Ярда дулкын.

Сезгә ничектер,
Миңа — үз
«Гайре табигый» ул көн.

* * *

Диңгез — ярсыган ат кебек,
Аның өсте ак күбек.
Җайдагына баш бирмәгән,
Калдырган аны тибеп.
    Китсән,
        Китсән,
            Китсән,
                Китсән,
Белми кая китәсен.
    Чапкан,
        Чапкан,
            Чапкан,
                Чапкан,
Белми ярга җитәсен.
Ярны таптап үтмәк була —
Дулкынын ата тау-тау.
Дулкын ярга чыгып үлә,
Сеңеп сүнә олы шау.
Диңгез арыган ат сымак,
Өстендә вак-вак күбек,
Дулый белми дулаганга
Сыкрый, үкенә кебек.

* * *

Егет диңгездән йөгереп чыкты.
Ай яктысы чәченнән тама.
Караңгыда кыз тавышы:
— Кочагың юеш —
Кочаклама.
Караңгыда кыз тавышы:
— Кочагың салкын —
Кочаклама...

Шулай диеп бер-берсенә
Кеше ничек әйтә ала?!
Кара, нинди шыксыз сүзләр:
«Кочагың салкын —
Кочаклама...»

## Вакытсыз яңгыр турында хәбәр

Татарстанда ашлык пешкән,
Тик яңгыр кыйный икән.
Диңгез сыйган бу йөрәккә
Шул яңгыр сыймый икән.

Дулкын кереп актарганда
Эһ тә итмәгән идем,
Пешкән бодайларга төшкән
Тамчы йөрәккә тиде.

Бер куырды, бер туңдырды,
Бер телгәләде вак-вак...
Балтыйк дип чумам, Иделдә
Яуган яңгырга батам...

* * *

*В.Кузнецовка*

Якты дөньяга чыктык без,
Калкып ныклы тамырдан,
Бирәсене бирер өчен,
Аласын да алырга.

Ни бирдек без?
Шигырь бирдек,
Китап бирдек,
Җыр бирдек!
Чор булмаса, кайбер көннәр
Шул җырны җырлап йөрде.

Ни алдык без?
Бик күп алдык,
Күңел мохтаҗ булмады.
Берни югында, ичмасам,
Саф һавасын суладык.

Алган күпме?
Биргән күпме?
Әллә тигезме алар?
Саннарга гашыйк чорыбыз
Тиешле тапса —
Санар...

## Тормыш

*Кызыма һәм улыма*

Ни дисәк тә, тормышыбыз
Диңгездәй — иркен, тирән...
Колачлыйм һәм буйлыйм дисәң,
Тын җиткерергә өйрән.

Гүзәллеге — киңлегендә,
Ә асылы — тирәндә.
Тирәнгәрәк чумып кал син,
Кичәргә көч биргәндә.

Ләкин онытма, тирәндә
Кинәт тының бетмәсен.
Яшәү дигән сәяхәтне
Әле дәвам итәсең

Бар бит ерак ярга чаклы.
Ә тын бетсә, бетә юл.
Ярты юл ул — ярты гомер,
Ярты ярты инде ул...

Ни дисәк тә, тормышыбыз
Нәкъ диңгез — иркен, тирән.
Безнең яшәү — бары бер тын.
Тын җиткерергә өйрән!

## *Килешми, ярамый*

Диңгезгә дулкынсыз килешми дә, ярамый да —
Күлгә охшап кала.

Чүлгә эссесез килешми дә, ярамый да —
Даны-шаны югала.

Урманга җилсез килешми дә, ярамый да —
Сурәт кыяфәтен ала...

Кешегә мәхәббәтсез килешми дә, ярамый да —
Кайгыдан да, шатлыктан да уала.

* * *

Көзнең яфраклары сукмакларда...
Кайсылары икән, кайсылары,
Җәйге таңда чыклар җыя-җыя,
Сандугачны сугарган?..
Яфрак яфрак инде —
Төшкән — беткән...
Кайсылары соң, белмим, кайсылары,
Җәйге таңда чыклар җыя-җыя,
Сандугачны сугарган?
Мин аларны таптап атлап барам...
Бик уңайсыз миңа,
Бик уңайсыз,
Бик уңайсыз миңа шулардан.

* * *

Кырык вагон урман үтеп китте...
Нарат исе
Басып китте мазут исен.
Поезд шавын басып китте
Урман кисүчегә булган
Нәфрәт хисем...

Җылы, якты, яңа өйдә утырам.
Нарат исе...
Кемгә рәхмәт әйтим?
Кем кисте?

* * *

Беребез-бер Айга аяк басмадык,
Ай турынданиләр генә язмадык!..

Ул — асыл таш, нур йомгагы, ул — көмеш...
Колак алка иттек аны Ай килеш.

Хәзер инде Айда шигырь язылды.
Йә, шуннан соң элеккечә яз инде!

* * *

Кемдер теләктәшлек көтә,
Кемдер фатиха көтә...
Кайчак зур эш башланырга
Бер кечкенә сүз җитә.

Ул сүз нинди? Һәм кем сүзе?
Һәм ничек итеп әйтә?
Ышанычлы итеп әйтсә —
Хәлләрне җиңеләйтә.

Яшимен «минем сүзләрем
Нинди?» дигән уй белән.
Беләм:
Шигырь — ил исеменнән
Кешегә теләк теләү!..

## *Диңгез, урман, шагыйрь*

Каным тыныч, иркен ага,
Бушка ярсымый йөрәк —
Диңгездә мин тынычландым,
Давыллар күрә-күрә.
Урман шавына охшаган
Икән бит диңгез шавы.
Әйтәм, урман тели идем,
Сизгәч тышау йомшавын.
Китеп урманга, шаулаган
Һавасын сулый идем,
Һәрбер агачка кушылып,
Туйганчы дулый идем.
Кайта идем бар ярсуны
Урманнарга таратып.
Минем өчен озак шаулый
Иде имән, нараты...
Инде китәм мин диңгездән.
Күңел тыныч, ният пакь...
Диңгез шаулар минем өчен,
Дулкынланыр бик озак.
Игезәк дип әйтеп булмас,
Ахры, бик якын туган
Дулкынланып рәхәтләнгән
Диңгез,
Шагыйрь
Һәм урман.

* * *

Тигез юлда син бер сикәлтәме? —
Тынган күңел кинәт тетрәде.
Нидер булды минем йөрәгемә —
кысан инде аңа күкрәгем.

Салкын кырда җылы җилме әллә? —
Туңган хисләр эри башлады...
Кинәт килгән ташкыннарда акты
йөрәгемә тулган ташларым.

Кара төндә якты тәрәзәме? —
Ымсындыра мине, чакыра.
Нәрсә булыр әгәр аны каксам?..
Ә акылым никтер сак тора...

Уем көртләренә баткан килеш
әй тартылам якын языма!..
Канат та бар, ләкин очмый торып,
ышанычы беткән аз гына...

* * *

Кар иде бугай...
Балкый иде Ай...
Шундый эссе иде миңа, шундый якты —
карлы кырга да,
миңа да син
кояш булып бактың...
Тирә-юньдә барлык үсемлек чәчәк атты.
Хәтерлимен — иелеп өздем...
Хәтерлимен — гөләп тездем,
сиңа суздым —
барысын алдың...
Җирнең кайсы төше иде бу,
елның кайсы фасылы —
аңламый калдым.

## *Салыйм әле балдагымны...*

— Салыйм әле балдагымны...
Ул — язмышым шаһиты.
Кайчак шундый кысып ала —
йөрәк куя аһ итеп.
Мондый теләкнең йөрәктә
кабынганы юк иде,
әле беркемнең дә синдәй
кагылганы юк иде...

— Салма, салма балдагыңны,
салсаң, җаның үзгәрә —
балдак астындагы тәнең
ачылыр ят күзләргә...

* * *

Син — иң куркыныч табышым,
шартламый калган минам!
Мин шулай да бәхетлемен —
тап булдың ич син миңа.

Мин күтәреп барам сине
үз язмышым буйлата.
Алдыбызда гомер кебек
сикәлтәле юл ята.

Абынам да, терәк итеп,
һаман сиңа ябышам.
Ә мәхәббәт, сапер кебек,
гомергә бер ялгыша.

* * *

Ләйсән генәдер бу дигән идем...
Юк, ялгыштым,—
минем йөрәккә
циклон керде...
Өермәләренә
ияртте дә нидер өйрәтә.

Яманаты чыккан бу давылны
кабул итте күңел.
Яшәтә
ашыкмаучан гомер агышы һәм
дөнья гаме белән янәшә.

Ерылдылар канда күп буалар...
Раска чыкты җанда гөманнар...
Ләззәт белән ләгънәт бәрелеште
елый алмый торган томанда...

Матурлыкны күмгән юшкыннар да
сыдырылып кубып төштеләр...
Ирексездән җанга циклон керттем,
ничек саклыйм аны, кешеләр?

* * *

...Озак нидер сөйләштеләр.
Сөйләшүләрне бүлеп,
егет кызны, кыз егетне
йөз тапкыр алды үбеп.

Сеңеп бетеп кочыштылар —
әйтерсең Җир шарында
алар фәкать икәү генә
Зәмзәм суы ярында.

Болытка болыт бәрелгәч
чатнаган кебек яшен,
араларында чәчрәде
салкын утлы күз яше.

Егет кызның күз төпләрен
ирене белән сөртте.
Кыз тетрәнгән егетне
чәч буранына кертте.

...Озак нидер сөйләштеләр
кузгалырга да базмый...
Шулай, нужарып, бер бәхет
төенли иде язмыш.

## *Шәһәрара телефон станциясендә*

Беренче кабина:
— Алло? Алло! Уфамы бу?.. Нәрсә?..
Мәскәү?..

Икенче кабина:
— ... менә шулай — полный катушка!
Җәлләмәскә!..

Өченче кабина:
— ...илле генә сум булса да... Шунсыз
бетәм...

Дүртенче кабина:
— ...аңладым. Көтәм...

Бишенче кабина:
— Киңәшәсе бар, җен алгыры, үзе белән...

Алтынчы кабина:
— ...сеңелкәем, өйдә булмаса, күр чарасын —
зинһар, тоташтыр... Һич югында эзе белән...

## Бүгеннән

...Юк, беләсем килми үткәнеңне —
сүнгән йолдыз, узган давылны.
Синең өчен бүген нәрсә туды,
сиңа бүген нәрсә табылды?

Сиңа бүген кояш ничек булды?
Ай яктысы нәрсә сөйләде?
Сине бүген тынлык ничек кочты?
Җилләр сиңа нәрсә теләде?

Үткәнеңне һич беләсем килми —
янган, очкан, тамган, түгелгән...
Матур булса бүген дөнья — димәк,
язмышыңда мин бар бүгеннән...

* * *

Дантега ияреп,
җәһәннәмне күреп кайтып була...

Гете ярдәмендә
бәхетле мизгелне туктатып карап була...

Хәйямга кушылып,
туфракка һәм яңадан кешегә әйләнеп була...

Тукай кошына тотынып,
дөнья читлегеннән очып чыгып була...

Ә җәннәт ишеген ачышучы бер генә кеше
бар —
сөйгән яр!

## *Сөяргә икән...*

Син — үле җанны да терелтерлек назга
иясеңдер;
син — теләсәң кайчан, Антей җиргә тиеп
алган кебек,
сузылып Язга
тиясеңдер;
сиңа көзгә керү дә, кышны күрү дә
яттыр;
син — мәңгелек Җәйгә чыккан
заттыр;
син — аллалар кебек, бәлки,
үлемсездер;
без — фанилар мәхәббәтен тою сиңа, бәлки,
күңелсездер;
ә шулай да девиз безнең:
урларга икән — бер генә шигырь булса да
тудырырлык
тылсым,
сөяргә икән —
үлемсезне!

* * *

Син, гүзәл тылсымчы сыман,
мине уйлап чыгардың.
Тиңсез горур кыя иттең —
туфаннарга чыдарлык.

Син мине болытың иттең —
ап-ак булып агылдым.
Син мине Кояшың иттең —
хәтта күзең чагылды...

Син чөйдең мине йолдызлар,
аллалар арасына —
бәхет тисен диең бугай
бу адәм баласына.

Син мине күктән эзләдең...
Ә мин монда, түбәнтен...
Синең эз калган сукмакны
ауный-ауный үбәмен.

* * *

Син бит минем күзләремдә
тамчы-яшь булып яшәүче
бердәнбер гүзәл затсың.

Синең ярдәмеңдә
керфекләрем канат булып кагыналар,
авыртмыйча, тырналмыйча, сизелмичә
ачыла күзләрем.
Шыгырдамый әйләнәләр күчәрләрендә,
галәмдә әйләнгәндәй Җир шарыбыз.

Синең аша мин дөньяны матур күрәм!
Синең аша мин тормышны чиста күрәм!
Яшәү миңа бик тә кадерле!

Ә үзеңне күргәч,
күзләремнән ташып чыгасың да
тамасың син куаныч диңгеземә...

* * *

Җәеп сал чәчеңне
син яшел чирәмгә,
тартып ал да мине
үзеңнән җибәрмә.

Ак болыт шәүләсе
күзеңдә чагылсын
һәм минем күзгә дә
чагылып кагылсын.

Ак болыт аларыр,
ул эрер, таралыр,
куерыр зәңгәр күк,
куерыр, каралыр.

Чыгар Ай мөлдерәп,
түгелми-чәчелми...
Шулчак мин чирәмнән
җыярмын чәчеңне.

## *Кыргый кыз*

Үзе — ялкын,
Үзе — боз...
Кырын-кырын карап ала
Кыргый күзле
Кыргый кыз.

Башкаларны һич югында
Без күз белән назлыйбыз.
Кая кулны,
Күз карашын да тидертми
Кыргый кыз.

Сөзеп караса, күзенә
Сыя Ай һәм бар йолдыз...
Тик мине генә күзенә
Һич сыйдырмый
Кыргый кыз.

Йөрәгемдә минем яра.
Яра аша эчкә уз!
Үзе — ялкын,
Үзе — боз,
Яралаганын да сизә,
Дәваламый ничек түзә?
Кырын-кырын карап ала
Кыргый күзле,
Кырыс сүзле
Кыргый кыз.

## *Кумер тагын яна ала...*

Мәхәббәттә була шундый чаклар —
Көтмәгәндә сүнә кабынган учаклар.

Көтмәгәндә кабына анының яңасы —
Шундый дөрли... Үзең үк син таң каласың.

Көтмәгәндә сүнеп китә бу учак та...
Көлме, күмерме булырбыз шундый чакта?..

## *Китми*

Аягыннан дулкын этә:
— Кит, — ди.
Җил дә чәчләреннән тарта:
— Кит, — ди.
Ә мин аңа карап кына торам бары...
Дулкын этсә дә,
Җил тартса да —
Китми...

* * *

Яфраксыз урманда,
Умырзая туганда,
Бозлы күл буенда,
Бер-беребезнең куенында
Бу язны без икәү башладык...

Синең кулда —
Синең балдак,
Минем кулда —
Минем балдак...

Хисләребезне булмый ялгап —
Балдакларны булмый алдап...

Бу язны без шулай башладык —
Бозлы күлгә нидер ташладык.

Синең кулда калды
Синең балдак,
Минем кулда калды
Минем балдак...

## *Таныш җылы*

Озатканда нинди теләк телим?
Ул теләгем нишләр юлларда?
Кочыйм гына,
Кулың кысыйм гына —
Уртак җылы калсын кулларда.

Син кайтканда
Шушы куллар белән
Каршыларммын,
Кулың кысармын.
Таныш җылы синнән киткән булса,
Учларыма кереп посармын.

Учларымда калган җылылыкта
Алырмын да бераз җылынып,
Мин китәрмен, егет, син калырсың —
Җылысы барның һәрчак кулы нык...

## *Ян, дисеӊ син...*

Ян, дисеӊ син,
Ян, дисеӊ син,
Ян, дисеӊ син!
Яктысымы,
Җылысымы синӊа кирәк?
Алар миндә
Һава белән Җир шикелле —
Якты зәӊгәр күзләремдә
Җылы йөрәк.

Һәрбер җылы якты булу,
Һәрбер якты
Җылы булу фарыз түгел, фарыз түгел.
Якты аша
Җылылыкны күрсәтә алсам,
Канәгатьлек хасил итәр
Минем күӊел.

## *Сагынуның чиксез чагы...*

Йөгереп чыга каршыма,
Өй түйлары белән гөрләп,
Бәхет кичергән өйләр...
— Рәхим ит! Тик син сагынган
Кеше бездә юк, — диләр.

Яшел келәмнәрен җәеп,
Йөгереп чыга аланнар...
— Аланда да ул юк, — диеп,
Иреннәрен турсайтканнар
Чыклы, салкын баланнар.

Йөгереп чыга авыллар.
Аларда да юк эзең...
Юлда ничаклы авыл бар,
Берсендә дә сине күрмим —
Зарыгып бетте күзем.

Калалар каршылый мине,
Вокзал утларын ягып...
Ут эченнән сине эзлим,
Сине эзлим, тик табалмыйм —
Сагынуның чиксез чагы.

Вагоннан мин сикереп төшеп,
Чабып китәрмен кебек...
Күзләремне мин йомам да
Хисем тудырган томанда
Кайтам күзләрең үбеп.
Тимер юл йомгагын кемдер
Сүтә дә сүтә кебек...

* * *

Аягүрә басып арбага,
Ярылганчы гармун күреге,
Бер сузасы килә шаулы җыр,
Кычкырасы килә: күрегез,
Кайный әле, кайный шашкын хис.
Йөрәкнең бар дулар чамасы!..
Шау күбеккә баткан айгырдай,
Бер пешәсе килә, янасы.
Дүрт бармакны кабып авызга,
Сызгырасы килә кыл ярып.
Ыргыласы килә кыр буйлап,
Тузан болытлары кубарып.
Эх, килә бер сикереп каласы
Шул арбадан урман буена...
Яшьлегемнең зәңгәр язына
Элэгермен кебек тоела.

## *Буйсынам*

Давылларга алып кермә мине!
Керсәм ... исән чыга алмамын!
Йөрәк шартлар...
Йөрәк шартлар, белгәч
тын яшәүнең тынчу ялганын.

Давыл аръягынданиләр бардыр?..
Тәмуг уты?
Җәннәт багымы?
Ни булса да булыр!
Әй, Мәхәббәт,
буйсынамын сиңа тагы мин!

## *Мәхәббәт авырлыгы*

Кырык давыл аша узып,
сакланып кала алган
оялчан елмаю күрсәм,
хәтта югалып калам.

Маңгайдагы җыерчыклар,
күз төбендәге сырлар
сөю-сөелү серләрен
менә ачарлар сыман.

Ачылсалар, мин аларны
күтәрә алырмынмы —
хатын-кызның һәр серендә
мәхәббәт авырлыгы.

* * *

Кабат гашыйк булырмын дип куркам —
күтәралмас йөрәк, ярылыр...
Син, мөгаен, гади кеше түгел,
өйләр Иясенең ярыдыр.

Өй хакына бөтен нәрсәдән дә
баш тартырга, ахры, ризасың...
Белә микән Ияң гомерләрнең
җәйге яңгыр кебек узасын?!

Тәнең белән җирнең тере тәнен,
яшәү ямен тоймый калырсың...
Гашыйк булам! Һәм коткарам сине —
ярыла икән йөрәк, ярылсын!

Ияң, белмим, нәрсә вәгъдә иткән...
Минем вәгъдәм: бары кагылып,
безнең бергә булган һәр минутны
мин еларлык итәм сагынып...

* * *

Мине мең тарафка тарткан
әгъвалардан котылып,
синең яныңа кайттым мин...
Күз карашыңда — Котып,
сүзләреңдә бозлы гөрзи —
әйткән бере үтерә...
Ә мин тәмугка әйләнәм —
бозга каршы ут өрәм,
Котыбыңны җәннәт итәм,
гөрзиеңне — кар суы...
Иреннәрем сүндерерләр
сүзеңдәге ярсуны.
Муенга асылынырсың,
бер еларсың сулыгып,
үкси-үкси кабатларсың
бәхетеңнең юклыгын...
Яшьле керфекләрең тигәч,
күл булыр минем күзләр...
Күлемә батып, әйтерсең:
«Тагы ни кирәк безгә?!»

Аһ, кадереңне белмимен,
белмимен лә, белмимен —
синең яшеңне агызам,
су сораган гөлмени...

* * *

Алмагачлары — алмалы,
гөлләр чәчәктә иде.
Күзләрнең иң гүзәл чоры
барыбер миңа тиде.

Җәйнең җылысы бетмәгән.
Кышка да әле ерак.
Чыкларга чумып, язларны
бер кайтып була урап.

Алмаларына кагылсаң,
елан Хаввага сузган
алманың якты гөнаһы
йөрәк түренә уза...

Алмагачлары — алмалы!
Агачлар алтын киде.
Күзләрнең иң гүзәл чоры
барыбер миңа тиде!

## *Күзгә сугән мәхәббәт*

Мин киткәндә,
Хушлашып, кул изәмәде...

Кайткач сорадым:
— Нигә син кул изәмәдең?

— Кара, сизгәнсең икән аны!
Кулым җиле
Арканнан этсә,
Син күздән тиз югалырсың, дип
Курыктым, җаным...

## *Карасам күккә*

1

Карасам күккә —
моң күрәм: синең моңың.
(Сагыну тәэсир итә
микәнни күккә?..)

Карасам бакчага —
лепелди башлый йөрәк:
чияләр — синең иреннәр...
Тизрәк сине күрәсем килә.

2

Карасам күккә —
сагышың синең.
Карасам бакчага —
алмагачлар күлмәк сала.
Барам,
барам яныңа, барам...

3

Карасам —
инде күптән
теге болытлар киткән күктән.
Алар урынына
агы килгән,
туй күлмәге кигән.

Йөрәгем — дәрт!
Хисләр — күкерт...
Тәмәке кабызам...
Тәмәке генә.
Тәтене болытка менә,
менә,
менә...

Җитә алмый.

Ә күктә зәңгәр моң.
Синекеме ул?
Минекеме?

4

Карасам —
күктән кар ява.
Тирә-юнь тып-тын.
Тыныч.
Сафлык.
Ак карда шыгыр-шыгыр эзем.
Аның белән янәшә
бер эз дә юк.
Салкын дым...

## Үкенең җыры

Нигә киттең инде?
Кая җиттең инде?
Ниләр үттең инде?
Нишләп беттең инде?

Сине көттем инде,
Күп яшь түктем инде,
Ятны үптем инде,
Аһ,
Ятны үптем инде...

Кайтмавыңнан куркам,
Кайтуыңнан куркам,
Әйтмәвемнән куркам,
Әйтүемнән куркам...

Нәрсә эшлим инде?
Терсәк тешлим инде...
Атың кешни инде,
Аһ,
Атың кешни инде...

## *Чибәр күргәч*

Күзнең салкын зәңгәре
Гөлдәй атты — ут булды.

Башның кышкы карлары
Эреде, акты — юк булды.

Такты — китте...
Такты да китте...

## *Фәкать шулай*

Әгәр соңгарып кайтсам —
белеп тор:
хакыйкать артыннан китеп
адашканмын...

Әгәр иртәрәк кайтсам —
белеп тор:
ул көнне дөнья
синнән салкынрак булган...

Әгәр вакытында кайтсам —
белеп тор:
ул көнне тормыш
назламаган да мине,
какмаган да...

## *Менә кайдан*

Сузылып зәңгәр күктән
Кояш Җирне бер үпкән,
Ике үпкән,
Биш үпкән,
Бик күп тапкырлар үпкән.

Сузылып үпкән саен,
Туган бодай, мәк, каен,
Җанвары туган,
Кошы,
Гөлләр, җиләк һәм кеше...

Әллә кайчан,
Бик күптән,
Сузылып зәңгәр күктән,
Кояш Җирне бер үпкән
Һәм шуннан инде киткән
Могҗизалы үбешү.
Могҗизалы үбешү —
Җир белән Кояш эше.

## *Карт җырчы*

Бетсә җырчының тавышы,
Мәхәббәте калса исән,
Аның күңеле күкрәгеннән
Моң тулы җил булып исә.

Җырчы күрә:
Җилне тыңлап,
Күпме күңел гипнозлана...

Ә мин сизәм:
Шул вакытта
Сары камыштай сызлана
Аның тәне. Аның җаны
Япь-яшь гыйшык таләп итә...
Путаны кул диеп белеп,
Аның биле изрәп китә...

Табигатьне җиңәм диеп,
Кылыч итә күңел кылын.
Тик кылычны кынысыннан
Чыгара алмый хәлсез кулы...

Бетсә җырчының тавышы,
Мәхәббәте калса исән...

* * *

Китте.
Ялгыз калдым.
Тәмәке
Тынычландыра алу көчен югалтты...

Аһ, ничек телим:
Йөгереп керсен иде дә,
Тетрәнгән гәүдәсен
Иңнәремә элсен иде дә
Сыктасын,
Сыктасын,
Сыктасын иде.

Тәмәкемнең көле төшеп,
Аның чәч төбен пешергәч,
Кинәт туктасын иде,
Ычкындырсын иде
Иңнәремнән кулларын.
Башын иеп катып калсын иде,
Аяклары талсын иде,
Идәнгә аусын иде...

Гәүдәсе аша атлап чыгып китәр идем,
Калсын иде...

Аһ,
Син хәзер үк миңа тансык инде...

* * *

Китте бу яз.
Иреннәрдә
Калды үбешү эзе.
Эзгә җыелган хисләрдә
Күңелем йөри йөзеп...

Йөзә — эзли,
Йөзә — эзли.
Эзли нинди дәваны?
Юкмыни соң үбүләрдә
Үбешүнең дәвамы?

Килде бу җәй —
Үткән язның
Варисы, дәвамчысы.
Ни булып шытар иреңдә
Үбешүләр тамчысы?

* * *

Син, мин, Идел —
Өчәү янәшәбез,
Яшьлек турында без
Сөйләшәбез...
Минем яшьлек —
Тынган дулкын кебек,
Синең яшьлек —
Тыныч упкын кебек.
Җил генә дә җитә —
Дулкын кубар,
Сихри тобаларга
Мине убар.
Дулкын үзе җилгә
Куәт өсти...
Тынган дулкын инде
Яшьлек өстем...

## Дулкын керсен...

Ватык көймә ярда калган...
Исәннәре дулкын яра...
Минем яшьлек, давыл кичеп,
Ярга якынлаша бара.

Ватык көймәне дулкыннар
Һаман кага, җәрәхәтли.
Ялгыз ярга җитмәс борын
Татып калыйм бар рәхәтне —

Кагылыйм,
Сугылыйм
Һәм чайкалыйм
Мин дулкыннар арасында.
Су кермәсен,
Дулкын керсен
Минем яшьлек ярасына.

* * *

Үпкәләттем, ахры, —
стенага капландың.

Стена миннән җылырак, ахры,
бу минутта...
Күзләрем — боз,
күңелем — таш,
йөрәгемдә, ахры,
кар ява...

Эрисем килде —
кайнар яшең
бары идәнгә тама.

Эрисем килде —
сулуым бозга
әверелде үпкәмдә.

Кичер, иркәм,
озак эредем —
суык сүзем
йөрәгемнән кояшымны
сөйрәп чыгып киткәнгә.

* * *

Кара миңа, буран булып —
Бар начарлык катсын...
Керфекләрең, сөңге булып,
Бозны ватсын.
Авыртсын күңел, шунсыз ул
Яши алмый.
Кара миңа, ялкын булып —
Эреп китсен күңел.
Тик шуны бел: эресә ул
Тамчы гына түгел.

* * *

Зәңгәр күк, иркәм,
синең күзләрең күк:
шулай ук тирән
һәм шулай ук чакырулы.

Күңелем минем аңа да үрелә,
хыялым да аңа үрелә,
бөтен барлыгым аңа үрелә —
очрашасым килә күк белән.
Сизәм:
ул да кавышу таләп итә Кешедән.

Иркәм, зәңгәр күк
булганда, синең күзләрең күк.
Җирдә Икарлар булуы,
космонавтларның тууы
гаҗәп түгел,
гаҗәп булмагандай
минем сиңа тартылуым —
егетнең кызга тартылуы.

* * *

Сине сагынган чагында,
Миңа үем тар кебек.
Чыклы таңда күлгә төштем —
Анда шәүләң бар кебек.

Бер өянке суга кергән —
Яфраклары кар кебек.
Ул да салкын су телидер
Ялгыз калган,
Сагыну утларында янган,
Өзелеп сөйгән яр кебек.

* * *

Сөйгән ярларга тугрылык —
сөюләр түкәнгәнче!
Язмышларыбыз сабасын
сөю калдыра яньчеп,
калдыра тырнап, аңарга
уйганда яңа бизәк.
Менә нигә үз төшенә
өзелә кайчак үзәк.
Менә нигә үз төшенә
җанны кайчак яшь күмә.
Менә нигә күңел кайчак
әллә кая ашкына —
эзли сөюләр дәвамын,
өмет итә табасын,
ышана турайтасына
ул язмышлар сабасын.
Ышансын — ләззәт татысын!
Ышанычсызлык — әче!
Ә сөйгән ярга тугрылык —
сөюләр түкәнгәнче!

* * *

Хатын-кызның юлын кисмә —
аңа аркылы төшмә,
болай гына йөриме ул,
бара-кайтамы эштән.

Кайда гына атласа да,
ак ният белән атлый.
Иң олы гөнаһ кылса да,
ул ахыр чиктә хаклы.

Кара мәче йә буш чиләк
була күрмә юлында...
Хатын-кыз — язмыш Алласы,
тормыш аның кулында!

* * *

Һәр нәрсәнең сере — беркайчан да
ахыргача ачылмаячак ишектер...
Әй мәхәббәт! Соңгы көнемәчә
миңа ишек шыгырдавыңны ишеттер!

* * *

Һәрбер агач, һәрбер үлән —
һуш китәрлек әңгәмәдәш.
Сөйләшер — тик тамырына
кагылырлык итеп эндәш!

* * *

*Нури Арсланов истәлегенә*

Алмагачлар картаялар.
Алмалары сутлы һәм яшь!
Шагыйрьнең дә чыны гына
алмагачка лаек көндәш.

* * *

Уйларның авырлыгыннан
иелми башлар.
Уйларыңнан курыкканда
иелә алар.

* * *

Изге һәр эш ак уйлардан,
пакь куллардан башлана —
и ак сөлге, татар халкын
ярдәмеңнән ташлама!

* * *

Кемдер сата.
Кем — сатыла.
Кемнәрдер тора санап.
Моны карап торучылар
ала әхлаксыз сабак...

## *Лирик сәүдәгәр*

Сирәк урман. Түбән кояш юмарт.
Алсу карда зәңгәр шәүләләр.
Баеп калыйм әле гомерлеккә —
булыйм әле лирик сәүдәгәр.

Кемгә кирәк төз нарат шәүләсе?
Йөрәк сизә — аның төбендә
бер хатынның бер ир иңнәренә
куанычлы яше түгелгән.

Кемгә кирәк ап-ак каенныкы?
Беләм, беләм, аңа сөялеп,
мин синеке була алмам, дигән
яшь егетнең горур сөйгәне.

Менә монда нәфис миләшнеке.
Җаным тоя: аны сыйпаган
бер чал шагыйрь, бүгенгәчә әнә
тәлгәш-тәлгәш утлы сый калган.

Менә юкә, имән шәүләләре!
Барысын да кояш турайткан!
Алсу карга хисле шигырь булып,
җыр юллары булып нур яткан.

Сатып алучылар күренмәде.
Күпме шәүлә калды үземә.
Мин аларны сатмыйм, бүләк итәм
шигыремә төреп, сүземә.

# *Дару исе сеңгән шигырьләр*

*(Цикл)*

## 1. Шик

Мин дә ятам авыр уйлар уйлап...
Тәрәзәдә көлсу яктылык.
Гомер янды. Көле күпләп калды.
Йөрәк тибә ләкин атлыгып,
әйтерсең лә алда алтын капка!
Әйе, капка! Үзем күрәмен.
Уем белән мин, үземне узып,
шул капкага барып керәмен.
Җәннәт капкасы ич! Әйе, җәннәт!
Артка чигә уем ашыгып...
Йа Алла, мин ул дөньяга түгел,
бу дөньяга үлеп гашыйкмын!

## 2. Шом

Шом ул — тәннең аңсыз уе.
Нишлисең бит, уйлана —
бәп-бәләкәй үлем кергән
җан яшәгән ояга.

Шом ул — аңның сызлануы.
Нишлисең бит, сызлана
чәчәк кебек өметеңә
кырау өреп узганда.

Шом ул — кешенең табигый
киңәшче бәхәстәше!
Ләкин шомны җиңеп кенә
кеше кешечә яши.

### 3. Илаһилык

Алга карап ният кормыйм,
уфтанмыйм артка карап —
икесе дә бүгенгемнең
көчен урлаучы карак.

Миннән өстен, миннән көчле,
минсез сүнгән һәм янган,
минсез аккан, минсез каткан
хәл хакында уйланам.

Яшәүме ул, мәхәббәтме,
тормышмы ул, үлемме?
Менә шушы халәтемдә
илаһилык гөле мин!
Һәм акыллы, һәм матур мин,
мин үле мин, терек мин —
мин ут белән,
мин су белән,
Җир-Күк белән
бер үк мин!

### 4. Вакытлыча хушлашу

Җылы булды минем тормышым.
Кайнар булды минем гомерем.
Якты булды минем яшәвем.
Сүнми торган тере күмер мин.

### 5. Өмет

Мин хушлаша яздым әле
сары урман белән...
Янчыгымда булган ярый
яман саллы түләм.

Мин яңадан басып торам
тере салкын җиргә,
куанычым ялкыныннан
батып шыбыр тиргә.

Яфрак коела... Аңарга
юл юк инде кире.
Тере туфрак күпме җанның
мәңгелеге-гүре?!

Төркем-төркем кошлар күрәм
шәрә урман аша.
Мин алар белән хушлашмыйм,
бары — саубуллашам.

### 6. Теләк

Баш өсләп үтә болытлар,
вак кына яңгыр иләп.
Һәм минем синең яныңда
бер чыланасым килә.
Чал чәчләремнән тамчылар
чаларып тамсын тып-тып.
Шул тамчыларның тавышын
йөрәгең калсын отып.

Сары яфраклар өстендә
биегән яңгырдан соң
синең йөрәгеңдә һәр көз
җыр булып яңгырасын.

### 7. Үпкә

Аны, башы ярылгачтын,
мин коткардым үлемнән.
Колагыма рәхмәт акты
пышылдаган теленнән.

...Һәм миңа да янап алды
берчак үлем элмәге...
Рәхмәт, пышылдаучым хәтта
килеп хәлем белмәде.

Ояладыр... Оялудан
кими җанда шакшылык!
Мин аңа, оялтып, тагын
эшлим бугай яхшылык...

## 8. Ышаныч

Мин үземнән азат итмәм сезне
аяк эзем Җирнең йөзенә
төшми башлагач та...
Юлыгырсыз
юлыгызда үскән сүземә.
Кагылыгыз шайтан таягына,
тузганакның сөтен татыгыз,
ромашкалар, күкчәчәкләр белән,
күккә карап, аунап ятыгыз.

Исерегез көлсу әремнәрдән,
кычытканнар утын тоегыз,
алабута, сарут, әрекмәннең
орлыкларын җиргә коегыз.
Кайберләре тырнар...
Кайберләре
арындырыр чирдән, ярадан.
Чәчмичә дә үсә торган сүзләр
булып калам сезнең арада.

* * *

Җай гына башланган һәр эш
тәмамланмый җай гына...
Һәр гыйшык бәхет вәгъдәли,
кайчак кертә кайгыга...

* * *

Таш туңа да, чылана да...
кыза... чатный... яңара...
Таш бәгырьләргә ничек соң
таш тамырын ялгарга?!

### Үземә үзем сыеп...

Көне буе әзерләндем
мин матур вакыйгага.
Тамырларымда каным да
мәдхия җырлап ага.

Чәчләремнең көлсу төсе
балкыды көмеш булып.
Кочагым — чәчәкләр тулы,
телем — җылы сүз тулы.

Күзләремнең яшеллеге
тоташты зәңгәр күккә,
ә анда кара болытлар
пәйда булдылар кинәт.

Бәйрәмем барып чыкмады —
боз яуды коеп-коеп...
Мин исән кала алдым тик
үземә үзем сыеп.

* * *

Үз төшемә уянамын
төн упкыны төбендә.
Йөгереп китәмен. Кая?
Кая булсын — тегендә!..
Ә «тегендә» кайсы якта?
Ул давылмы? Дөньямы?
Ул җәннәтме, җәһәннәмме?
Сорауда ятам янып.
Ашкына җаным, ашкына...
Җанның күзләре йомык.
Барып җәһәннәмгә керсә,
кем алыр аны йолып?
Ә «тегендә» оҗмах булса?!
Мин калсам батып төндә?!
Газаплы үкенечләрдән
нишләрмен икән өндә?
Үз төшемә уянамын...
Мин кая чакырулы?
Йөрәгемдә башлана да,
миемдә бетә юлым...

* * *

Яфракларын өзмә көзнең —
җаныма төшә сызлау.
Көз — вакыт халәте түгел,
җан хасияте — кызган.

Бәллүр савытка утыртып,
туңдырма көз тамырын.
Көз бит миндә чәчәк ата,
көй сеңдерә, яңгырый.

Үз вакытын миндә көтә —
купшылана, җитлегә,
йөрәгемне азат итә
тезгеннәрдән, читлектән.

Көз булып дөньяга чыгам.
Ул — матур, якты, көләч.
Тик җан сызлый, кулың сары
яфракларыма тигәч.

## *Самолетта Бишкәккә*

Урмансыз,
елга-күлләрсез,
комлы-чүлле яшәеш
күзгә керә коры җилдәй, —
һәм күзләрем юпь-юеш...

Урманлы,
елга-күлләре,
гөлчәчәкле җирләрем,
күземә тизрәк кайтыгыз —
сезсез үләм чирләп мин.

* * *

Кайбер уйлар кысыр болыт кебек...
Шәүләсе бар, ләкин юк дымы.
Сүзләр чәчәк атмый...
Әллә миңа кысыр болыт чире йоктымы?

Кайбер уйлар, әйе, кысыр болыт...
Күләгәсе ләкин бар аның.
Тормыш эссесеннән качып, кайчак
фәкать шунда мин хәл аламын.

## *Абу-Дабида*

Комнан аркан ишеп булмый, диләр...
Яшәгәнбез шуңа ышанып,
вакытында салып атмаганбыз
аңыбызны буган тышауны.

Ком гарәбе әнә ишә алган.
Дөясеннән сикереп төшкән дә,
аркан белән илен күтәргән ул
Европалар җиткән түшәмгә.

Җир өсте дә безнең Җир асты күк.
Тотына калсак әгәр ил белән,
аркан гына түгел, ишәр идек
менә дигән ипле дилбегә.

Илебезне борып кертер өчен
сәгадәтле такыр юлларга...
Тышауларны тизрәк, тизрәк чишик,
чишеп ыргытырлык кул барда.

Бәлки, бүген моның вакытыдыр,
соңарырбыз, бәлки, иртәгә...
Абу-Даби диңгезендә ятам.
Җан тынгысыз, каным үртәлә.

Комнан аркан ишеп була икән.
Куш учыма көрәп ком алдым.
Бармак араларымнан агып, ул
әкият җене кебек югалды.

## *Капитолий үрләрендә*

Капитолий үрләрендә
кешеләр көләч...
Җаным әллә нишләп китте,
баскычын менгәч.
Бер рәхәтлек
һәм мең гарьлек
анда буталды,
йөрәгем йокыга талды,
уем тукталды...
...Иң бай илдә
ярлылыкка
яшибез батып.
Төзәтергә — гомер кыска,
дәрман да ватык.
Шулчак йөрәк телгә килә:
гарьләнү,
тик сынма —
арткы аяк һәрвакытта
калачак соңга...

## Женевада

Синең хакыңны хакларга
килдем, Татарстан.
Заман шундый — шикләнәсең
дошманнан, дустан.

Женева күлендә дулкын
зәңгәрсу-яшел...
Минем хисләрем дулкынга
кушылып яши.

Бәргәләнә. Җилгә кушып
җибәрә моңын.
Йөрәккә утырып кала
уйларның дымы.

Сине биредә белмиләр
ник, туган илем?
Бик ерак киталмый икән
даныңның җиле.

Кычкырдым, үпкәм шартларлык
итеп тын алып...
Ишетмәделәр — үз-үзен
тыңлый бар халык.

Мин шартладым — юл булмады
кире чигәргә.
Кыйпылчыкларым әйләнде
шушы шигырьгә.

## *Кояшчыклар*

Песнәкләр коена карда:
чумалар, кагыналар —
сагыналар, ахры, карның
агымсу чагын алар,
шатланган хәлен дөньяның
чәчрәгән чакта чыклар.
Эретерләр, ахры, кышны
канатлы кояшчыклар.

* * *

Томаннар аша узган бар —
ул болгана, кузгала.
Уйны әллә кайларга ук
тартып торган эз кала.

Томаннар артында дөнья
чистарактыр, яктырак...
Исә җил һәм кояш балкый...
Һәм каласың аптырап.

Томаннар аша чыккан бар,
сулаган бар салкын дым.
Хыялый томанлы чакны —
яшьлегемне сагындым.

* * *

Инде күптән яңгыр тамчыларын
кара иткәнем юк каләмгә.
Күңелемдә ашкынудан шаша
киләчәккә дигән сәламнәр.

Җиргә тигән яңгыр кибә — беләм.
Ләкин үлми. Туа яңадан —
гөл таҗына кунган чыклар булып,
томан, болыт булып яңара.

Шигырьләрем — җырмы, беркатлымы,
аһ-зарлымы, саймы, тирәнме —
алар,
алар киләчәккә сәлам,
һәм аларда минем йөрәгем

чәчәк ата, галәм дымы тисә...
Үз вакыты ләкин яңгырның...
Шуңа күрә янган каләмемә
мин мең тапкыр күзьяшь яудырдым.

## *Менә мин кем!..*

Иблис, Шайтан, Мефистофель
— берни түгел!..
Ә мин менә — чып-чын Кодрәт
— көчле, бөек.
Күрәсезме, акчарлаклар сугыштырам,
пароходтан валчык-валчык ипи чөеп...

## *Керсезлек*

Күләгәдә кояш нуры
күрә алган кешедер Сез!
Димәк, Сезнең күңелегез
кояш нуры кебек — керсез.

## *Татарстан хатыннары*

Җирнең һәммә асылташы,
көмеше, алтыннары
читтә торсын сез булганда,
Татарстан хатыннары!

Безне куркытмый язмышның
яңгыры, салкыннары
сезнең кочагыгыз барда,
Татарстан хатыннары!

Җирдә күпме сайрар кош бар —
аларның хак моңнары
сезнең пышылдауга тормый,
Татарстан хатыннары!

Сез пешергән ризыклардан
тәмлерәк тәгам бармы?!
Булса да, бик тә сирәктер,
Татарстан хатыннары!

Һәммәгез булырга лаек
шагыйрьләр, ханнар яры —
сез акыллы да, назлы да,
Татарстан хатыннары!

Көзнең җимешләре бит сез,
ә кышның ап-ак кары,
яз гөлләре, җәй рәхәте —
Татарстан хатыннары!

* * *

*Үзеннән зуррак булып күренергә*
*тырышкан кайбер каләмдәшләргә*

Үз томнарын үзе акча түләп
бастыра да, үзе сатып ала.
Китапларын кеше күрмәсә дә,
файдасы бар — даны янга кала!

* * *

Танымагыз... Санламагыз... Кирәкми!
Давыл егып салгач кына тирәкнең
кадере арта — сандугач та, карга да
мәхәббәтен ышандырып каргана...

* * *

— Заман җиле уй-фикерне
иләде һәм җилләтте...
Аңладым, булырга тиеш
кешенең бер милләте.
Милләтен аның теленнән,
көе-моңыннан эзлә!..

— Милләтен ничек белдерә
ләкин чукрак-телсезләр?

## *Мәйданнарда*

Мәйданнарда киңлек була.
Һәр киңлектә булмый ирек.
Әгәр булса — алыр идек
барлык мәйданнарны биреп.

Мәйданнарда шау-шу була,
ә шау-шуда булмый гакыл.
Әгәр булса — мәйданнардан
чыкмас иде барлык халык.

Мәйданнарда халык булмый,
мәйданнарда төркем генә.
Төркемнең бәхетле итә
алганы юк беркемне дә...

* * *

Мин яхшы, башкалар начар,
дип яшәгән кешедән
чыккан һәр сүз боз була да
кереп канны өшетә.

## *Таллинда*

Таллин мине ярты айга
иртәрәк язга кертте.
Күңелем карурманында
бөреләр борын төртте.

Казанда, Аккош күлендә
кыш калган иде ятып...
Хәтта кояш чыгышына
каршы аккан бит вакыт —

көнчыгыштан көнбатышка
ага иде ләбаса!..
Гөрли уйларым ташкыны —
йөрәгемне су баса...

## Нашатырь

Сугыш ерак... Сугыш якында...
Гәзитләрдән чыккан ялкында
яна дөнья... Күек исеннән
парламентлар, илләр исергән —
кояшка да берсе таш атыр...
Тизрәк, тизрәк, тизрәк — нашатырь!

## Байкалда

Байкалның иң төньягында,
терәк итеп Саян ташын,
Казанга этеп җибәрдем
дымы кипмәгән кояшны.

Тәгәрәде сибә-сибә
Байкал-күлгә алтын чыгын...
Таулар янгынга әйләнде,
дулкыннардан ялкын чыгып.

Курка калдым: кояш шулай
барып җитсә Казаныма,
китерер ул көтелмәгән
хәсрәт, бәла-каза гына...

Туган җирне ихлас сөю
тынгы бирми йөрәгемә.
Һәрвакытта ул — горурлык,
һәм борчылу — кирәгендә.

## *Күз*

Гомер буе ничә тапкыр
ачыладыр, ябыладыр...
Ачылганда — җаныңа ямь,
ябылганда — ял буладыр.

Иң беренче ачылганда,
якты дөнья тула аңа.
Соңгы тапкыр ябылганда,
якты дөнья кайда кала?

## Җәяү

Тарих буйлап яланаяк атлыйм...
Машинада чапкан чак булды...
Аягымны туфрактан аерып,
мин беразга, ахры, отылдым —
камыл тишә нечкәргән табанны;
чыпчык тизәгендә таелам;
әллә ничек шунда — керә алмыйм
шәһри гомеремнең җаена...
Җәяүледән эзләр җирдә кала,
аскылары кала, өскесе!
Мин өзгәнмен, ахры, аһ, өзгәнмен
аяк эзләремнең дисбесен...
Төймә-төймә кала җирдә эзләр —
тарих буйлап җәяү барамын,
дисбе тезеп, чөнки өзек дисбе
рухны тазартырга ярамый.

## *Төшкәндә*

Төшеп киләм менә мәрмәр баскыч буйлап...
Баскан саен агып китә уйлар, уйлар
үрләргә һәм үзәннәргә, урманнарга,
баткакларга сузылып яткан гомер буйлап.

Менгән чакта кулларга да, уйларга да
чыккан сөял сызлап куя сулык-сулык.
Төшкән саен күтәреләм үз алдымда,
халык җанын аңлый торган патша булып.

## *Ошаса!*

Түземсезләрнең капкасы
һәрвакыт ачык.
Йөрәкләре һәрчак әзер
чыгарга качып,

кошлардан канат алырга,
җилләрдән — тизлек.
Түземсез үзен узарга
мең ысул эзли...

Миллионнар таба алмыйлар...
Кем таба ала,
Шул кеше бик күп гасырга
Вакытта кала.

Түземсезнең җан капкасы
һәркемгә ачык...
Кил, кер — гыйбрәтләр күрерсең.
Ошаса — ал, чык.

* * *

*Грозныйга самолетта очканда.*
*5 сентябрь, 1998*

Кешене мәшәкать йөртә.
Ул — куркудан көчлерәк.
Курку бер инфаркт төбәсе,
мәшәкатьтә өч йөрәк.

Мәшәкатьнең олысы да,
кечесе дә бер көчтә.
Чәчәк бүләк итәр өчен
кеше диңгезләр кичә.

Яшәсен йөрәктә мәңге
кешелекле бер гадәт:
мәшәкатькә буйсыну һәм
мәшәкатькә мәхәббәт.

## *Грозный, 1998 ел*

Сугышларны минем күргәнем юк.
Күп күрдем мин ләкин эзләрен
үз илемдә, ерак Европада...
Бүген менә сугыш күзләре
күзләремә минем карап тора
чечен өйләреннән, сызланып...
Һәм алардан шартлау булып чәчри
миңа үпкә, мине кызгану.
Акланырга сүзләр эзләп йөдим.
Таммый ләкин телдән сүзләрем,
яралы өй миннән эзләгәндә
кешелеклек хисе эзләрен...

## *Илбасар кабере*

Кем болганчык уеннарда
җан-намусын җуяр икән —
кем илбасар каберенә
тере чәчәк куяр икән?!
Кан койса да, җан бирсә дә,
буйсынып олы әмергә,
илбасар илбасар инде,
нинди генә данга төрмә!
Нинди генә максат белән
акласаң да аның эшен,
илбасар илбасар инде —
ил канынннан даны юеш!
Кем болганчык уеннарда
җан-намусын җуяр икән —
кем илбасар каберенә
тере чәчәк куяр икән?!
Корымасмы аның кулы,
ватылмасмы коты-коны,
шул илбасар нәселеннән
булса да аның токымы?!
Аң тарихка ага ала,
ә кан ага киләчәккә...
Бердәмлек киләчәгенә
куелсын тере чәчәкләр.
Кем болганчык сәясәттә
җан-намусын җуяр икән —
кем илбасар каберенә
тере чәчәк куяр икән?!

* * *

Тукай туган көнне һәр ел кояш.
Ә төштән соң бик еш — яңгырлар.
Тукай кояш булып ымсындыра
һәм сут суза шигъри тамырга.

* * *

Кабат килде март ае —
яшькә гашыйк карт ае;

бер туңа да, бер эри...
Чынлап түгел лә, юри,

дип уйлый күрмик тагы!
Бу — елның сынган чагы,

аңның суынган чагы,
җанның ымсынган чагы...

## *Яз исе*

Яз исе!
Яз исе!
Яз исе...
Кулларның килә җир казыйсы,
аякның каядыр чабасы,
күзьяшьнең — агасы, агасы...

Яз исе!
Яз исе!
Яз исе...
Киләдер дөньяны таслыйсы,
телемнең — җылы сүз әйтәсе,
йөрәкнең — яшьлеккә кайтасы...

Яз исе!
Яз исе!
Яз исе...
Килә лә бер шашып назлыйсы,
тылсымлы учаклар ягасы...
Кар суы булыплар агасы...

Яз исе!
Яз исе!
Яз исе!

* * *

Ачу-үч өермәсенә
башымны ташладылар,
агу белән сүзләремнең
тамырын ашладылар —
йә тынсын, йә фикереннән
атылсын диеп янау,
түзмәс диеп, ялгышыр дип,
бирешер диеп санап.

Ачу-үч өермәсендә
бер очтым, бер мәтәлдем,
сүземне, канымда юып,
кешечә әйтә алдым.
Теләүчеләре аңлады...
Ә дошманнар?.. Алары:
«Сүзендә — кан исе!..» — диеп
ярдылар бугазларын.

## *Сайлау*

Язмыш хәл ителгән вакыт —
сайлый кайсы... сайламый...
кайсы уйлап, кайсы уйнап,
аңлап, алдап, аңламый,
кайсы — ышанып гайбәткә,
кайсы — пычракка батып,
кайсы — беткә ачу итеп,
шәп тунын утка атып,
кайсы сайлый сайламыйча,
сызып атып барысын —
томанлы шау-шу эчендә
яшәү аңа ярыйсы...
Чатный өмет. Болгана аң.
Тотрыксыз кала күңел...
Сайлаулар — әлбәттә, уен,
һәм уен гына түгел.

# *Аңладым*

1

Һәрбер адым — мин аңладым
күптәннән —
атлау икән киләчәктән үткәнгә.

2

Бихисап күз ачу-йому, ышандым,
чәйнәү икән ниндидер нык тышауны.

3

Йокыга һәр талып алу — төшендем:
үлеп каравы икән ул кешенең.

4

Гомумән, мин күп нәрсәне аңладым...
Ә үземне әле һаман алдалыйм...

## Эзләдем балын, тозын

Көнне актардым кирегә —
эзләдем балын, тозын...
Кайбер сәгатьләр бик кыска,
кайбер секундлар озын,
кайбер хәлләр искә төшкәч,
тетрәнеп куям кабат,
йә чоңгылларга мәтәләм
яки киерәм канат,
кичәм шикләр карурманын,
кермәмен яу кырына,
үч кычытканында ауныйм,
наз гөленә орынам...
Яшим икән әле, димен —
бүген дә булган кызык!..
Ләкин һаман аера алмыйм
яшәүнең балын, тозын.

## *Ике сайлау арасында*

Сандугач сайрап йоклата...
уята күке тавышы...
Ике сайрау арасыннан
уза гомерләр агышы.

Дөбер-шатыр...
Ыгы-зыгы...
Гөрселдәүләр...
Авыр тынлык...
Кеше түгел — җансыз ташның
салкын тәне авыртырлык.

Ә шулай да яшәү — ләззәт,
ишеткән, тойган, күргәндә —
сызландырып, сокландырып,
дөнья җаныңа кергәндә!

## *Нәрсә әйтим?*

Кавышуларга безнең бөтен дөнья шаһит,
Вәгъдәләрне бөтен дөнья белә.
Нәрсә булды сиңа —
Оныт, диден.
Зиһенем җуеп,
Оныта алмый кайтып киләм.
Нәрсә әйтим сине көткән бусагага?
Хәлләремне ничек итеп мин аңлатыйм?

Нәрсә әйтим ак каенга, тулган Айга,
Йолдызларга, үз-үземә нәрсә әйтим?
Онытырмын, дисәм —
Булыр ялган.
Онытмам, дип
Һич тә әйтә алмам.
Мәңге язмыш белән килешә алмам,
Ничек кенә сабырлыклы була алыйм?

## *Шушы шатлык*

*(Табын җыры)*

Шушы шатлык, бәлки, кабатланыр
Күзгә җилләр искән чагында...
Язгы җырлар дуслык анты булсын
Һәр табында,
Икмәк алдында!

Шушы җырлар, бәлки, кабатланыр
Кышын, җәен, тагын, тагын да...
Җыр китергән ләззәт уртак булсын
Һәр табында,
Икмәк алдында!

Шушы бәхет, бәлки, кабатланыр
Заманалар кичкән агымда...
Уртак бәхет җырга әверелсен
Һәр табында,
Икмәк алдында!

## *Син*

Тәңредән дә илаһирак көч юк, диләр.
Син аннан да хәтта көчлерәк —
эшләнәчәк гөнаһларны ярлыкыйсың!
Ул — үткәнен генә кичерә...

* * *

Ел фасылы түгел лә мин —
кайчан телим, шул чакта
яфрак ярам, чәчәк атам,
янам сары учактай.

Еллар буе яфрак коймый
тора алам, теләсәм...
Әмма бер шарт: минем өчен
кояшың сүрелмәсә...

* * *

Мин сиңа болыт юлладым —
яңгыр итә алырсыңмы?

Җылылык төяп озаттым
сезгә таба искән җилгә —
яңгыр итә алырсыңмы?

Шушы юллар арасына
йөрәк тибешемне салам —
күктән яңгыр коя торган
күк гөлдерәү итеп аны
яңгырата алырсыңмы?

* * *

Ә син мине урламадың...
Син мине... бүләк иттең.
Элек ярты гына идем,
хәзер инде мин — бөтен.

Элек мин ярлы булганмын,
хәзер шундый баедым.
Җирне су басу алдыннан
әйтерсең Нух каегы!

Курыкмыйча йөзә алам
дулкыннар упкынында —
үлмәслек өмет йөрәктә,
сүнмәслек ут кулымда.

Каек туктала калса, бер
ниндидер җиргә җитеп,
дөнья корыр куәтем бар
матур һәм җайлы итеп.

Кодрәтем бар сине шунда
мендерергә тәхеткә...
Син бит мине бүләк иттең
менә нинди бәхеткә.

## *Олы юлның тузаны*

Белми калдым, сизми калдым
яшь гомернең узганын...

*Татар халык җыры*

«Олы юлның тузаны»н ла
үземә дип уйнадым.
Гармунымнан бармакларның
тайпылганын тоймадым.
Алар моңлы канат булып,
төнге күктә югалды...
Үзәк өзгеч бу утлы көй
өзелмәде,
ул янды,
бер кабынган учак кебек —
дөрләде дә дөрләде...

Ялкында синең янганны
күрмәдем мин, күрмәдем...
Бармакларымның пешүе
мине кинәт айнытты —
аларны син үбә идең,
ә иреннәрең утлы...
«Олы юлның тузаны»н ла
үземә дип уйнадым.
Бармакларның үткәннәрне
кузгатуын тоймадым...

## *Почта ящигы*

Көн авыр. Яңгыр карлы...
Җирне ертып, ул хатынның
кая шулай ашыкканын
мин генә беләм бары.

Бар аның ерак яры...
Бүген иртән нинди хатны
үбә-үбә укыганын
мин генә беләм бары.

Почта ящигы сары...
Ул хатынның куенында
нинди кайнар хат ятканын
мин беләчәкмен бары...

* * *

Мәхәббәтемнең канаты шулчаклы киң —
яшеренлеген саклар өчен,
Казан — авыл!..

Мәхәббәтем кайнарлыгын саклар өчен
Җирне япкан һава юрган —
иләк төбе!..

Мәхәббәтемнең очышы шундый биек —
Кояшка кагылып көя,
Айда — өши!..

Мәхәббәтемне кадерләп саклар өчен
дөньяда бердәнбер урын —
синең йөрәк!

* * *

Бөртек-бөртек
нәкъ сиксән сигез керфек.

Сиксән сигезәр кара кылыч
ике диңгез тирәсе.
Кылычлардан тишелә-киселә
килә шунда керәсе.
Һәр яраны ерта-ерта
тулсын диңгез йөрәккә —
яшәү өчен бу диңгезгә
батып үлү кирәк тә...
бата алмый аптырыйм.

* * *

Ялгызым йөрдем мин урамда...
Уйларым чайкадым буранда...

Аһ, буран һич түгел гади җил —
аңа ут өстәгән Газазил,

ә Җирнең күгәргән һавасы
сеңдергән тереклек хафасын.

Бер җитди кайгы да буйламый,
күрәсең, керләнгән уйларым.

Шул килеш калсалар тагын да
каралтыр идем көн агын да —

чайкадым уйларны туйганчы,
агару ләззәтен тойганчы...

Һәм хәзер мин лаек назыңа...
Килермен, көт инде аз гына...

* * *

«Күзләреңнән күземә
коңгырт-кара төс иңде
һәм күзем карасына
үткерлек булып сеңде.
Күзләреңә күземнән
зәңгәрлек йогып калды.
Кая куйдың син аны,
нинди җилдә югалттың?»

«Күзләремә күзеңнән
йогып калган зәңгәрлек
мендәрләрем читендә
ачы тоз булып әрни!..»

* * *

Күңелсездер сиңа минем белән —
утым сүнде әле йөрәктә.
Сайрар кошларым да күкрәгемнән
очып китте...
Алар еракта...
Йолдызларым нурсыз калды әле...
Күкрәгемдә —
кошсыз кара төн...
Күзләремә карап, әйтерсең лә
кояш әйтте миңа: «Яратмыйм!..»
Шундый чакта син терәк бул миңа,
кошларыма җайлы тирәк бул...
Кашларыма кагыл...
Шундый чакта
кабынмаган йөрәк сирәк ул.

* * *

Мунчаларга да яшермә,
шкафка да качырма,
чормаңа да менмәмен мин,
чоланыңда да тормам.

Чит күздән укам коела —
күрмәсен лә җиде ят:
ышанычлы җирдә сакла —
йөрәгеңә кертеп яп!

## *Китә аламы?*

Җил һавадан китә аламы?
Кызыл төстән аер баланны!

Йә арындыр көнне яктыдан,
тау-тау болытларны ак дымнан,

сөю сүзен аер назлардан,
умырзаяларны язлардан,

үбешүне — күзләр сүнүдән!..
Һич аңламыйм: әле син нидән

моң кертәсең якты җырыңа —
уйланасың булмас турында...

Китә аламмыни яныңнан
яшәткәндә сине җанымда?!

## *Шуны онытма*

Тормыш шундый — уттан алып
төпсез суларга сала...
Яшел аланда чагында
шуны онытма, бала,
шуны онытма, бала!

Үз бәхетен биреп, кеше
бәхетсез итә ала...
Мәхәббәтең, тапшырганда
шуны онытма, бала,
шуны онытма, бала!

Көе суынса да җырның,
сүзе йөрәктә кала...
Гомерлек җыр сайлаганда
шуны онытма, бала,
шуны онытма, бала!

## *Керү хакы*

Яннарыңда синең миңа рәхәт —
вакыт туктый җәннәт түрендә.
Матурая дөнья...
Хәтта гүр дә
якты ятак булып күренә.

Курку бетә...
Үлемсезлекнең дә
һич кирәге калмый бөтенләй.
Дөнья гамен
сөю ялкыннары
әйләндерә зәңгәр төтенгә.

Юкка гынамыни мәхәббәтне
утларында аның көйгәннәр;
«Яшәүдән дә хәтта татлырак ул,
үлемнән дә ачырак!» — дигәннәр.

Син янымда чакта
бу дөньяның
барлык җәннәтләре тирәмдә...
Яшәп калам,
керү хакы итеп
язмышымны сиңа бирәм дә.

## Тораташка әйләндерде

— Сагындыңмы?
— Сагындым.
Сиңа йөгереп киткән идем,
мин Иделгә абындым.
Идел суын зур су диләр,
артык киң тоелмады —
йөзә белмәгән көенчә
мин аны кичә алдым.

— Куандыңмы?
— Куандым.
Куанычымны шулай да
күзләремнән куа алдым —
аларда гомер күрмәгән
яктылык күрер идең...
Башка мине күрмәс идең —
күз караң эрер иде.

— Алай икән...
— Шулай да...
Үзең минем күз алдымда,
ләкин күңелең кайда?
Мин үземне шатлык санап
сиңа китердем үзем...
Тораташка әйләндерде
боз кебек ике сүзең.

* * *

Күз нуры да кайвакытта
сына, сызлана икән,
ә тавыш колак эчендә
туңа, бозлана икән,
дәртле җыр тамак төбендә
әверелә елауга,
веналарга үтеп кереп,
аңны болгата гауга.
Кызыксындырмый киләчәк
һәм кирәк булмый үткән...
Бу халәтне хәзер беләм:
ул — җан авырту икән.

* * *

Билгәнсең эчем-тышымны син
һәм тулгансың тирә-юнемә.
Дөньямның мин шулай кысылуын
рәхәтләнеп юрыйм юньлегә.

Гөмбәземдә йолдызларың яна,
сулаганым — күптән синең тын,
вакытның да, син булганга күрә,
якты, җылы һәрбер минуты.

Киләсемдә — синең киләчәгең,
үткәнемдә — синең үткәнең...
Мин кысылып иркенәя торган
галактика булып беткәнмен.

Ә юкса мин гади гашыйк кына,
тик илаһи минем терәгем —
чын гашыйкның күкрәгендә һәрчак
сөйгәненең олы йөрәге.

## *Елның изге мизгеле*

Иң изге теләкләр белән
башладым яңа елны:
киләчәк чорлар алдында
гөнаһсыз булсын юлы.

Җиргә теләдем тынычлык...
Кышка теләдем ак кар —
бүген дә гөлләр өстенә
корым яуган илләр бар.

Язга теләдем ташкыннар —
күңелдән юсын ләмне.
Җәйгә — салават күпере,
шундый җәй генә ямьле.

Ә көзгә теләдем муллык —
амбарда да, төстә дә,
һәм туйлар ыгы-зыгысы —
бусы иң зур өстәмә.

Кешеләргә — олы сөю!
Ә үземә... үземме? —
Төнне көткән күзләреңдә
һәрчак күрим йөземне.

* * *

Ә бүген мин төне буе
күземне дә йоммадым —
сүтеп чыктым син чорнаган
хисләремнең йомгагын.

Җәйләр, көзләр, язлар узды.
Дөнья миңа гел актан! —
Гыйнварның кар шыгырдавы
һаман тора колакта.

Югыйсә бер генә тапкыр
төннең зәңгәр суыгы
без сүз дәшә алмаганга
куйган иде сулыгып.

Сизгән иде, сизгән иде —
көрт астында, еракта
умырзаядай җылылык
кузгалганын йөрәктә.

Шуннан бирле мин оныттым
вакыт агым икәнен.
Җәй көне дә кар тавышын
җырыма көй итәмен.

* * *

Болытлы көн нигә якты әле?
Әллә болытларның аръягында
берәрсе шырпы сыздымы?
Әллә
агарынганчы
вакыт кыздымы?
Әллә,
миңа якты сүз әйтергә теләп,
кадерле кешем ак кулларын
телефонга суздымы?
Болытлы көн
нигә болай якты әле!

* * *

Муеныңа салдым авыр чылбыр...
Ул — коллык билгесе, диләр...
Бәлки, чындыр.

Беләгеңә салдым кан тибешен саный торган
хәтәр богау...
Хата икән богау салып кына
хаким булдым диеп уйлау...

Бармагыңны
җептәй алтын боҗра белән будым.
Колым булдың дигән идем,
кемем булдың?

* * *

Язның беренче көнен
бүләк итмәкче бит мин,
ә син шундый да ерак!..
Кошлардан канат сорап,
тәвәккәллә — юлга чык.
Күрәсеңме, көн ачык,
һава зәңгәр, кырлар ак...
Ә мин торырмын карап
син киләсе тарафка —
беләсең бит — яратам
карарга таң атуны.
Син беренче таң булып
керерсең зәңгәр язга...
Күзләремдә уяныр
зәп-зәңгәр умырзая.

Шуны бүләк итәрмен!

* * *

Эзсез дә табам ич мин сине.
Күзсез дә күрәм ич мин сине.
Сүзсез дә аңлыйм ич мин сине.

Эзсез дә табам ич мин сине —
давылга
нәрсәгә соң
эзләр?
Күзсез дә күрәм ич мин сине —
йөрәккә
нәрсәгә соң
күзләр?
Сүзсез дә аңлыйм ич мин сине
сөюгә
нәрсәгә соң
сүзләр?

Мин сине табам ич эзсез дә.
Мин сине күрәм ич күзсез дә.
Мин сине аңлыйм ич сүзсез дә.

* * *

Минем хатлар самолетта бара...
Синекеләр — атка утырып...
Сагынганга шулай тоела микән?
Сагынмаган гашыйк юктыр ул.

Җирдәге иң җитез тизлектән дә
разый була алмый сагыну.
Исләреңә төшер кавышырга
тик адымнар калган чагыңны,

тик секундлар... Әмма вакыт бара
әкәм-төкәмнәргә утырып...

Минем хатлар әллә гамьсез микән?
Синекеләр — гамьнәр тутырук...

## Өч канатлы кош

Каз канатларын санама —
ничә санасаң да пар...
Ә кешенең йөрәгендә
өч канатлы кош та бар.

Бер канаты сына калса,
тиеп кара болытка,
хәтта бөркет җансыз ташка
әйләнә шул минутта,

акчарлакны дулкын уба,
һәлак була сандугач,
яшәвенең бар терәге
пар канат кына булгач.

Ә безнең йөрәк кошының
канаты иртә сына —
иң беренче мәхәббәтнең
бер суык иртәсендә.

Ә кош яши, ә кош оча...
Ул — мәңгелек юлдашың.
Ул — Мәхәббәт, ул өзлексез
йөрәккә бәхет ташый.

* * *

Минем көнем синдә яши бугай —
син күз ачкач чыга дөньяга,
күзләремә күрү көче бирә,
сүзләремә уйнак ут яга.

Җирдә күрәм төннең салкын юлын.
Синең җаның аша узган ул.
Күктә күрәм җил-давыллар эзен —
минем уйлар кебек тузгыган.

Һәм шул чакта фанилыктан өстен
бер көч итеп сиздем үземне —
кодрәт иясе күк мин җилләргә,
мин күкләргә сиптем сүземне:

җылытасым килде синең төнне!..
Һәм ишеттем кемнең өннәрен? —
«Алла түгел, бары кеше генә
җәннәт итә кеше төннәрен...»

## *Син каргама мине*

Син каргама мине хәтта
төшеңдә дә...
Каргыш сүзен җиңалмаган
кеше — бәндә.
Күл-күзләрдән, әйе, тоттым
алтын балык —
шуннан бирле кояш кебек
калдым балкып.
Мин сорадым якты көннәр —
аны бирде.
Мин сорадым җәннәт багы —
анда кердем.
Ул күлләргә күп чумды бит
синең күз дә!
Ничек инде — күлгә кер дә
анда йөзмә?!
Бәлки, суы синең өчен
тозлырактыр...
Дулкынының тибәрүе,
бәлки, хактыр...
Шулай булгач, син каргама
төшеңдә дә —
Күлгә кергәч тә йөзмәгән
кеше — бәндә...

* * *

Җилкәннәрдә әле язлар җиле.
Вакыт дулкыннарын ертабыз.
Максатыбыз — көзләр, кышларны да
җәйләр итә торган җыр табу!

Мачталарга яшен ташлар атты,
җилкәннәрне давыл йолыкты...
Ә күңелне нидер җылытты да,
шуңа таба көймә юл тотты.

Яңгырады кинәт эзләгән җыр...
Ул якын да кебек, ерак та...
Синең өчен минем йөрәктә ул,
минем өчен синең йөрәктә.

## *Янә ярлыкарга*

Мин ярлыкыйм барлык гөнаһыңны:
миңа чаклы булган барысы...
Тик әйт: нигә синең күзләреңдә
була кайчак курку ярысы?

Зәңгәр көннәр, кара төнне ертып,
ни күрә ала синең күзләрдән?
Кем куллары тиеп кашларыңа
карашыңның нурын үзгәрткән?

...Былбыл кунмый, әгәр оясында
сизсә исен ят кош эзенең...
Керфегең яп, тешлә зәңгәр көнне —
каный-каный синнән өзелим,

кояш булып батыйм сагышыма...
Синсез бераз яшәп карыйм соң...
Кабат калкып янә ярлыкарга
булган гөнаһларың... барысын!

* * *

Арыдыңмы җилгә каршы очып?
Авыртамы талган канатлар?
Өзә күрмә матур бу очышны —
бик теләрсең, булмас кабатлап.

Болытлары, бүселгәләп төшеп,
җиргә кысты очыш түшәмен...
Беләм, беләм: бер генә түшәм дә
кичералмый үзен тишкәнне.

Синең очыш бер йолдызга таба.
Син йолдызга исем илтәсең.
Беләсеңме: үзен йолдыз саный
һәр куерак болыт көлтәсе.

Өзә күрмә матур бу очышны...
Гомер узар... Булмас кабатлап...
Ә җил тынмас... Тик аңарга бәрелеп,
сынмас, сынмас көчле канатлар.

## *Ай — гашыйклар кояшы*

Ай ул — гашыйклар кояшы,
ләкин күпкә яктырак
һәм җылырак —
ул йөрәкне
хәтта чәчәк аттыра.

Диңгезләрне чигендергән
һәм яңадан ташыткан
көчен тамчысына хәтле
бирә ул чын гашыйкка.

Кубалар кайнар дулкыннар
хисләр океанында —
Эверестлар, цунамилар
тамчы алар янында.

Шундый дулкыннарда йөрәк
Айга тия атынып,
убыла да
упкыннарның
бар дәһшәтен татый ул.

Йөзә мәхәббәт иркендә
ул яңа чәчрәү көтеп,
тоя үзен сөйгәненә
чөелгән чәчәк итеп.

* * *

Җылыта Кояш,
яктырта
дөньяның тышын, эчен...
Кояш кына җитми икән
җанны җылытыр өчен,
тутырыр өчен аңарга
тамыр җәячәк нурлар...
Кеше җаны бу дөньядан,
ахры, бик күпкә зуррак.
Бәлки, артык кечкенәдер...
Ул кинәт балкып китә —
аңа кадерле кешеңнең
назлы бер сүзе җитә.

## *Кояш нуры ни бәя?*

Син янымда!
Юк — җанымда!
Шуңа эчтән яктырам...
Ләкин куркам — нидер килер
түләп булмас хак сорап...
Ә шулай да рухым ныклы,
җанымда көч күбәя —
хак сораучыга җавап бар:
Кояш нуры ни бәя?

## *Без бер елга*

Көтеп алам...
Дулкынланам...
Мондый бәхет — елга бер.
Ургыйм, ташам,
ярым ашыйм —
син давыл,
мин елгадыр.
Син китәсең...
Мин кибәмен...
Кемгә сөйлим зарларым?
Без бер елга.
Дулкын — синдер,
ә мин — моңлы ярлары.

## Үзгәрешләр

*Лилиягә*

Синдә нинди үзгәрешләр күрәм?..
Күзләреңдә очкын дымлырак,
төндәй чәчләреңдә таң беленә,
сүзсез торуларың шомлырак...

Ә калганы бар да элеккечә...
Тавышыңда шул ук көмеш чың...
Яшьлегеңнән берни кирәкмиме? —
Бик буласым килә йомышчың.

## *Кулың һаман кайнар*

I

Синең кулың һаман кайнар әле...
Учларыңда һаман тылсым бар —
кагылдың да җанны сугардың син,
гөл төбенә сеңгән дым сыман.

Зәңгәр чәчәк булды минем күзләр,
иренеңә синең атлыгып...
Үзгәрмәде ләкин чәчләремнең
Ай нуры күк салкын аклыгы.

Йөрәгемнең шашкын ашкынуы
тынган инде, туңган су сыман...
Синең кулың һаман кайнар әле...
Тик мин генә бераз суынган...

II

Синең кулың һаман кайнар әле,
бармак очларыңда тылсым бар —
кагылдың да кабат эреп акты
йөрәктәге авыр туң сулар.

Актарылды һәм уалды бозлар —
миңа әйткән салкын сүзләрең...
һәм яз килде кышның уртасына...
һәм яшәвем минем үзгәрде.

Синең кулың һаман кайнар әле...
Җылылыгын ничек сакладың?
Ничә яңгыр аны чылатса да,
җилгәрсә дә ничә ак давыл,

ничә гашыйк сиңа ялварса да:
«Бир җылыңны, юкса җан үчә...»
Синең кулың һаман кайнар әле —
мин җылытып киткәндәгечә.

## *Көнләшү галәмәте*

Әй көнли мине хатыным
әллә нинди хатыннан...
Ул хатынның белмим хәтта
фамилиясен-атын да.

Ә беркөнне уйлап куйдым,
хатыным бераз тынгач:
«Килде-китте түгелдер ул,
көнләштерерлек булгач...»

Иртәгесен белеп алдым
фамилиясен-атын да,
тагын ике-өч көн узгач,
характеры хакында.

Ә хатыным һәр көн саен
минем җанны чистарта...
Ул көнләшкән саен, минем
кызыксынуым арта.

Кайда яшәгәнен белдем,
кемнәр белән торганын,
быел ялны үткәрергә
нинди план корганын,

ничә халаты барлыгын,
төп-төгәл хезмәт хакын...
Кыскасы, белеп көнләшә —
акыллы минем хатын.

Ә көнләшкән саен, һаман
кызыксынуым арта,
кызыксыну арткан саен,
мине тегендә тарта.

Ә беркөнне уйлап куйдым:
«Тукта, нигә чиләнәм? —
Үз хатыным табып биргән
бу хатынга өйләнәм...»

Бәлки, мин чыннан да шулай
эшләгән булыр идем,
хатыным, бәлки, терсәген
тешләгән булыр иде,

әмма аңа нидер булды —
көнләшүен ташлады;
теге хатын әйтерсең юк —
телгә алмый башлады.

Һәм беркөнне уйлап куйдым:
«Мөгаен, бардыр сәбәп —
хатын көнләшмәслек булгач,
андый ярлар нәрсәгә?..»

## *Батырай көйләренә*

*(Цикл)*

1.

Һәр җырыңа үч итеп,
үгезләреӊ суйганнар...
Мондый хәлләр безгә дә
ят булмаган, Батырай*.

Эчеңдәге ялкынны
эчтә сүндерер өчен
авызыңа алтын су
коярлар иде бугай...

Шигыренең һәр юлына
сарык вәгъдә иткәч тә
килешмәгән — җырлаган
үз җырын шагыйрь Тукай!

2.

Син яшәгән бу дөнья
бер җылынсын өченгә,
күңелемне мамык җеп
итеп Җиргә чорнадым.

Заман дәһшәтләрендә
өзелмәсен, чыдасын
дип, күңелне тылсымга
мәхәббәткә — урадым.

---

* Батырай (1831–1913) — даргин шагыйре, һәр үткен җыры өчен үч итеп, байлар аның үгезен суя торган булганнар. Җырлыйсы килгәндә, кешеләр ишетмәсен дип, башын җиргә күмелгән зур чүлмәккә тыгып җырлаган.

Утлы өермәләрдә
мәхәббәтнең тамыры
кипмәсен дип, сөеклем,
сине, сине җырладым.

3.

Нигә гашыйк булмаска!
Гашыйк булу гөнаһмы?
Картайган тирәккә дә
былбыл куна лабаса...

Кичен сайрау ишетсәң,
сандугач дип уйлама:
бу — тирәк мәхәббәткә
сусавын җырлап баса...

Син көнләшмәсен диеп,
шагыйрь Батырай кебек,
башымны базга тыгып
җырлыйм мәллә, булмаса?

4.

Сөю өермәсендә
башы әйләнгән егет
дөньясы болганса да,
егылмас кара җиргә.

Сөю өермәсендә
күкләргә ашкан егет
җиргә егылмас өчен
җанын йолдызга бирә.

Сөю өермәсендә
бер тапкыр җан бирмәгән
егетнең, йә, бармы соң
әйләнгәне чын иргә?

5.

Бер үк төптә үсәләр
кушкаен һәм төз нарат,
тамырлары чолганып,
адәм язмышларыдай.

Бер каен каерылып
китмәкче дә, киталмый,
хисләре тапталса да,
гыйшкы исән гашыйктай.

Мондый ачык өчпочмак
китапта гына, диләр...
Йә, кайсыбыз булмады
шушы моңлы каендай?!

6.

Бүген сиңа ни булды? —
очкын чәчә күзләрең,
кара төндә ялтырап
яшен аткан шикелле.

Әгәр дә, син әйткәнчә,
йөрәгемдә мүк үссә,
аңа ут кабар иде,
тузга капкан шикелле.

Хәзер сиңа ни булды? —
Күз яшьләрең агалар
битең буйлап елтырап,
чишмә аккан шикелле.

Әгәр дә, син әйткәнчә,
сүземдә ут күп булса,
сүнеп суынуы бар,
Идел каткан шикелле.

Бүген миңа ни булды? —
Әллә ничек сөйләшәм,
Кояштан да җылырак
йолдыз тапкан шикелле.

7.

Ап-ак мендәрләргә салып
саныйм ак чәчләреңне...
Кайсыларын мин агарттым?
Һич танымый күзләрем.

Беләгемә башың куеп
саныйм чал чәчләреңне...
Аларда мин күрәм кебек
сүзем салган эзләрне.

Күкрәгемә башың кысып
саныйм ак чәчләреңне...
Шул ак чәчләрдән тукыгыз
миңа соңгы бүзләрне...

8.

Миңа караган кебек,
башкаларга карасаң,
күзең нуры, боз булып,
күз караңа кадалыр.

Миңа сыенган кебек,
башкаларга сыенсаң,
дегетле капка кебек,
беләкләрең каралыр.

Миңа җырлаган җырны
башкаларга җырласаң,
соңгы сүзе, таш булып,
тамак төбеңдә калыр.

9.

Алма бакчасына кереп,
төнлә алма өзгәндә,
агачын да сындыралар
таш бәгырьле бәндәләр.

Бакча кебек күңелемнең
җимешләрен өзгәндә,
нигә инде гөлләрен дә
таптадыгыз, адәмнәр?..

10.

Шундый якын чагында
сөеп, күреп туймыйча,
ник очырып җибәрдем
мин карлыгач баласын?..

Кулларымда җитәрлек
җылы булмады мәллә –
нигә килмәде аның
кулларымда каласы?..

Йөрәгем хәзер яна —
җылысы учларымда,
сөеп туймаган кошны,
эх, чакырып аласы!

11.

Төнге бәсле тәрәзәң
кинәт чылтырап куйса,
бел — туңган керфекләрем
пыялага кагылды.

Төнге бәсле тәрәзәң
чак кына зәңгәрләнсә,
аңа сине сагынган
күз нурларым ягылды.

Төнге бәсле тәрәзәң
көтмәгәндә чатнаса, —
ачудан алмаз булып
керфекләрем ябылды...

12.

Син ыргыткан авыр сүз
әгәр дә җиргә төшсә,
хасил булган ярыктан
янар тау атыр иде.

Син ыргыткан авыр сүз
әгәр Иделгә төшсә,
төбе тишелеп, Идел
суын югалтыр иде.

Син ыргыткан авыр сүз
тиде нәкъ йөрәгемә...
Мин күтәрдем... Ә сине
кемнәр юатыр инде?..

13.

Кояш көнгә чыккан күк,
мәхәббәтем йөземә
чыга да балкып тора —
нигә аны яшерим?

Җил чыккач, күлнең өсте
дулкынсыз кала алмый,
минем гашыйк күңелдәй —
нигә аны яшерим?

Ут капкач урманнарга,
төтен күренми калмый...
Йөрәктә сөю уты —
нигә аны яшерим?

14.

Тал-тирәккә нинди кош
кунып сайрап алганын
белү өчен шул талның
астында йөрү җитә.

Тал-тирәккә кунган кош
аңа ни сайраганын
белү өчен ябалдаш
җиленә керү җитә.

Талга корган оясын
ташлар өчен былбылга
ят сайрауга яфракның
тибрәвен күрү җитә.

15.

Сиңа ишеттерәсе
килгән җылы сүземне
җилгә әйтсәм, урманнар
тарап калмаслар микән?

Тәрәзәңә ут кергәч,
сиңа таба йөгерсәм,
җиде көндәш, куш күзләп,
карап калмаслар микән?

Көткән сүзең килмәсә,
үземне дә күрмәсәң,
турсайган иреннәрең
каргап талмаслар микән?

16.

Мәхәббәт газапларын
бер татыган кешенең
кыл уртадан икегә
ярылган була җаны.

Яртысында зәмһәрир
суыгыдай суыклар,
икенче яртысында —
тәмуг утында яну.

Ә шулай да Җирдәге
бар ләззәтләрдән артык
җанны урталай ярган
коточкыч газаплану.

17.

Иңнәремдә ике тау
йөртәмен, диеп әйтсә,
бәхәсләшмә — бик мөмкин
моның булуы шулай.

Күзләремдә мөлдери
ике диңгез, дип әйтсә,
бәхәсләшмә син — күзләр
судан яралган бугай.

Йөрәгемнең түрендә
ике Кояш, дип әйтсә,
ышана күрмә тагы —
берсе аның бары Ай...

18.

«Синең ап-ак мендәрең
әйтерсең лә кар көрте —
баш төртсәм, өшемәсме
минем бит алмаларым?»

«Бәлки, ул ап-ак көрттер.
Әмма язлар кагылгач,
җылы умырзаяга
әйләнә урман кары...»

19.

Тәңредән дә элгәре
яралган булсам, Айны
мин элгән булыр идем,
һәм тагы да әллә ни!..

Тәңрегә хәтле тусам,
синең өең өстенә
йолдызларны да күбрәк
сибәр идем жәлләми...

Төннәреңне шулкадәр
нурлы итәсем килә —
шәмдәлеңдә шәм булып
яныйм микән әллә мин?!

## *Яшьлегемнең моңлы өч хикәяте*

### 1. Илсөяр

Аны гына беркем дә
чакырмады биюгә...

Барыбыз да, бөтерчектәй, вальс әйләнгәндә,
кайберләребезнең хисе хискә,
күбебезнең сүзе сүзгә генә бәйләнгәндә,
аккош кебек ак муенлы,
иң нечкә билле,
иң төз аяклы,
иң сылу гәүдәле кыз
басып кала бирде ялгыз.

Трубалар җиз тавышын сызды.
Вальс арты вальс узды...

Янындагы иптәшләрен берәм-берәм
чакырып киткән саен егетләр,
горур башы аның иелә барды,
иелә барды...

Командировка ялгызлыгы гына
этеп керткән иде мине бу ят залга.
Яңгырагач тагын бер вальс,
чакырдым аны биюгә...
Шулай җиңел,
шулай очынып,
үз-үземә шулай сокланып,
шулай көязләнеп
биегәнем юк иде минем!

Ул да ләззәтләнеп,
күзләрен ярым йомып,
җилфердәде минем тирәмдә...
Вальс тынгач,
кызлар, гадәттәгечә, бер якка,

егетләр каршы якка барып сыенгач,
бөтен залны үзенә караттырып,
шаһинә күк атлап чыгып китте.

Мин аны төннең иң карасында,
урамнарның иң караңгысында куып җиттем.
— Гафу итегез,
озата барыймчы, — дидем.
Ул сискәнеп китте...
Акрынайтты адымын...
Йа бәндә!
Тәненең төн карасы аша саркып чыккан аклыгы!
Чәчләр, күзләр һәм каш
төн карасы белән тоташ!
— Минем исемем Илсөяр, — диде ул, —
беләсезме, мине нигә
озата бармыйлар өйгә?..
Минем исемем Илсөяр.
Мине ил генә сөя...
Беләсезме мине нигә
чакырмадылар биюгә?..

Күңелемне һәм телемне
кытыклап торган бу сорауны
үземә биргәч, каушап калдым.
Ул көлеп җибәрде...
Көлүе җылы иде, моңлы...
Аннары тынды...
Аннары
күкрәгемә капланды да
пышылдады:
— Минем дә сөеләсем килә, абый,
сөеләсем килә,
үбешүләрнең серле тәмен беләсем килә...

Йомры тыгыз беләкләре
муенымны көйдереп алды...

— Сез, абый, безнең Буада
бер дә күренмәгән кеше...

Калыгыз шушында, караңгыда —
якты урам буйлап
сезнең белән килми барасым...

Һәм мин, сихерләнгән кебек, басып калдым...
Шактый ерагайгач,
яктыдан караңгыга таба кычкырды ул,
— Әй, абый,
мин бит бераз гына кылый...

Әле дә булса,
кечкенә генә район үзәгендә
ишеткән шул сүзләр
йөрәгемдә минем чыңлый...
...Бәхетлеме син, Илсөяр?..

## 2. Шомырт ботагы

Юкка гына үпкәләтеп,
назга сусаганга гына үпкәләгән булып,
язгы бакчага чыгып утырдым...

Зәңгәр күктә дә, күңелдә дә
кечкенә генә ап-ак болыт...
Шулай инде, сандугачлар күк сайрашып
яшәрбез дигән булабыз,
йөрәгебездә үстергән гөлләрдән
гөләп сузабыз,
әнә шундый —
ак болыт күк саф букет...
Һай, болыт та түгел икән ич ул күк агы,
сындырырга буй җитмәгәнгә генә
исән калган
шау чәчәктәге шомырт ботагы!

Ә мондый ботакка
заманында Аның буе җиткән иде...
Классыбыз белән сөйләшеп,
шомырт чәчәгенә чыккан идек...

Иң өстәге ботакка ымлап:
— Өзеп биримме? — дидем.
— Сузылган-сузылган, йолдызларын да чүплә, —
диде Ул, әллә юри, әллә чынлап...

— Көпә-көндезме? — дидем мин.
— Бик теләсәң, синең кулың
күк гөмбәзен тишеп чыгар,
сузылып җитәр йолдызларга...
Их син!.. Өзеп биримме, имеш...
Нинди егет сорап тора ди кызлардан...
Хәзер үзем менеп китәм дә
сиңа чәчәк бүләк итәм...
— Кыз кешегә егет алдында
агачка менүояттыр...
— Ә син күзеңне йомып тор...

Ул менде, чәчәккә сузылды...
Һәм кинәт,
Ул тотынган ботак каерылып,
чытырдап кәүсәдән аерыла башлады.
Менә шулчак мин күз йомып,
ул егыласы турга ташландым...
Һәм соңыннан өч ел буена,
институтның беренче курсын тәмамлаганчы,
ботакка ябышып кочакка кергән кызны
үпмәвемә үкенеп йөрдем...

Шулай:
Өрмәгән урындыкка да
утыртмам, дигән булабыз,
онытабыз,
юкка гына үпкәләшәбез,
һава кебек куерабыз, мөлдерәшәбез,
яшьнибез, күкрибез,
кайчакларда яңгыры да ява. —
Аның күзеннән минем кочакка
назландырыр өчен җыелган тамчы тама.
Боз булмый, була да алмый.

Шомырт чәчәге исән-имин кала.
Әнә ул ап-ак ботак минем баш очында,
өстә — кул җитмәс биеклектә.
Юк, ул шомырт чәчәге генә түгел,
ләйсән яңгырыннан калган ап-ак болыт
мәхәббәтнең аяз күгендә йөзеп бара.
Юк, алай гына да түгел —
ул гомеребез океанында
икебезне кабат яшьлеккә илткән
ап-ак җилкән кигрән кораб!

## 3. Зәңгәр чатыр

— Укы әле, — диде, —
зинһар, укып кара!
Булмаганга башка чара, калмаганга тәкать
язган җырларым бу фәкать.
Син үзең дә, шагыйрь, мөгаен,
мәхәббәткә сабышкач кына
шигырьгә ябышасыңдыр...
Болай булды бу:
командировкада кинода
табыштык та таныштык ул кыз белән.
Унынчыда гына укый иде әле.
Имтиханнары алдыннан
Толымбай урманнарыннан
җыеп кайттык ап-ак сирень.
Биш таҗлысын эзли-эзли сөйләде миңа:
унынчы «А» классыннан
аңа бер малай гашыйк икән,
багышлап шигырьләр яза икән.
Ә ул аны малайсыта...
Әйтәм бит: гашыйк булдымы кеше,
күккә аша башлый,
чүп кенә сүзе дә
шигырь булып таша башлый.
Мине армиягә алдылар,
ә Ул

шул көзне үк Казанда техникумга керде.
Ике ел ике арада кайнар хисле хатлар йөрде.
Шушы җырлар минә,
дәфтәремнән чыгып качып,
Аңа таба очты, Аңа таба йөгерде.
Ни генә юк җырларымда минем!
Бу җырларда минем тилелегем,
бу җырларда күпме хыялый сурәт,
хыялый урман, хыялый күл,
хыялый төн уртасында
зәңгәр чатыр,
кайчакларда хәтта сабый тавышы...
Армиядән мин туп-туры Казанга кайттым,
иске өйләр арасыннан фатирын эзләп таптым...
Ишек кактым.
Ярым караңгыда бер ханым ишек ачты
һәм, мине танып,
чаршау эченә кереп качты.
Кермә, диде ул, күрмә, диде ул, сыктап...
Мин хыянәт иттем, диде, сиңа...
Тиздән балам була...

Ничә ел инде күз алдымда чәчәкле чаршау
һәм чаршауда
йөкле хатынның кара шәүләсе...
Менә ничә ел узгач,
җырларымны укып карадым.
Ихлас күңелдән язганмын бит,
ихлас күңелдән.
Бу җырларым кәгазьгә түгелгән...
Кайдалыгын белмим.
Казанда юк.
Эзлисе дә килә, табасым да килми.
Үзем түгел, бәлки, җырым эзләп табар.
Бәхетсездер кебек — менә күзләренә кара...

Егет миңа рәсем сузды.
Әйе, әйе. Ул — шул,
кайчандыр мине малайсытып,

хисләр давылына ташлап киткән,
ташлап китеп, мине шагыйрь иткән
Беренче мәхәббәтем!

Башка кеше күңелендә ул тудырган хисләр
менә шигырь булып өелеп ята минем алдымда.
Минем алдымда
минем беренче мәхәббәтем хакында
саф күңелдән язылган
ят шигырьләр...

## *Көтелмәгән көн*

*(Цикл)*

### 1

Бу көн аяз булсын иде диеп,
күпме теләп йөрдем күңелдән...
Өленгеләр чагылышы булып,
тәрәзәмә яңгыр эленгән.
Мин көткән көн бүген килми калды.
Әзер түгел күңел бу көнгә...
Агымына
теләмичә кушылам —
кем белә бит, бәлки, үкенмәм.
Көн кечкенә...
Таңда — өр-яңа көн...
Үкенечләр барысы басыла...
Ә тарихта инкыйлаб була да,
килә күз күрмәгән гасырлар,
ватаннарның барлык хасияте
алмашынып куя бер таңда...
Кичә кеше ят ватанда иде,
бүген инде — туган ватанда.
Унҗиденче елда туган көнгә,
шәт, кемнәрдер йөзен чыткандыр.
Яши-яши генә аңлашылган —
килгән икән күптән көткән чор.
Ә бу көннәр, нинди булсалар да,
шул чорларның хәләл дәвамы —
чалт аязмы,
әллә җил-давылмы,
юлың бүлеп яңгыр явамы...

### 2

Ничек инде өйдә утырасың?
Бер чыланыйм әле туйганчы.

Мин самолет түгел,
телим икән,
томанда да миңа юл ачык.

Көннең болытлары күңелләргә
керә алмый, кертмим дигәндә.
Тыштан чылансам да, күңел әзер,
чаткы булса, дөрләп китәргә.

Тормышның бит олы матурлыгы
сүрән көнгә карап үзгәрми.
Яла, гайбәт томаны аша да
Дөрес күрә аны күзләрем.

### 3

— Мондый көндә кая юл тотасың?.. —
Онытыла язган танышым
су анасы кебек басып тора.
— Аяк илткән якка барышым,
ә соң үзең?
Эри язгансың ич...
— Эрер көнеммени, и туган,
минем өчен бүген яңгыр түгел,
Океан-диңгез хәтта тубыктан.
Малай туды. Беләсеңме — малай!
Күр әле син көннең шәплеген —
яңгыр түгел, туган, явып ята
минем бәхет, минем шатлыгым.
Үземне инде яңгыр юды бугай,
ә малайны — безгә юасы.
Киттек өйгә, бераз җылынырсың —
чылангансың шактый, туңгансың. —
Күлдәвекләр күзенә баса-баса,
йөгердек без аның өенә.
Яңгыр яумый.
Яңгыр сикереп бии,
яңгыр җырлый,
яңгыр сөенә...

## 4. Тост

Бүген туган һәрбер кеше
бәхетле булсын!
Әтисе дә, әнисе дә
аннан уңсын.
Вакыты белән, газапламый
чыксын теше.
Бар нәрсәгә теше үтсә —
көчле кеше!
Алга атлый белгән генә
батыр кеше,
адым саен ул кешенең
уңсын эше.
Ихтирамлап бабаларның
зур йоласын,
уң кулында алтын балдак
ялтырасын.
Аннан инде дәвам итеп
буыннарны,
бер-бер артлы тезелеп китсен
кыз-уллары.
Туры тотсын ил-халыкның
әманәтен —
гадел булсын, чыгармасын
яманатын!
Бу теләкләр ана сөтенә
сеңсен иде,
һәрбер сабый шундый сөтне
имсен иде!

## 5. Күчену

Өйдән өйгә әнә күченәләр.
Шатлык белән дөнья өртелгән —
машинадан, рояль, шкафлардан,
күз, йөзләрдән бәхет бөркелә.

Дөнья буйлап күпме һиҗрәт үткән...
Афәт булса, һиҗрәт туа ул —
кешеләрне өйдән өйгә түгел,
илдән илгә язмыш куалый.

Бер энәгә, имеш, бер сыер, дип,
туган илне ташлап киткәннәр,
кайталмагач,
туган илдән килгән
кош эзләрен ятып үпкәннәр...

Өйдән өйгә энә күченәләр,
ил эчендә, шәһәр эчендә.
Шатлык төяп чаба машиналар,
көндез чаба,
чаба кичен дә...

### 6. Эчке шатлык

Мин шатланам...
Мин балкыймдыр кебек,
балкуымны тоям йөземдә.
Ә карасам —
йөзем, күзем кырыс.
Аптырашта калам үзем дә.

Заманнанмы,
үземнәнме?
Белмим...
Тик еш тоям шундый чагымны —
эчке шатлык миндә тулып ята,
ә йөземдә кайчак чагылмый.

### 7. Күп булды

Дөньяны, тормышны сәбәпсез
каһәрләү, хурлаулар күп булды.
Сүз раска чыксын дип, матурын
яшерү, урлаулар күп булды.

Яндылар бүрекләр ялкынлап.
Ояттан йөрәкләр ут булды...
Ә тормыш — яхшыдан яхшыга!
йа дөнья,
гөнаһлар күп булды.

## 8

Урамнарда афәт эзләре юк.
Кешеләрнең тыныч йөзләре...
Бер уйласаң, дастаннарга лаек
ил-көндәге шушы үзгәреш.

Бер уйласаң, бүгенге кешенең
көннән алган олы хасияте —
яшереп булмый торган бәхете булу,
яшереп була торган хәсрәте...

## 9

Мизгел, тукта, син гүзәл...
*Гёте, «Фауст»*

Һәрбер мизгел, һәр көн, атна, ай
теләгемчә гүзәл булса да,
мин Фаустның соңгы сүзләрен
кабатламамын күк... Бусага
идән белән тигез — иртәгә
өй күрәсе таңга, көннәргә...
Өметемне шушы таң аша
мин киләсе көнгә җибәрәм.
Ул көн килер!
Ләкин анда да
мин Фаустның соңгы сүзләрен
кабатламам. Бөтен кешеләр
кабатлагангача түзәрмен.
«Бәхет килде» дисә бер кеше,
бәхетмени илгә, халыкка?..

«Бәхет килде» дисә бар кеше,
өнсез калырмын күк шатлыктан.

**10**

Илгә карап үзгәрәләр көннәр.
Ил үзенчә бизи
йә боза...
Хәсрәтлеләр күз яшьләре итеп
килгән көнгә кайгы тамыза.
Бәхетлеләр
көнне бәхет белән
сугаралар — бәхет таралсын.
Көннәр кешеләрдән тәрбия ала.
Көннең күңеле һәрчак нарасый.

**11**

Янасы да әле, янасы —
без янудан кабына тора
көннең якты, яңасы!

Ныгыйсы да әле ныгыйсы —
яман көннәр килә калса,
безгә бәрелеп егылсын!

Балкыйсы да әле, балкыйсы
җиргә йокканчыга чаклы
байрагымның ал төсе!

## *Каурый каләм*

*(Цикл)*

### 1. Шигырь турында шигырь

*Шамил Анакка*

Шигырь күңел чәчәге генә булса,
Рудакиның якты күзләрен
караңгылык чокып атмас иде;

Пушкинны
алтын бөркетле гайбәт
дуэльгә тартмас иде;

Тукай ишеген,
Газраилдән узып,
жандармнар какмас иде;

Гарсиа Лорканы,
лимон агачына терәп,
франкочы атмас иде;

Назыйм Хикмәт йөрәге
сөекле Истанбулыннан
бик еракта ятмас иде...

Чәчәк өчен генә Җирдә
беркемне дә беркайчан да
үтергәнне тарих белми!

## 2. Кол Гали монологы

*Тавил Хаҗиәхмәтовка*

Болгар-йорт илтабары,
олы мирасы итеп,
миңа өч ук калдырды:
берсенең очы тимер,
берсенең очы көмеш,
берсенең очы алтын.

Болгар-йорт илтабары,
төп васыяте итеп,
өч киңәшен калдырды:
тимер укны алга ат,
көмеш укны өскә ат,
алтын укны аска ат.

Салып туйра җәягә,
аттым мин тимер укны.
Ватаным җирләренә
аяк баскан дошманның,
аттым да, җанын алдым.
Булат кылыч бирделәр,
ил сагы бул, диделәр.

Салып туйра җәягә,
аттым мин көмеш укны.
Парын җуйган аккошның,
канатыннан каерып,
бер каурыен алганмын.
Ап-ак кәгазь бирделәр,
җырчыбыз бул, диделәр.

Салып туйра җәягә,
аттым мин алтын укны.
Яу үткән җиргә чумып,
угым күздән югалды.

Аксакаллар килделәр,
кулга сабан бирделәр,
сөреп эзлә, диделәр.

Мин һаман ил сагында,
мин хакыйкатьне җырлыйм,
туган кырларым сөрәм.
Өч илаһи көчемне
бергә туплауда гына
мин бәхетемне күрәм:
кылыч, каләм һәм төрән!

### 3. Пушкинның гүр маскасы

Гөнаһлыны изге иттерергә
теләүчеләр әле табылыр...
Тарихның да, безнең колакның да
ялганнарга сусау чагыдыр...
Пушкин җирләрендә һәр манзара,
һәрбер адым аһлы, көн аһлы...
Гипс иреннәре ачылыр да,
пышылдар күк: «Әйе, гөнаһлы...»
Тәне түгел, җаны сызлаганын
күреп торам гипс аша мин.
...Натальяны мактый: «Ул — гөнаһсыз».
Мин аңламыйм... Ахры, шашамын...
Еллар узган саен, кан өстенә
куна, куна тарих сөреме.
Ә шулай да йөрәк белән күрәм
шагыйрь үлеменең серен мин.
Таш масканың тере газапларын
карыйм, карыйм ничә кат килеп...
Ядрә генә, Дантес кына түгел,
гайбәт түгел Пушкин катыйле —
хыянәттер...
Өмет хыянәте...

## 4. Лермонтов

Тенгинского пехотного полка поручик Михаил Юрьев Лермонтов 27 лет убит на дуэли 15-го июля, а 17 погребен, погребение пето не было.

*Запись в метрической книге Пятигорской Скорбященской церкви за 1841 год, часть III, № 35*

Гөнаһлары, бәлки, булгандыр...
Бер гөнаһсыз булмас шагыйрьләр —
түмгәккә дип кенә кизәнеп,
зур тауларны ишкән шәп ирләр:
тәхетләрнең чаты чатнаган,
күз нурыннан купкан юшкыннар...
Һәм ачылып киткән, күренгән —
кем таш аткан бөек Пушкинга!
Даһиларны яла явыннан
даһи гына бары аралый.
Менә гөнаһ — шигъри намусны
якларга да хәтта ярамый!..
Ә кем база — ала җәзасын.
Аллалардан күреп, җен аза —
Лермонтовны җиргә тыкканнар,
укымыйча гына җеназа —
ахирәттә утта янсын, дип!
Янды шагыйрь, янды шулкадәр —
яна-яна яңа йолдыз булды,
шәһит китеп, булды пәйгамбәр...

## 5. Тукай

Тукай таптап тузан иткән ташлар
дуен булып яткан Җаекка...
Һәм саеккан Җаек... Йөзмәс булган
шагыйрь кереп баскан каеклар.

Ник уалган димсез бут ташлары?
Тукай шулай авыр булганмы?
Ә бармы соң
Җирдә
җиңел
шагыйрь —
шагыйрь иңнәрендә ил гаме!

Казан ташы, бәлки, күтәрер дип,
Иделенә кайткан әйләнеп...
Көтмәгәндә Тукай җиргә иңгән,
иңнәренә алгач галәмне...

Күңел кошы калган бу дөньяда —
тар дөньяга ничек сыясың?!
Ул шагыйре кебек ятим түгел —
һәр йөрәктә аның оясы!

### 6. Дәрдмәнд

Маңгай җыерчыгы анаң булган...
Җыерчыкка
кайгы катыш акыл тулган.
Маңгай җыерчыгы анаң булган...

Алмагачтан алма ерак төшми:
ут баласы — чаткы,
сыныкы — җир чыгы,
ә син, Дәрдмәнд, үзең
төпсез тирән маңгай җыерчыгы,
зур бер илнең
моңы, сагышы,
өмет тавышы
тулы маңгай җыерчыгы!..
Алмагачтан алма ерак төшми...

Шундый җыерчыклы маңгай нәрсә?
Шундый маңгай йөрткән ил нәрсә?
        Нинди силләр күмә алыр икән,
        толпар тоягына эз уеп, ил
        гасырларга толпар җибәрсә?..
Андый илгә вакыт, сил нәрсә?..

### 7. Кайту

Күзләремне йомам да, мин
ике дөньямны кушып күрәм —
эчкесе белән тышкысын...
Мин аларда күпме каршылыклар,
тарткалашлар таптым —
сынып китә язды рухым,
чак чатнамый калдым теш кысып...

Көннәрдән бер көнне шулай
күзләремне
        тышкы яктан
                нидер какты...
Яшендер дип ачкан идем —
күзләремә кыю Җәлил кайтты!

Күзләремне йомам да, мин
ике дөньямны кушып күрәм
ачык итеп, якты итеп...
Икесе дә эләгә бераз өтек,
икесе дә эләгә бераз китек...
Сынып китә язды рухым...

Көннәрдән бер көнне шулай
күзләремне
        эчке яктан
нидер какты.
Утлы яшьтер дигән идем —
күзләремә туры Тукай кайтты!

**8. Дуэль мәйданчыгы**

Машук башына менмәдем,
йөрәгем ашкынса да,
итәгендәге вак ташлар
мине рәхимсез санар.

Дуэль мәйданына бастым,
йолдызга торам тиеп —
Лермонтов егылган урын
Эверестлардан биек.

Бу төштән дөнья күренә,
исә йолдызлар җиле,
халыклар өне яңгырый,
давыллар аша килеп.

Биредән бер гасыр ярым
калынлык линза аша
шагыйрь йөрәген күрәм мин...
Каны миңа тоташкан...

Җырлыйм мәңгелек яшәүне,
мең кабат кайта-кайта...
Лермонтов җан биргән җирдә
минем дә шәүләм ята.

**9. Биштау**

Биш башыңа биш ак бүрек
элеп китәм мин.
Үтенәмен: кия күрмә,
зинһар, бүтәнне.

Ил исеменнән сүз әйтергә
лаек карт сыман,
һәр кояшны ак бүрегең
салып каршыла.

Икенче бүрегеңне сал
син җылы җилгә —
салкын алып килмәгәнгә
чәчәкле илгә.

Өченчесен салырга син
уйласаң әгәр,
былбылга сал — сайравында
юк хәтәр хәбәр.

Ай каршында дүртенчесен
сал, биек кордаш, —
Җирнең дусы булган өчен
һәр авыр чорда.

Ә бишенчесен саласың
һәр көн, әлбәттә,
бөек Лермонтов җан биргән
утлы сәгатьтә.

### 10. Шигырьләрне байрак итеп...

Шигырьләрне байрак итеп
күтәрәсе килгәндә,
күз алдына сез басасыз,
Ватанны сөйгән шагыйрьләр!

Сүзгә хәнҗәр үткерлеге
иңдерәсе килгәндә,
сезнең җырлар искә төшә,
дошманга үчле шагыйрьләр!

Хисләргә Җир җылылыгы
сеңдерәсе килгәндә,
сезнең күңел күздән кичә,
халыкны белгән шагыйрьләр!

Иманда калкан ныклыгы
булдырасы килгәндә,
сезнең йөрәк үрнәк була
безгә, коммунист шагыйрьләр!

Шатлыкка җилләр канаты
бирергә теләгәндә,
сезнең канатлы куаныч
безгә өлге, шагыйрьләр!

Шигырьләрне байрак итеп
күтәрәсе килгәндә,
без сезнең сафка басабыз,
Җәлилләр һәм Кәримнәр!

### 11. Җәлил туган җирдә

Һәрвакытта минә шулай була —
рух көчәя, сагыш сүрелә,
бастым исә бөек кешеләрнең
туган яки үлгән җиренә.

Тамыр җәям кебек шул туфракта,
алам кебек шушы җир сутын.
Ул мәңгегә минем канда калыр —
җилгәрсен җил,
яусын яу уты...

Үсәм кебек изге Ватанымның
яшәү көчен туплап йөрәктә...
Тирәклектә һәрбер тирәк — терәк,
әвереләм кебек тирәккә...

Ябалдашым минем дуслар өчен
яшел ялкын булып кабыныр...
Килә калса дошман,
башын ватар,
тамырыма минем абынып.

## 12. Райнис музеенда уйлану

Халкының диңгездәй күңеле киңлеген
сыйдырган китабы битенә...
Шагыйрьнең өстәле, бүлмәдә булса да,
иркендә булган шул,
иркендә.

Шагыйрьгә ялкыннар ерактан күренгән,
дулкыннар калдырган көек тә...
Райнисның бүлмәсе, кечкенә булса да,
биектә булган шул,
биектә.

Ялкыннар җитмәгән, дулкыннар упмаган,
Райнисны алмаган кылыч та...
Шагыйрьнең йорт-җире, давылда торса да,
тынычта булган шул,
тынычта.

## 13. Рәсүл Рзага сораулар

Дулый дулкын,
кага дулкын,
ашый кыя йөрәген.
Диңгездә дулкын хисапсыз...
Күз яшендә кимрәкме?
Тау ярыла,
кыя уба —
ачыла Җир ярасы.
Тауларда упкыннар төпсез...
Күз төбендә сайракмы?
Кипкән күз яше тозында
нур ярыла мең төскә...
Һәр төс, мең мәгънә уранып,
ничек сыя бер хискә?

Шатлык яше,
кайгы яше
бер үк җыерчык уя...
Дулкыннар да күз яше күк —
ничек аера кыя?
Кайвакытта дулкын тына,
өметсезлеккә бата.
Шул чагында ник аңа тау,
ачуланып,
таш ата?

Дулкыннар кабат уяна,
кыядан ут чыгара...
Ә күз төбендәге тамчыда
күпме җырлык җегәр бар?

## 14. Кәбисә

*Шагыйрь Әнвәр Давыдов истәлегенә*

### 1

Шагыйрьләр китәләр...
Йөрәкне өтәләр...
Кемнәр соң тегендә
аларны көтәләр?

Исәннәр бәхетен,
кайгысын җыр иттең...
Ашыктың син кая?..
Ник киттең?..
Ник киттең?..

Ник киттең?
Ник киттең?
Ник киттең? Югыйсә
бер артык көн бирде
ич сиңа кәбисә.

Көннең дә җайлысын,
җәйгесен, асылын...
Сиңа дип нур җыйды
җирдә һәр яссылык.

«Җырга — чор төсе!» — дип,
һәрвакыт тик нурга
ярата идең бит
каләмең манарга.
Ник киттең?
Ник киттең?
Ник киттең? Югыйсә
бер артык көн бирде
ич сиңа кәбисә.

Картларга син — яшьтәш,
Яшьләрдән яшьрәк...
Гафу ит! Алдыңда
күз яшем яшерәм.

Елаулар — куәтсез.
Күз яше — тик тамчы —
терелтми... койсаң да
җир диңгез булганчы.

Күз яшьсез иде бит
синең үз йөрәгең —
күмердә тамчы су
кемнең бар күргәне?

«Калыпка сыялмас
ритмда яшәгән,
шашынып җырлаган
һәм сабыр яшьнәгән

кешегә күз яшьләр
күрсәтү ул — язык», —
дип, кабер ташыңа
куясы бар язып.
Килгәннәр күрсеннәр
инде юк кешене...
Килгәннәр китсеннәр
еламый яшәүнең
мәгънәсен төшенеп!

### 15. Яңа Шүрәле

*(Булган хәл)*

Казанда Шүрәле йөрде,
күтәреп имән бүрәнә.
Һәм кычкырды:
— Әй, шагыйрьләр,
күзегез мине күрәме —
ник чыкмыйсыз, җыелмыйсыз?
Килдем изге ният белән.
Апушның мин ничек Тукай
булганлыгын яхшы беләм!
Чыкмасагыз — хәзер китәм...
Кем өлгеррәк, ашыгыгыз,
шуны яңа Тукай итәм.

Һәм Шүрәле тирәсендә
шагыйрьләрнең барчасы да —
Буа һәм Балык Бистәсе,
Уфа, Казан, Арчасы да...
«Мине!» «Мине!» «Мине!» дибез,
этешәбез, төртешәбез,
атланабыз баганага,
таеп, егылып төшәбез.

Барыбызның да кулында
алтын шарлы затлы каләм,
кесәбездә — төрле диплом,
уебызда — лазер... Галәм...
Ә Шүрәле бүрәнәсен
дөпелдәтте тротуарга
һәм тотынды бармакларын
шыртлаткаларга, уарга.
Диде Шүрәле:
— Артыктыр
кети-кети уйнап тормак,
алыгыз балта,
ярыгыз ярык,
кысылырга әзер бармак...

Тәмам итеп шуны әйтим:
янә бер Тукай тумады —
арабызда балта тота
белүчебез табылмады.

### 16. Тукталышларда

Бер генә яхшы шигырьне дә
тукталмыйча укып чыга алганым юк...
Һәм шул тукталышларда мине
иң гакыллы әңгәмәдәш көтеп тора:
астын өскә Җирнең айкыйбыз,
гөнаһларны савапларда чайкыйбыз,
сөенечләрдә чәчәк атабыз,
көенечләргә кереп янабыз,
акыл алабыз үкенечләрдән...

Кем соң син, әй, әңгәмәдәш:
шигырьләрнең серле иясеме,
әллә... юк, юк, булмас... үземме?

### 17. Иң ләззәтле

Иң ләззәтле сөю
шигырьдәндер —

шигырь — тәндер,
шигырь — җандыр.
Шигырь — сөттер,
шигырь — кандыр...

Иң газаплы үлем
шигырьдәндер —

дарусыз, уксыз,
балтасыз, утсыз
үтерелә җан,
сөткә кушыла кан,
исән кала тән...

* * *

Мин бәхетемә ышанам,
чөнки өметем уяу,
баш өстендә Дамоклның
кылычы диеп уйлап,
богауга тыкмыйм үземне:
мин — җил-җиләс,
мин — бөркет,
мин — күбәләк, мин — бер чәчкә,
кырга төшәсе бөртек,
мин — якты җыр,
иркен шигырь,
үртәшү-көлешүләр,
мин — Космос күзенә җем-җем
сирпелгән төнге шәһәр.
Мин — мәхәббәт, татлы сагыш,
гашыйкларның куш анты,
хатын-кызлар буйга узу
киләчәккә ышанып!
Мин бәхетемә ышанам,
һәр яңа көн —
бәйрәмем.
Баш очымда кылыч түгел,
кояш тора әйләнеп.

## *Шатлыгым күп*

Шатлыгым күп —
бүлешәсем килә...
сәхнәләрнең менәм түренә.
Мин күргәнне сез дә күрәсез ич —
Ватаныбыз
        һаман
                үр менә,
бер-бер артлы биеклекләр яулый
заводларда, фәндә, кырларда,
торган саен тормыш матурлана,
кеше көнгә лаек җыр таба!
Җирне ныграк аңлый бара йөрәк,
күңелләрдә арта чисталык,
Хезмәт белән Намус —
бер җигемдә,
берләшәләр көч һәм осталык!
Иң беренче бишьеллыклар биргән
күркәм гадәтләрнең чаткысы
бүген
                гигант утлар булып дөрли —
йөзебездә шуның яктысы.
Һәм шатлыгым минем
                менә шушы —
Ватаныбыз
        һаман
                үр менә!
Шул үрләргә басып менәрбез без
бәхетебезнең якты түренә!

## *Илнең җылы сүзе*

Җылы сүздән күңелдәге
суыклар шартлап сына,
матур хыял шытып чыга
җылы сүз җылысыннан.

Кешенең арта куәте —
шакката үз-үзенә:
кара кырны алтын иткән,
ашлап җылы сүз белән!

Кояш артык пешергәндә,
җылы сүз — болыт кебек,
кырларга кырау янаса —
тылсымлы толып кебек.

Күрдем: Зәйнең ташлы кыры
бик аз бирәм дисә дә,
авыр башаклар күтәргән —
шул җылы сүз тигәнгә!

Туфрак могҗиза тудыра
игенченең эзеннән,
Ә игенче кодрәт ала
илнең җылы сүзеннән.

## *Бодай кырлары өстендә*

Уңган бодай басуларын
күргәч, әллә нишли күңел —
иркенәя офыклары,
биегәеп китә күге,

башаклар төсле Кояштан
аңкый көләч калач исе,
күз алдында көмеш Айда
зәңгәр чәчәк чыга үсеп,

йолдызлары якыная —
басып бармак очларыңа
сузылсаң, ихтимал, берсен
уйнатырсың учларыңда.

Гаҗәеп матур манзара!
Хыялмы бу? Әллә чынмы?..
Чү! Йолдызлар арасыннан
килде кебек тимер чыңы...

Аһ, һич булмас андый гөнаһ!..
Ышанмаслык юк эштер ул —
бодай кырлары өстендә
йолдызларны сугыштыру!..

Табында хәтта яман сүз
сөйләү хәрәм! Менә канун!
Ә иген кырлары — табын,
һәм өсте сөттәй пакь аның!

## *Колхоз председателе*

*Зәй районының яшь*
*колхоз председательләре*
*Госман Муханов һәм*
*Ринат Фәрдиевкә*

Иң матур, саф хыялларын
йөрәктә йөртә авыл:
һәрвакытта авыл булып
каласы килә аның.

Эчтән-тыштан үзгәрсә дә
заманга буйсынып ул,
саклап каласы килә бик
тургайлы моңсулыгын,

әтәчле көмеш таңнарын,
әкиятле биек күген,
эчкерсез сертотмаслыгын,
тату гаиләлеген,

авылга хас барлык ямьне —
кеше, йолдызлар гизеп
кайткач, кабат искә алсын
кешелеклек нигезен!..

Йөрәктә менә ниләр бар...
Әле барсы да түгел!..
Ә авыл йөрәге бүген —
колхоз председателе!

## *Игенче бәхете*

Күккә карап бәхет өмет итмә —
йолдызлары ерак,
салкыннар,
болытлары аңлаешсыз йөзә —
буйсынганнар серле шаукымга...

Кирәк чакта Кояш —
яңгыр ява,
кирәк чакта яңгыр —
тамчы юк!..
Синең тирне эчкән ашлыкларны
яшенле боз килеп камчылый...

Һәм җиргә дә карап бәхет көтмә,
бушка гына бирмәс — саран ул!
Юмартлансын дисең икән туфрак,
алтын булсын синең сабаның,

җылы булсын аның төрәннәре
камыр баскан хатын учыдай...
Игенченең бәхете кара җирдә
һәм төрәннең якты очында...

## *Казан урамнары*

Ничә тапкыр мин урадым икән
Казанымның һәрбер урамын!..
Тик һаман да, ташларына бассам,
уйларыма батып торамын.

Бер могҗиза Казан урамнары!
Көндәй ачык алар, төндәй сер!
Кайсы таштан Тукай тавышы чыгар?
Кайсы таштан Такташ эндәшер?

Коймаларның чуен челтәрләре
чәчәк ата кинәт — чың ага...
Капкалардан якты бүгенгегә
олпат ирләр атлап чыгалар.

Казан буйлап — тарих адымнары...
Йөрәгемдә бөек яңгыраш:
адымыңны безгә кушыйм дисәң,
ил хакына бүген ян, көрәш!

Тагын ничә мин урармын әле
Казанымның һәрбер урамын!
Шуны беләм: мәңге-мәңге тынмас
хисләремнең якты бураны.

## *Чуваш җыры*

*(«Оч-оч, кәккүк»)*

*П.П.Хузангайга*

Чабаксарга килгән саен миңа
дуслар яңа җырлар өйрәтә —
чувашларның ничә көе инде
татарлашты минем йөрәктә!

Мин аларны кайтып өйдә җырлыйм...
Үзем өчен генә...
Уйланып...
Чуваш җыры Идел кебек тирән —
чоңгылында уем буйламый.

Чуваш җыры карурмандай серле.
Йөз мең сукмак сине чакыра
әллә кая,
сихри аланнарга —
хыял яши торган чатырга.

Кәккүк булып, урман үзәгендә
аттырасы килә кырык таң...
Кош буласы килү матур да бит,
кәккүк булып калу куркыта...

Йөрәк аша моңлы тетрәү уза,
кырлар аша тургай узгандай...
Нинди җырлар!..
Беренчесен аның
син өйрәттең, остаз Хузангай!

## *Буа ягым — тау ягым*

Карлы дигән инешнең
агышлары килешле.
Дулкынынннан бер җыр оттык
сез дусларга килешли:

Буа ягым — тау ягым,
якты янсын маягың,
күркәм эшкә,
кайнар хискә,
тапкыр сүзгә бай ягым!

Зөя буе тал-тирәк,
сандугачсыз тал сирәк,
сандугачкай бер җыр җырлый,
отып калырга кирәк:

Буа ягым — тау ягым,
якты янсын маягың,
күркәм эшкә,
кайнар хискә,
тапкыр сүзгә бай ягым!

Җиребезгә ямь өсти
ашлыкның алтын төсе.
Хезмәт җыры булып яңгырый
кырларның гөрелтесе.

## *Түзеп булмаслык юксыну*

Диңгезендә дулкын җитми,
болытларга дым җитми...
Ярга яткан балык кебек,
никтер миңа тын җитми.

Кояшка җылылык җитми,
серлелек җитми Айга...
Җилкән киергән — көймәм йөзми...
Утырам, ахры, сайда.

Суга ут төртәсе килә,
Кояшка — су сибәсе,
тауга бик каты тибәсе —
ишелеп төшсен түбәсе...

Күңелдә бушлык давылы...
Үз төшенә моңаю...
Түзеп булмаслык юксыну...
Сагынудыр, мөгаен!

* * *

Керфектән тотып диңгездән
мине тартып чыгарды
туган якны сагынуның
күзгә тулган чыклары.

Ярдагылар күрмәделәр
сызлап аккан хистәшне —
бер үк төстә, бер үк тәмдә
диңгез белән күз яше,

ләкин диңгездән җылырак,
кайнаррак кызган таштан —
Диңгез Җиргә, ә күз яше
янган җанга тоташкан.

Ә зурлыгына килгәндә,
зурлыкны давыл сыный:
диңгез сыя ярларына,
күз яше күзгә сыймый.

Чыгып капландым ташларга,
янәсе кызсын аркам...
Ак уйларым ярга сипкән
соры ташлардай таркау.

## *Картлар ансамбле*

«Яшьләр җырлый,
яшьләр бии,
картлар акыл өйрәтә...»
Дөрес бу!
Дөрес тә түгел!
Тау илендә — бигрәк тә.

Сөйләгәннәргә ышансаң —
ышанмаска сәбәп юк —
йөздә генә егетлекнең
җитә асыл сәгате.

Ә йөз унда ачыла, ди,
ирләрнең чын тавышы...
Менә бит ул таулар булу —
барысы да тау эше!

...Җырлый картлар ансамбле...
Әллә җыр...
Әллә үлән...
Әллә таулар,
әллә күкләр
сөйләшә синең белән!

...Бии картлар ансамбле...
Хәрәкәтләр серләшә...
Аларда бөркет очышы,
ат чабышы берләшә.

Ә җитмеш яшьлек «малайлар»
әргән тарта
көй рәтләп...

Йөз яшьлекләр җырлый, бии —
шулай акыл өйрәтә...

* * *

Ак болытлар аръягында
күк күкри.
Атмый гына...
Менә ышан син болытның
тып-тыныч аклыгына!..

Һәм кинәт күзләр чагылды
яшене яктысыннан...
Хәзер бик күп матур нәрсә
Троя аты сыман...

## Һаман арта

Тау һавасының сихәте
нихәтледер —
анысын белмим, диңгезнеке
сихәтледер:
якты хисләрем ныгыды —
караларын
тиз баш калкытмаслык итеп
яралады.
Күкерт кебек кабынып китмәм
елдырымнан,
вак-төякләр чыгаралмас
чыгырымнан...
Тик бер генә авыр нәрсә
һаман арта —
туган якны сагынудан
җан авырта.

* * *

Сизмичә дә җыр башлыйм.
Ярга сыймаган сулардай,
йөрәктән тулып ташый.

Җырлар йөрәктән ташый...
Йөрәк мәңге үз булгандай,
җыр да гомер юлдашы.

Җырлар — гомер юлдашы.
Йөрәкне тибешле иткән
кайгы, шатлык кордашы.

Кайгы, шатлык кордашы...
Җыр — шатлыкның һәйкәл ташы,
кайгының кабер ташы.

* * *

Кем язса да — туган телен
мактап язар...
Һәм шул телдә кайчак язар
сап-сай әсәр...
Төссез әсәр телне хурлар,
ямен урлар.
Яхшы әсәр, яхшы улдай,
телне зурлар!

## *Поэзия*

Никахлаштык яшерен генә...
Беркемнең фатихасын
сорамадым һәм алмадым...
Гомер буе туй ясыйм.

Һәм йөрәктә гомер буе
илаһи мәҗүсилек:
тынмый давыллар, йолдызлар,
чәчәкләр мәҗлесе.

Үпкәләүләр, үкенүләр,
нәфрәт, сөю, күз яше,
өмет, каргыш, ярлыкаулар...
Мин хәзер шулай яшим!

Сер идең син, чыктың тышка
йөрәккә капкан уттай...
Безне мәңгелек яр итеп
никах укыды Тукай.

## *Шул дым*

Ничә меңдер сүзләр,
ничә елдыр
миндә ята алар сер булып...

Яктылыкка сусагач кына сүз
җиргә шыта якты җыр булып.

Уяна сүз,
йөрәк багларыннан
кояшына таба юл суза.
Кайдан килә аңа мондый тоем,
әкияти көч биргән бу сусау?!

Һәрбер сүзнең
һәрбер авазында
җан орлыгы бардыр тумыштан.
Һәм күңелгә кайчак
күзьяшь тама...
Җыр шытарга
шул дым
булыша.

* * *

Тукай таптап тузан иткән ташлар
дуен булып яткан Җаекка...
Һәм саеккан Җаек... Йөзмәс булган
шагыйрь кереп баскан каеклар.

Ник уалган димсез бут ташлары?
Тукай шулай авыр булганмы?
Ә бармы соң Җирдә җиңел шагыйрь —
шагыйрь иңнәрендә ил гаме!

Казан ташы, бәлки, күтәрер дип,
Иделенә кайткан әйләнеп...
Көтмәгәндә Тукай җиргә иңгән,
иңнәренә алгач галәмне...

Күңел кошы калган бу дөньяда —
тар дөньяга ничек сыясың?!
Ул шагыйре кебек ятим түгел —
һәр йөрәктә аның оясы!

## *Тукай соравы*

— Барын алдан белеп тора,
күреп тора барын да:
ни чыгасын язмышыңа,
ни кирәсен карыңга,
Җирнең астын, күкнең өстен,
тереклекнең ниятен,
йолдызларның хәрәкәтен,
кешенең хиссиятен,
ташларның ком булачагын,
бөртекнең — алтын бодай...
Һәркайда бар, һәркайда бер,
барлыкның аңы — Ходай...

Хәлфәнең шушы сүзләрен
тыңлап торган да Тукай,
күз күтәреп сорау биргән,
ә Тукайда сүз уктай:
— Кодрәте чиксез булып та
ничек күрми калган ул
Адәм һәм Хавва гөнаһын?..
Менә шуны аңламыйм...

# *Җырлар яна*

1

Бер җыр язар өчен меӊ җыр
яктылыгы кирәккә
мин бүген җырлар яндырам,
өзеп алып йөрәктән...

Учак яна... Янган саен,
күӊел карала бара —
җырны көл иткән учакныӊ
ялкыннары кап-кара.

2

Бер җыр язар өчен меӊ җыр
җылылыгы кирәккә
мин бүген җырлар яндырам,
өзеп алып йөрәктән...

Учак яна... Янган саен,
үзәккә үтә салкын —
бозлы икән җыр янганда
шатлык татыган ялкын.

## *Тамгалы атом*

Физикларның лирикага
килгән еллары иде...
Ат алган шагыйрьләр ул чак
көнче юлбарыс иде.

Өзгәләдек лирикага
тыгылучы башларны,
көчлеләренең каләмен
чәйнәп-чәйнәп ташладык.

Эзәрлекләдек бакчага
ялгыш керүчеләрне —
шигырьдә тамгалы атом
булып йөрүчеләрне.

Үзебезнең шундый атом
буласы килде бугай...
Ә карасак, инде күптән
андый шагыйрь бар — Тукай.

Һәрбер күңел нейтронын
ул үзе тартып тора...
Тик ватылмый, тик шартламый,
ул ныгый, артып тора.

## Үз дулкынымны көтәм

Кайнаган диңгез ярында
үз дулкынымны көтәм...
Килсен генә — җилкән кереп,
әллә кайларга китәм.

Ничек танырмын дисезме?
Ул мине үзе таныр:
күзе зәңгәр, күңеле ак,
дип әйтеп, тартып алыр.

Башка җирләр, башка җилләр
миңа һич кирәк түгел —
бар байлыгын диңгезенә
бирергә тели күңел...

Йөрәкнең санап тибеше
ярсыта, ашыктыра...
Үз дулкынымны көтеп мин
өметтә басып торам.

Ул килер... Бәлки, көттерер,
бәлки, калыр соңгарак...
Ярыннан кубар да кораб,
китәр кояшка карап...

* * *

Бакча бакча булсын өчен нәрсә кирәк?
Җимеш биргән бер-ике агач,
өзеп кабарга бирәр җиләк,
кояштан ышыкларлык күләгә,
качып үбешерлек куыш,
учка сөял салдырырлык түтәл,
гыйбрәтләр сөйләүче күрше
һәм... бүтән берни кирәкми...

## *Яшәү гармониясе*

Бер карт җырлый...
Һәм аңарга
кушылды сабый тавыш.
Грузинча мин берни белмим,
ә җыры шундый таныш,
әйтерсең үзем белмәгән,
ә җаным күптән белгән
ширбәтне мин тәүге тапкыр
эчәм диңгезе белән.
Балачак исемә төшә...
Алдагым уйландыра...
(Үткәннәр — тәгаен эштән,
киләчәк — уйдан тора!)
Җыр — бер агым,
ә яшь тавыш
картныкына кушылмый...
Яшәү гармониясенең
сере әллә шушымы?..

* * *

Күрде ул күткән штормын —
менә ул!
Гүли!
Тере!
Тавышы, тауларга кереп,
кыялар ватып йөри...

Үзен
йокы баса никтер...
Җаны башка ямь эзли...
Әллә күңел тынычлану,
әллә чиксез гамьсезлек?..

## *Анда, таулар арасында*

Вак шигырьләр кебек дулкын...
Диңгезнең хисе кипкән —
йөрәген кузгатырлык җил
тауларга исеп үткән.

Анда болытлар куера,
анда ялтырый яшен,
анда хисләр шундый кайный —
таш агыза күз яшен!

Кыяларга, давылларга
лаек аңлашу анда!..
Ә диңгездә вак дулкыннар
вак шигырьдәй шуалар...

## *Хәтер көне*

Беркемгә дә хәтер сакламыймын...
Барысын да саклыйм хәтердә...
Мине таптап узган кара атның
тояк эзе сызлый хәзер дә.

Каты кулларымда чакта аның
күбекләнеп чергән йөгәне,
инде миңа тояк күтәрмәс дип,
хаталанып күпме йөргәнмен?!

Ул таптады... Чәчрәп аккан каным
Идел дулкыннарын аллады.
Егылулар гына коллык түгел,
мин калыктым тотып калканны.

Минем өстән күпме яулар узды.
Күпме күмде мине көл-болыт...
Әй бүгенге мескен, мәңгегә от:
яшәмәде татар кол булып!

Шуның өчен хәтер сакламый ул.
Хәтерендә саклый барысын...
Ай айгырга менеп, ап-ак юлдан
ак офыкка карап барышым.

## Ак сөлге

Ихтирамымны белгертим
Хак сүз белән:
Кунак килсә, каршыладың
Ак йөз белән;
Дошман килсә, чыкмадың
Кулын юарга,
Һәм булмадың ак төстәге
Сатлык байрак!
И ак сөлге, беркайчан да
Пычранмадың —
Күпме сөрттең гаделләрнең
Хәләл канын!
Син көрәштең сабантуйда,
Билгә яттың.
Көрәшченең гаделлеге,
Көче артты.
Көрәшләргә озатып калдың
Син ирләрне,
Сау бул, диеп, кулга кушылып
Җилфердәдең,
Җилфердәдең кызыл туйлар
Пар атында,
Әверелеп туйның бәхет
Канатына...
Җеназада син, ак сөлге,
Безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
Соңгы юлга...
Кичрешләрнең таныш сиңа
Һәркайсысы,
Илемнең һәрбер шатлыгы,
Һәр кайгысы.
Син бит үзең дә халкымның

Күңеле төсле —
Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.
Һәрбер эшнең, һәр ниятнең
Өмете — уңыш.
Кешеләрнең нияте зур,
Сөлге,
Булыш!

## Ә Казаным белә сугышны

Бомбаларны, шөкер, татымады,
Ә Казаным белә сугышны.
Иң терәп, ул Ивановоларга
Шинель өчен постау тукышты.

Хәрабәләр сагышын белми Казан,
Ләкин Казан һәрчак сугышты —
Мәскәү яны, Курск, Днепрда
Киселде аның күпме сулышы?!

Моабитта хәтта ятты Казан,
Моабитта хәтта сугышты —
Штыкка тиң каләм була алды,
Һәм җыр булып кайтты шул штык.

Күкрәгендә — йөзләгән мең яра
Обелисклар булып калыкты.
Һәм ике йөз Алтын Йолдыз яна
Казанымның йөзен балкытып...

## *Бабам сүзе*

— Бер аягы зуррак атлау
Килешә юлга чыккан иргә...
— Нигә?
— Хисләре адашканда да
Әйләнеп кайтыр туган җиргә!..

## *Татарстан әләме*

Яшелле-аклы-кызыллы
туган илем әләме.
Кул изәгәндәй җилфердәп,
ул дөньяны сәламли.

Сәламли ул һәр кешене,
һәр дәүләтне, халыкны —
ул Җирдәге байракларга
тигез булып калыкты.

Төсләренең мәгънәсен ул
беркемнән дә яшерми —
ирек, өмет билгесе дип
җилфердәтә яшелне.

Кызылны — кан һәм яшәү дип
электән таный халкым.
Кызыл төс әләмдә шатлык
билгесе булып балкый.

Ак тасма — безне бәхеткә
илтә торган тигез юл.
Ак сөлге кебек кунакчыл,
пакь сөт кебек изге ул.

Ниятебез — дустанәлек!
Куәтебез җитәрлек...
Әләмне без аңа иң саф
мәгънә биреп күтәрдек!

## *Сәйях*

1

Җир өстенә ялгыш килеп чыккан
тамырларга баскан чагында,
мин уйланам никтер халыкларның
сәйях кешеләре хакында.
Җирнең читен эзләүчеләр булган,
теләүчеләр күкне тишәргә,
диңгез суын яндырып карарга,
ә көленнән аркан ишәргә...
Кайберләре яңа утрау ачкан,
кайберләре — яңа материк,
берәүләре байлык алып кайткан,
берәүләре — яңа матурлык.
Шәһит китүчеләр күпме булган?!
Калучылар читтә тилмереп?!
Үз халкыңа бәхет юллаганда
аяу мөмкинмени гомерне?!
Бу тамыр да менә килеп чыккан —
тетелеп беткән йомшак кайрысы.
Үзе өченмени?! Аңарда бит
агачының яшәү кайгысы.

2

Мин дә тамыр... Сыртым каезланган...
Сызланамын «Татар! Татар...» дип.
Бәхет эзлим. Тапсам, үз халкыма
өлгералсам иде кайтарып.

## Җил

Ул җил минем күкрәгемә
очып кереп җиткәнче,
изге Ак бүре йөрәге
аша исеп үткән җил!

Ул җил күзем карасына
очып кереп җиткәнче,
Идел акчарлагы күзе
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем табаныма
очып кереп җиткәнче,
дала айгыры тоягы
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем кулларыма
очып кереп җиткәнче,
Алып батырның беләге
аша исеп үткән җил!

Ул җил телемә-көемә
очып кереп җиткәнче,
Орхон-Енисәй балбалы
аша исеп үткән җил!

Ул җил минем күңелемә
очып кереп җиткәнче,
анам сөтенең хәтере
аша исеп үткән җил!

Ул җил нинди җил, дисеңме?
Улым, якынгарак кил:
ул җил — минем аша үтеп,
сине татар иткән җил!

## *Киев. 1986 ел. Җәй*

В год 986. Пришли болгары
магометанской веры, говоря:
«Ты, князь, мудр и смыслен...»

*Повесть временных лет*

Днепр дулкыннарында
бер мең еллык пышылдау...
Ертык күктән кояш төшкән
пляжлар бушлыгына.

Күзем кояшкаябышкан,
колагым — дулкыннарга...
Бармы суларда таныш өн?
Бармы таныш эз ярда?

Бар ич, бар — ап-ачык күрәм
һәм ап-ачык ишетәм:
Киевка килгән болгарлар
руслардан каек көтә —

бу якка алар чыкмакчы,
мин басып торган якка...
Мин каршылашам... Арада
мең еллык тарих ята.

## «Дмитрий Донской» теплоходында

Идел түгел,
су да түгел —
ага куерган Вакыт...
Дулкыннарында кай ара
уйларым кала батып.

Уйларым артыннан үзем
тирән тарихка чумам...
Һәм әләгәм шул мизгелдә
ике сөңге очына —

Пересвет белән Чалу би...
Агыла Җиргә ал кан...
Ике сөңге арасында
булмакчы идем калкан!..

Икесе дә сынды миндә,
тәндә калды... күмелде...
Пересвет оныгы — дусым!
Безгә яшәү күңелле.

Ике баһадир егылган
урында әрем үсә.
Җилләр булып еллар исә...
Ә без — Хәтер,
без исән...

Бернинди авырту сизмим
ни тәндә, ни аңымда...
Ләкин менә, җанны ярып,
сөңгеләргә кагылма.

## *Төрки телләр*

Төрки телләр шактый аерылышкан.
Сүзләр бер үк... Мәгънә — төрлерәк...
Күрше яшәсәк тә гомер бакый,
яшәгәнбез икән бик ерак.

Кардәшлекне истә тотсак та без,
аз йөрештек хәтта кирәктә —
былбылларыбыз да сирәк кунды
йөрәктәге төрки тирәккә.

Аерылганны аю ашар, диләр...
Татар телем бик күп гасырлар,
аю-бүреләрдән таланса да,
исән кала алды асылда.

Төрки халык әгәр беравыздан
әйтмәк булса Җирдә бөек сүз,
татар теле мәгърур хорда яңрар —
ул куәтле, дәртле, җылы, төз!

Без, төркиләр, бүген шактый төрле,
юкса бер үк ана имезде...
Ләкин туплый безне изге сөттән
телебезгә сеңгән игезлек...

## *Татар иле*

I

Татар иле Татарстан,
син яңадан калыктың.
Син — рухы, көче, намусы
татар дигән халыкның.

Мең бөктеләр, мең сыктылар,
тик егылмадың бер дә,
башыңа оргач, чумдың тик
син тездән каты җиргә.

Җанлы балбал булып тордың
дәүләтләр арасында,
сикереп менәлмәдең лә
заманнар арбасына.

Арбалар тәгәри торды,
күрдең алар узганны...
Әкрен генә күмә барды
сине тарих тузаны...

II

Һәм син яңадан калыктың...
Иртә чыктылар ясин...
Әй Бөек Болгар оныгы,
тарихлы да, яшь тә син,

көчле дә син, җитез дә син —
атлан акбүз атыңа
һәм куа чык алга узган
ил-дәүләтләр артыннан.

Яшелле, аклы, кызыллы
әләмең җилфердәсен —
әй Казан ханлыгы улы,
тарихлы да, яшь тә син,

олпат та син, горур да син,
ниятең пакьтин пакьтер —
син шатлыктан елый белгән
баһадир кебек матур!

III

Табаның такырга баскан...
Ә бер адым арттарак
сине тоткын иткән чокыр —
богау кебек кап-кара...

Вакытыңны әрәм итмә,
ул чокырдан үч алып,
атлан да акбүз атыңа,
уктан тизрәк оч әле,

алга киткән дәүләтләрне,
халыкларны тизрәк җит.
Яхшылык кылу сиңа хас,
ачу тоту сиңа чит!..

Татар иле Татарстан,
син яңадан калыктың.
Син — рухы, көче, намусы
татар дигән халыкның!

## *Татар бәйрәме*

*М.Ш.Ш-кә*

Сабантуйларның саны юк!
Юк сабантуйның яше...
Сабантуй һәрбер татарның
йөрәк түрендә яши.

Яши ул могҗиза булып,
яши ул өмет булып,
әйтерсең лә чәчү беткәч
яварга килгән болыт!

Әйтерсең лә яңгыр үткәч
ялтырап чыккан кояш —
нурын, терек суы итеп,
җан тамырыңа коя.

Көне җиткәч, йөрәкләрдән
ул мәйданнарга таша.
Чишмә-чишмә куанычлар
бәйрәм булып тоташа.

Сабантуй — борынгы йола!
Бүген дә ул шул килеш!..
Шарты бер — кеше үзеннән
үзе сорарга тиеш:

хакым бармы соң бәйрәмгә,
лаеклымы мин аңа?..
Гасыр аръягында туган
бу сорау һаман яңа.

Бу сорауга татар халкы
җавабын бирә торды —
тәненнән кан акканда да,
ул икте, язды, корды!

Шулай итеп сабантуйга
яулады ул үз хакын...
һәм менә көчле кулына
язмышын алды халкым.

Язмышка хуҗа халыкның
шатлыкка да хакы бар —
ә шатлыкның Сабан туе
дигән мәгъруր аты бар.

Яңгырасын ул мәйданда,
гөрләсен һәр йөрәктә —
сабан туе һәр кешене
көр яшәргә өйрәтә!

## *Белем йортым*

Казан педагогия университетына

Болак тулып алкын сулар акмаса да,
Болак өсләп дулкынланган җилләр исә...
Гомер уза, зиһен туза икән лә ул!
Синдә булган бик күп мизгел миндә исән.

Күңелемдә бушлык туса, җаным туңса,
киләм сиңа — яшьлегемнең кордашына —
һәм яшертен, һәм сак кына кагыламын,
Белем Йортым, диварының пакь ташына,

көче беткәч, Антей җиргә кагылгандай,
һәм йөрәккә яшьлек кайта яңабаштан.
Без бит синең ташларыңа сеңеп калган
изге, җылы, якты тылсымга тоташкан!

Белем дигән тылсым аша өйрәндек без
тиз күрергә Вакыт дигән йомгак очын.
Анам — тапкан, илем — баккан, ә син минем
иң акыллы, һич картаймас укытучым.

Яшьләр килә Болак буйлап. Җилләр исә
түгәрәкләнгән чатыңны сыйпап-назлап.
Синнән чыккан һәрбер кеше яздан чыга,
сиңа кергән һәрбер кеше керә язга!

* * *

Әкрен генә барам Казан урамнары буйлап,
күзләремне иң кадерле азык белән сыйлап.

Кайбер урамнар тар — шигырь китаплары кебек,
хәтта шушы юлларны да кертү кирәк бөгеп,

йә сындырып, мичкә тыккан чакта таякларны,
өзеп калган кебек йә башларын, йә аякларын,

ләкин матур, ләкин җылы, кысан кочак сыман,
аларга минем яшьлекнең күпме сере сыйган?!

Әкрен генә барам... Аңым — баеп... Көнем — бөлеп...
Илле ел элек кенә туган мәңгелек кебек...

## *Кунакка чакыру*

Тарихтан килгән юлларны
тагы да такырлап, сез,
җәеп кочак, корып табын,
кунакка чакыргансыз.

Күрешүләр күркәм була,
ямьле була тагы да —
рәхәтләнеп без җырласак
сез чакырган табында.

Бер күрешү — бер гомер ул!
Истә тотыйк моны без.
Аңлашсын йөрәкләребез,
аралашсын моңыбыз.

Күрешүләр күркәм була,
ямьле була тагы да —
рәхәтләнеп бер биешсәк
мондый күркәм табында.

Йөрәккә тоташ юлларны
тагы да такырлап, без,
җәеп кочак, корып табын,
кунакка чакырабыз.

Күрешүләр күркәм була,
ямьле була тагы да —
рәхәтләнеп утырсагыз
без чакырган табында.

## *Империя таркалганда*

Империя чәлпәрәмә килгән вакыт...
Кыршау өзек. Ялгау әйберләре ватык.
Светофорлар кыса бары сары күзен —
барыргамы, туктаргамы — кара үзең...

Элекке илнең читендә хәтәр эшләр —
кеше тимер торбаларны өзә тешләп...
Тукран чукый черек имәннең кайрысын.
Бездә кайры астындагы корт кайгысы...

Империя чәлпәрәмә килеп ята.
Ил башлыгы тәвәккәл — пыяла вата.
Чалторт-чолтырт — олы пыяла уала,
һәр кисәге көтелмәгән форма ала.

Чатнау — юлсыз. Ә без юллы. Безнең исәп —
Татарстан кыяфәтле төгәл кисәк.
Чатнауга бирик дисәк без юл-юнәлеш,
пыялага алдан эз тырнарга тиеш...

## *Ачыш*

Гаҗәеп ачыш ясадым...
Кинәттән... Бер дә юктан...
Тукай сүзендә йакут бар,
йакут сүзендә — Тукай!

Асыл шагыйрь асыл мәгънә
асрыйдыр исемендә...
Тукай дисәм, балкып ала
асылташ хисе миндә...

* * *

Дәүләтләрдә халыклары холкы,
ә халыкка кешеләрдән күчә...
Чабуыма ут төрттеләр ничә,
ялкынында җылынмакчы булып...

Гөлләремне ташладылар йолкый.
Учагыма су сиптеләр азмы —
чишмәләрем хәтта кибә язды —
түздем —
кешеләрдә халыклары холкы.

Халыкларда кешеләре холкы,
ә кешегә тере сүздән күчә...
Сүзебезгә, телебезгә ничә
кизәнделәр үтермәкче булып.
Кала алдык һәлакәттән йолып...

Түздек —
халыкларда кешеләре холкы.

## Табын

Ничәнче тапкыр тагын
дусларны җыйды табын.
Бер сөйләшик — искә төшсен
гомернең төрле чагы.

Бер көлешик — күңелләрне
йолдызларга күтәрик,
борчуларны, болыт итеп,
диңгезләргә түнтәрик!

Сагыну нурына чумыйк,
бераз яктырып калыйк —
бер генә мизгел булса да
саф сабый булып алыйк!

Җырлашыйк җырлый белсәк тә,
белмәсәк тә җырлашыйк —
җыр бит эчкәре дөньядан
тышкарыга нур ташый.

Бизик әле дөньяны бер
табыннар яме белән —
күктән йолдыз тел шартлатсын,
җирдән үрелеп — үлән!

## *Саратов татарлары җыры*

Акчарлаклар чайкалалар
Идел дулкыннарында.
Иделдәй тырыш булырсың
синдә татар барында.

Күп давыллар үтсәләр дә,
синдә тарих әзе сау.
Син безнең туган җиребез,
әй Сарытау, Сарытау!

Инешләрең, үрләреңдә
бабайлар хатирәсе.
Гасырларның якты данын
син безгә җиткергәнсең.

Тауларыңа менеп бассаң,
киңәяләр офыклар.
Син безнең йөрәк түрендә,
үз итсеннәр оныклар,
Сарытау!

* * *

Зәһәрләнеп исә бозлы җил.
Ачу белән карый тәрәзләр
«ярый шунда» итеп төзелгән
тугыз катлы төссез кәрәздән.

Юлда кар юк. Оча тозлы ком.
Хәмер махмырыннан айнып та
өлгермәгән иске самосвал
әй сүгенә — көпчәк каймыккан.

Картон ящик килә тәгәрәп.
Чит илнеке — әнә «Мейд ин...»ы.
Хәер бирә идек үзебез...
Көтә идекмени мондыйны?!

Иске газеталар өере
тилгән кебек оча һавада.
Нидер эзли алар, Казанга
пике ясар өчен яңадан.

Кибетләрдә буп-буш чисталык,
ә чиратлар арта һаман да...
Сөйләшәләр: «Үрдәк үрәтник,
песнәк писер булган заманда...»

Сәгатенә беркем карамый.
Ул хыялда йөри кирегә...
Бүлдермәче, зинһар, бозлы җил,
бәхетлеләр яши биредә...

* * *

...Һәм без гомер сөрәбез...
Сөрә-сөрә күрәбез —
пычрак икән тирәбез,
тозсыз икән өйрәбез,
комнан аркан үргәнбез,
салкын суга өргәнбез,
кемнәрнедер кызганып,
салып ыштан биргәнбез...

Күрәбез дә күрәбез,
шырык-шырык көләбез,
көлә-көлә бөләбез,
бөлә-бөлә үләбез —
әйләнәбез көлгә без,
табынсак та гөлгә без...

Әверелик илгә без,
тузан булмыйк җилдә без,
таза әле җилкәбез —
әверелик илгә без!

* * *

Безнең барлык кылганнарны
тарих торадыр барлап...
Каеннар санын арттырдык,
имәннәрне акшарлап —
алардан, диеп, Җиргә ямь,
илебезгә яктылык...
Башка агачлар яныннан
уздык без күзне йомып...
Һәм берзаман яңгыр яуды,
юды барлык буяуны...

Иван булып йөргән татар
имам булып уянды.

* * *

Үле мәче, сынык байрак, сәрхуш бәндә
ауный ертык лотерейлар арасында...
Безнең юлга бу байлыклар сибелеп калган
илебезнең тишек төпле арбасыннан.
Без шуларга абынабыз...
Егылабыз...
Һәм торабыз... Килми ятып каласыбыз —
эзгә басып килгән буын тәкенмәсен!
Үкенечләр тулы тарих баласы без.
Намус исән безнең шуңа!
Тезләр ертык,
куллар пычрак, борын канлы
булсалар да...
Үле хыял, сынык өмет, сәрхуш әхлак
яңа гасыр аяк баскан бусагада.

## *Кәрван*

Кояш бата.
Ай калка,
җемелдәшә йолдызлар...
Юллылар алга атлый.
Нишли икән юлсызлар?

Бик авырдыр аларга,
юлдан сапкач көндезен:
кай тарафка китәргә,
юл итәргә кем эзен?

Йолдыз сүнәр...
Ай батар...
Таң атар...
Кояш чыгар...
Ни әйтерләр кәрванга
адашкан юлбашчылар?..

## Гаеп кояшта...

Кичә аяклар җирдә иделәр...
Без салган эздән ямьсез көн шыткан...
Бүген аяклар җиргә тимиләр —
Заман якадан йомарлап тоткан,
күтәргән күккә, караган күзгә...
Салырмы суга, бәрерме ташка?..
Ә бездән чәчри кичәге сүзләр:
гаеп кояшта... Гаеп кояшта...

## Берсенә дә...

Яңа Заман килә... Килә җәя җәеп...
Күзебезгә терәп ата бик күп гаеп.
Урамнарда йөри күпме тере мәет!
Берсенә дә чыкканы юк моңлы бәет,
берсенә дә!..

## *Әй замана...*

Олау әкәм-төкәм сыман,
җикеренсәк тә атка...
Көпчәк бетеп ыңгыраша,
ат та күбеккә баткан.
Олаучыны әй сүгәбез,
әрләшәбез үзара.
Ә арбабыз элеккечә —
әкәм-төкәм күк бара.
Уйланабыз... Киңәшәбез —
нәрсәдән бу, нилектән?..
Олау шуышып шуыша,
бозга тамган дегеттәй.
Ялтырады яп-якты уй,
башлар китте әйләнеп...
Дилбегәнең
уңын
сулга
алмаштырып бәйләдек!
Рәхәт булып китте безгә
(эш үзгәрә юктан да!)...
Ныклабрак бер карасак,
олавыбыз туктаган...

## *Минутлык төшенкелек*

Тартып алчы мине, йолдыз,
салчы якты ташыңа —
җирнең карасы аяктан
саркып менде башыма.

Телемә артык еш килә
керләнеп беткән сүзләр.
Якты дөньяны томалап,
томан куера күздә.

Берни дә аңлыйсы килми,
бернәрсә аңлатасы...
Бүгенге ыгы-зыгылар
ул бит Ходай хатасы...

Тартып алчы мине, йолдыз,
коткарчы каралыктан.
Ялварыр идемме сиңа,
ялварам чара юктан...

Юк, тыңлама мине, йолдыз!
Минутлык төшенкелек
бөтен узган гомеремнән
алмакчы булды көлеп.

Мин бит үзем гомер буе
суздым коткару кулы
һәм күпләрне һич мәгънәсез
үлемнән калдым йолып.

Аларның сүнгән күзенә
үз нурымны өстәдем...
Яшәвемнең, ни булса да,
үз яме һәм үз тәме.

Миңамы җебеп торырга?!
Тәнем, акылым исән!
Төшенкелекнең үрелгән
кулын елмаеп кисәм.

* * *

Ничаклы каршылык яши
икән безнең йөрәктә:
ак күгәрчен булып намус
очып чыга күкрәктән;
зәңгәр канатларын кагып,
мәхәббәт кошы чыга,
аның артыннан иярә
көнче чуар карчыга;
шатлык кошы сандугачлар
сайрашалар кавышып,
һәм ерактан «Мин дә бар...» — ди
сыңар аккош тавышы;
ябалак булып шомлану
сагаеп посып тора;
һәр үткән мизгелне санап,
соры күке кычкыра;
бөркетләр булып өметләр
мәһабәт күтәрелә,
канатлары каурый коя,
кыяларга бәрелеп;
чыгалар вак мәшәкатьләр
чыпчык өере булып —
һәммәсе белән тирә-як
һәм сулар, һавам тулы...
бар тормышым — ыгы-зыгы,
дилбегәсез тамаша.
Бер йөрәктән чыккан кошлар
бергәләшеп талаша.
Талашсыннар.
Тузсын каурый.
Туктату — үз үлемең...
Кошлар белән адым тулы,
каурый белән —
күңелем.

* * *

Югарыга үрләгәндә
аяк ышанып атлый.
Ә түбәнгә төшкән чакта
аптырый — җирне тапмый.

Җир түбәндә, тик бар аны
табалмый таптаучылар.
Рәхәтләнеп: «Җир бар!» — дия
тик үргә атлаучылар.

* * *

Шигырьләрдә минем тимер, бетон...
Шигырьләрдә минем авырлык...
Шагыйрьләргә потлап таратсаң да,
тау кадәрле артып калырлык.

Тимер ләкин һәрчак ап-ак була —
әллә кыза, әллә бозлана.
Бик беләсең килсә, шигыремә
йөрәгеңне тидер, кызганма.

## *Китмибез!*

Китмибез без, безгә анда...
*Г.Тукай*

«Китмибез!» — дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Күк гөлдерәү булып күңелләрдә
«Китмибез»е калды яңгырап.

Советларны Казан диварына
терәгәч тә китереп фетнә көз,
Вахитовлар каны ташка сеңде —
ташка сеңде катгый «китмибез!»

Йөрәкләрдән окопларга күчте,
дошман белән килде йөзгә-йөз.
Газинурлар батырлыгы булып
яңгырады кабат «китмибез!»

«Китмибез!» — дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Күк күкрәү булып күңелләрдә
«Китмибез»е тора яңгырап.

«Азат Европа»лар күңелләрне
аздырмакчы була. Безнең сүз —
корал тотып алган чикләрдән дә,
йөрәк яулап алган үрләрдән дә
Бер адым да артка чикмибез.

Һич кирәкми безгә башка һава,
башка нигез безгә — чит нигез.
кызыл байраклардан китмибез без,
яшел аланнардан китмибез.

Ил тамыры белән без тип-тигез,
сөт чишмәсе белән без игез —
сөт тамыры корган халык китә,
без яшибез әле, китмибез!

«Китмибез!» — дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Һәр күңелдә мең мәгънәле булып
«Китмибез»е яши яңгырап.

## *Кан һәм каләм*

Кыса-кыса, чормаларга заман
күпме китапларны менгерде!
Укыйм дигәннәргә якты булды
чормаларның серле эңгере.

Ярлык тагып, төрмәләргә заман
күпме әдипләрне яптырды!..
Языйм дигәннәргә диварлар да
кәгазь була алды, ак торды.

Язды татар, яза татар, язар,
укыр татар барлык язганын —
бушка китәме соң мең ел буе
җанны тазартуда казгану!

Яу кырында, зинданнарда туган
татар китапларын карагыз —
язучылар канга батсалар да,
әсәрләре керсез, ярасыз.

Мәгърур итә татар дөньясының
Тукай тоткан рухи әләме,
Муса Җәлилләрнең шәһит каны,
Исхакыйның милли каләме.

* * *

Идел өстендә көмеш ай
эленгән — китми, бармый,
дымлы комда көмешләнә
акчарлак койган каурый.

Идел суы зәңгәр төнне
ахыргача сеңдергән.
Дулкыннар иренеп кенә
йолдызларны сүндерә.

Мин торам салкын балконда,
ә өйдә җылы-җылы...
Ак түшәктә ауный-ауный,
минем шигырем җылый —

әйтерсең лә гүзәл хатын!
Минем мендәрне кочкан.
Сөюгә багышланганга,
ул җылый куанычтан.

Идел өстендә тулган ай
эленгән, һаман тора,
балкон тәрәзеннән кереп,
шигыремне яктырта.

Идел суы акчарлакның
каурые кебек якты...
Мин дә, бер иркәләним дип,
шигырь янына яттым.

* * *

Эт уйната берәү кала уртасында —
уяу булсын, усал булсын, тугры булсын!..

Ат уйната берәү дала уртасында —
күндәм булсын, көчле булсын, җитез булсын!..

Этем дә юк, атым да юк... Сүз уйнатам
басып торып дөньяның кыл уртасына.

* * *

Каләм авыр бүген... Бигрәкләр дә авыр...
Карасы да кара түгел — кара сагыш...
Йөрәк даруына диеп сузылдым да,
каләмемә кулым тиде... Алдым ялгыш.
Һәм язамын... Йөрәгемдә кара... рәнҗү...
Хисләремнән кер эзлиләр тырнап-тырнап.
Башымда да гөрселдәшә кара уйлар...
Җитте... Куям... Каләм! Син дә ялгыштырма.

* * *

Уйларымны ихлас килеш
сүзгә саласым килә —
башлап язучы яшь шагыйрь
булып каласым килә.

Илле яшемә җиткәч тә,
алтмышымны үткәч тә,
котылгысыз куркыныч көч
басканда да үкчәгә.

Бу сүзләрем көнгә ярау
булып тоелыр кемгәдер.
Бәлки...
Ләкин көннән өстен
шагыйрь Җирдә меңгә бер!

Башлап язучы яшь шагыйрь
нәкъ менә шул исәптә —
теленә килгәнне әйтеп,
гасырларны кисәтә...

## *Истәлекләр иләп кенә*

Истәлекләр иләп кенә дә мин
гомеремнең соңгы көненәчә
берөзлексез шигырь яза алам,
ләкин күңел — кымыз эчкән чичән —
яңа суык эзли, яңа җылы,
яңа үрләр эзли, яңа үзән...
Яңа чатыр кора алам әле,
учак яга алам әле — сизәм.
Яңа хисләр кирәк, яңа тойгы,
хәтта яңа курку алсын котны...
Тугарылып бер яшисе килә,
гел җигүле килеш бик арытты.
Истәлекләр иләп кенә булмый...
Күздән тамган яңа тамчыларга
каләмеңне манып язарга да,
язганыңны укып бер еларга...

## *Шигырьләрне байрак итеп...*

Шигырьләрне байрак итеп
күтәрәсе килгәндә,
күз алдына сез басасыз,
Ватанны сөйгән шагыйрьләр!
Сүзгә хәнҗәр үткерлеге
иңдерәсе килгәндә,
сезнең җырлар искә төшә,
дошманга үчле шагыйрьләр!
Хисләргә Җир җылылыгы
сеңдерәсе килгәндә,
сезнең күңел күздән кичә,
халыкны белгән шагыйрьләр!
Иманда калкан ныклыгы
булдырасы килгәндә,
сезнең йөрәк үрнәк була
безгә, коммунист шагыйрьләр!
Шатлыкка җилләр канаты
бирергә теләгәндә,
сезнең канатлы куаныч,
безгә өлге, шагыйрьләр!
Шигырьләрне байрак итеп
күтәрәсе килгәндә,
без сезнең сафка басабыз,
Җәлилләр һәм Кәримнәр!

* * *

Сүрән көн дә якты була
син елмайганда.
Салкын көн дә җылы була
син куанганда.

Чәчрәтеп көлеп җибәр бер —
җил алыр отып.
Ул болытларга кагылыр —
җылыныр болыт.

Түгелер ул язгы җиргә —
шытарлар гөлләр,
купшыланып, юмартланып
китәр күңелләр.

Яңа җыр туар дөньяда —
якты, җылы җыр.
Гомер буе шул җыр безне
назлар, җылытыр.

* * *

Әй хатын-кыз! Синең тылсымыңнан
исермәгән җирдә кем генә?!
Барыбыз да шулай айнымыйча
килеп җитә ахыр көненә.

Барыбыз да: «Учларымда гына
йөртәм сине», — диеп алдыйбыз.
Һәм шунда ук сиңа таянмыйча
яшәп булмаслыгын аңлыйбыз.

Белмим, нинди җаннар затысындыр —
син борынгы һәрчак, син — яңа.
Күзләреңнән кайсы яшеңдә дә
дәрт нурлары ага дөньяга.

Җирдә хатын-кызсыз иң илаһи
ләззәт юклыгын син беләсең...
Тик онытма: бездә, ир-атларда,
җәннәт капкасының ачкычы. 

Әй хатын-кыз! Сине шәраб итәм,
сине сулыш итәм, чор итәм!
Син беркайчан җырлап бетермәслек,
туйдырмаслык гүзәл җыр икән!

## *Кеше кайчан ямьсез?*

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Күз яшереп сөйләшкәндә,
алдын-артын карамыйча,
потлап вәгъдә өләшкәндә;
көнләшкәндә, башын җуеп,
үз-үзенең шәүләсеннән —
шәүләсе озын булганга
аның карсак гәүдәсеннән.

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Рәхмәт әйтә белмәгәндә;
синең йөрәк гозереңне
колагына элмәгәндә;
көлмәгәндә кеше белән
халык күңел ачкан чакта,
кара гына эзләгәндә
күз яшеннән калган тапта.

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Сабыйларга акырганда,
ата-анасын, дусларын
бусагасыннан борганда;
торганда сынын катырып
сырты чыккан карт алдында,
күзенең нуры сынганда
йөрәгендәге салкыннан.

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Хак булса да мактанганда —
буш куыклар күктә шартлап,
төкерек булып тамганда;
акланганда шакшы кулын
чит чабуга сөртә-сөртә;
яшәгән чакта күршесен
озын акча белән үртәп.

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Үзенә дан даулаганда,
гөнаһлы ачык кочакны
матур яба алмаганда;
алдаганда яшен-картын,
ант сулары эчә-эчә,
өмет таптауның җинаять
икәнлеген дә белмичә.

— Кеше кайчан ямьсез була?
— Үзен матур санаганда;
уртак табын табагыннан
мулрак калҗа сайлаганда;
бәйләнгәндә юк-бар өчен,
янаганда, кизәнгәндә —
кешелеген югалтуын
күрмәгәндә-сизмәгәндә!..

# *Эчтәлек*

Төзүчедән ... 7

Әлегә хушлашмыйбыз... ... 10
Алтын төрән ... 11
Даһи хис ... 12
« Һәрбер кеше — Җир-тәгәрмәчнең бер теше...» ... 13
Бар тырышканым ... 14
Renatus ... 15
«Кайчандыр Ай...» ... 16
«Кан тамырындагы тынлык...» ... 17
Хәбәр ... 18
Анда, космонавтлар янында ... 19
«Күңел минем ничек тыныч булсын?» ... 20
Тырышты Җир ... 21
Гасыр яшьтәшләре сөйләшә ... 22
Бала турындагы уйлар ... 23
Казанның кызыл түбәсе ... 24
« Һәр халыкның үткәнендә...» ... 25
Бәхет Аем ... 26
Италия дәфтәре *(Цикл)* ... 27
«Агачларда еллар сыры...» ... 33
«Кабат каләмемә үсә яңа канат...» ... 34
Юл читендәге үлән ... 35
Коктебель ... 36
Җен бармагы ... 37
Алтын капка ... 38
Шторм ... 39
Давылдан соң ... 40
«Дулкынга аркаңны бирмә...» ... 41
«Акчарлаклар, мине күргәч...» ... 42
«Кораблар диңгезгә китә...» ... 43
«Кояш баеганда җил туа...» ... 44
Юл да юл ... 45
Йөрәк белән капшап ... 46
Болыт күләгәсе ... 47
Тәмуг сүнгәч ... 48
«Әйбәт кеше иртә китә...» ... 49
Моң ... 50
«Ничаклы кош!..» ... 51
«— Иртән кем елый?..» ... 52
Хата! ... 53
«Якты аңга да килә кара уй...» ... 54
Дәвам ... 55
Көлкегә калса ... 56
Ага ... 57
«Аһ!..» ... 58
«Оясыннан егылып төшкән кош баласы белән...» ... 59

Ау чоры ........ 60
«Көз керә...» ........ 61
Ашыгып бәхеткә ашкынганда ........ 62
Тыныч көзләр ........ 63
Август ........ 64
Га́града, октябрьдә ........ 65
Коньяктагы курортта ........ 66
Алмагач монологы ........ 67
«Син хаклы, диңгез дулкыны...» ........ 68
«Минут саен гашыйк булып...» ........ 69
Җир һәм Газазил ........ 70
Полигон ........ 71
Үтерергә өйрәнәләр ........ 72
Бокс ........ 73
Кара таракан ........ 74
Күгәрченгә бәрелеп ........ 75
Замана яктысы ........ 76
«Барысы алдан билгеле...» ........ 77
«Мин хуҗасы да Җирнең, колы да — кулымда...» ........ 78
Мин ул ........ 79
Янган йөрәк ........ 80
Сурәтләшүләр ........ 81
«Көймәмә әле Заманның...» ........ 82
Бирмә ........ 83
Тынычлык таләп итәм ........ 84
Ныклык бар! ........ 86
Рәмел тактасы ........ 87
Яралар *(Цикл)* ........ 88
Баскычлар ........ 97
«Җанлының да, җансызның да...» ........ 98
«— Шагыйрьләр...» ........ 99
Җай таба ........ 100
Тарихи тамаша ........ 101
«Галилей хаклы булганда...» ........ 102
Чөйсәләр... ........ 103
Йомшак бәгырьлеләр ........ 104
Менә шулай ........ 105
Шипка монастыренда ........ 106
Пумала ........ 107
«Гаҗәп!..» ........ 108
«Аткан таң алга дәшә...» ........ 109
«Аптырагач...» ........ 110
Оялар ........ 111
«Бер дусымны уң җилкәмә күтәрдем...» ........ 112
Алтын сүз ........ 113
«Чигәдәге һәр чал чәчне саный китсәң...» ........ 114
Бозлавыклар ........ 115
Ике гөл ........ 116
Исле гөл ........ 117
Сагындырган ........ 118

«Күргән күпме ак болытның...» ... 120
«Ләйсән яңгыр быел төнлә яуды...» ... 121
«Утыз ел авызлык тешләгәннән соң...» ... 122
Кайсына тиң? ... 123
Иң көчле кул ... 124
Йодрык һәм бармак ... 125
«Яшел яфракларны кар каплады...» ... 126
Арагызда ... 127
«Күк моңайса...» ... 128
Ул көн уза ... 129
«Беркайчан да сезгә күрсәтмәмен аны...» ... 130
Төн ... 131
Сүнмәгән ут ... 132
Кесә көзгесе ... 133
Кызыл маяк ... 135
Көндезге Ай ... 136
«Бер-беребезгә шундый якын идек...» ... 137
«Очрашканнар...» ... 138
«Вәгазь укырмын дип куркам...» ... 139
Таң алды ... 140
Бер дә юшкынсыз ... 141
Бизәк *(Цикл)* ... 142
Кыр уртасы ... 148
Әгәр шатлык җитешмәсә... ... 149
«Башны учка куйдырырлык гаҗәеп бер заман бу...» ... 150
«Кояш тыныч кына чыга...» ... 151
Әйләнеш ... 152
Даимилек ... 153
«Мин Җир буйлап сәяхәттә...» ... 154
«Яшен яшьнәп, күкләр күкрәп яуды кар...» ... 155
«Бу тойгыдан да ләззәтлерәк ниндие бар?» ... 156
Кышкы болыт ... 157
Кочак тулы чәчәк ... 158
Ике тамчы ... 159
Хат көткәндә ... 160
«Рәнҗетелгәннәр ярсымый...» ... 161
Ияр һәм тәхет ... 162
«Башлаган эш — беткән эш дип...» ... 163
«Балыксыз күлдә...» ... 164
«Өйгә җил генә кертсә дә тәрәзә...» ... 165
Әбиләребезнең берсе ... 166
«Дым әйткән, ди, улына...» ... 167
«Бөтен нәрсә — гади...» ... 168
Озатканда ... 169
Казанда яз ... 170
Сезнең исем ... 171
Өч тәрәз ... 172
«Күңелемдә кайчак гаҗәеп сурәт була...» ... 173
Куера бара ... 174
Җыр ... 175

Карга бураны ..... 176
« Һәр көзнең моңы бар, көе бар...» ..... 177
Кычыткан ..... 178
Күздән яшь сикканнан соң... ..... 179
«Еллар узган саен...» ..... 180
«Үпкәлим дә юлга җыенам...» ..... 181
«Аякны гына...» ..... 182
Зөя яры ..... 182
«Артка карап алга кача...» ..... 183
«Син ничек яшисең?..» ..... 184
Киткәннән соң... ..... 185
«Бураннарга каршы басып тора...» ..... 186
Кем алданрак! ..... 187
Вакыт ага ..... 188
Көзге ..... 189
Кайтавазлар кайта ..... 190
«Озындырмы, кыскадырмы үткән юлым...» ..... 191
Көз килү ..... 192
«Мин балконга чыгам да...» ..... 193
«Юл тузанында...» ..... 194
«Ир уртасы кешеләргә...» ..... 195
Шавы миндә үлмәс кайтаваздай ..... 196
«Төссез уйны — күккә атам...» ..... 197
Әйт син, баш! ..... 198
«Нигә син, яңгыр, күзләремә качтың...» ..... 199
«Бар ваклыклар калды Иделдә...» ..... 200
«Кара гына урман...» ..... 201
«Күптән түгел тып-тын иде...» ..... 202
Конфет, алма, чәчәк ..... 203
«Суыгызны беләм...» ..... 205
Акчарлаклар ..... 206
Балыкта ..... 207
«Диңгез — ярсыган ат кебек...» ..... 208
«Егет диңгездән йөгереп чыкты...» ..... 209
Вакытсыз яңгыр турында хәбәр ..... 210
«Якты дөньяга чыктык без...» ..... 211
Тормыш ..... 212
Килешми, ярамый ..... 213
«Көзнең яфраклары сукмакларда...» ..... 214
«Кырык вагон урман үтеп китте...» ..... 215
«Беребез-бер Айга аяк басмадык...» ..... 216
«Кемдер теләктәшлек көтә...» ..... 217
Диңгез, урман, шагыйрь ..... 218
«Тигез юлда син бер сикәлтәме?..» ..... 219
«Кар иде бугай...» ..... 220
Салыйм әле балдагымны... ..... 221
«Син — иң куркыныч табышым...» ..... 222
«Ләйсән генәдер бу дигән идем...» ..... 223
«Озак нидер сөйләштеләр...» ..... 224
Шәһәрара телефон станциясендә ..... 225

Бүгеннән ........ 226
«Дантега ияреп...» ........ 227
Сөяргә икән... ........ 228
«Син, гүзәл тылсымчы сыман...» ........ 229
«Син бит минем күзләремдә...» ........ 230
«Җәеп сал чәчеңне...» ........ 231
Кыргый кыз ........ 232
Күмер тагын яна ала... ........ 233
Китми ........ 234
«Яфраксыз урманда...» ........ 235
Таныш җылы ........ 236
Ян, дисең син... ........ 237
Сагынуның чиксез чагы... ........ 238
«Аягүрә басып арбага...» ........ 239
Буйсынам ........ 240
Мәхәббәт авырлыгы ........ 241
«Кабат гашыйк булырмын дип куркам...» ........ 242
«Мине мең тарафка тарткан...» ........ 243
«Алмагачлары — алмалы...» ........ 244
Көзге сүрән мәхәббәт ........ 245
Карасам күккә ........ 246
Үкенү җыры ........ 248
Чибәр күргәч ........ 249
Фәкать шулай ........ 250
Менә кайдан ........ 251
Карт җырчы ........ 252
«Китте...» ........ 253
«Китте бу яз...» ........ 254
«Син, мин, Идел...» ........ 255
Дулкын керсен... ........ 256
«Үпкәләттем, ахры...» ........ 257
«Кара миңа, буран булып...» ........ 258
«Зәңгәр күк, иркәм...» ........ 259
«Сине сагынган чагында...» ........ 260
«Сөйгән ярларга тугрылык...» ........ 261
«Хатын-кызның юлын кисмә...» ........ 262
«Һәр нәрсәнең сере — беркайчан да...» ........ 263
«Һәрбер агач, һәрбер үлән...» ........ 263
«Алмагачлар картаялар...» ........ 264
«Уйларның авырлыгыннан...» ........ 264
«Изге һәр эш ак уйлардан...» ........ 265
«Кемдер сата...» ........ 265
Лирик сәүдәгәр ........ 266
Дару исе сеңгән шигырьләр *(Цикл)* ........ 267
«Җай гына башланган һәр эш...» ........ 271
«Таш туңа да, чылана да...» ........ 271
Үземә үзем сыеп... ........ 272
«Үз төшемә уянамын...» ........ 273
«Яфракларын өзмә көзнең...» ........ 274
Самолетта Бишкәккә ........ 275

«Кайбер уйлар кысыр болыт кебек...» ..... 276
Абу-Дабида ..... 277
Капитолий үрләрендә ..... 278
Женевада ..... 279
Кояшчыклар ..... 280
«Томаннар аша узган бар...» ..... 281
«Инде күптән яңгыр тамчыларын...» ..... 282
Менә мин кем!.. ..... 283
Керсезлек ..... 283
Татарстан хатыннары ..... 284
«Үз томнарын үзе акча түләп...» ..... 285
«Танымагыз... Санламагыз... Кирәкми!..» ..... 285
«— Заман җиле уй-фикерне...» ..... 286
Мәйданнарда ..... 287
«Мин яхшы, башкалар начар...» ..... 288
Таллинда ..... 289
Нашатырь ..... 290
Байкалда ..... 291
Күз ..... 292
Җәяү ..... 293
Төшкәндә ..... 294
Ошаса! ..... 295
«Кешене мәшәкать йөртә...» ..... 296
Грозный, 1998 ел ..... 297
Илбасар кабере ..... 298
«Тукай туган көнне һәр ел кояш...» ..... 299
«Кабат килде март ае...» ..... 299
Яз исе ..... 300
«Ачу-үч өермәсенә...» ..... 301
Сайлау ..... 302
Аңладым ..... 303
Эзләдем балын, тозын ..... 304
Ике сайлау арасында ..... 305
Нәрсә әйтим? ..... 306
Шушы шатлык ..... 307
Син ..... 308
«Ел фасылы түгел лә мин...» ..... 309
«Мин сиңа болыт юлладым...» ..... 310
«Ә син мине урламадың...» ..... 311
Олы юлның тузаны ..... 312
Почта ящигы ..... 313
«Мәхәббәтемнең канаты шулчаклы киң...» ..... 314
«Бөртек-бөртек...» ..... 315
«Ялгызым йөрдем мин урамда...» ..... 316
«Күзләреңнән күземә...» ..... 317
«Күңелсездер сиңа минем белән...» ..... 318
«Мунчаларга да яшермә...» ..... 319
Китә аламы? ..... 320
Шуны онытма ..... 321
Керү хакы ..... 322

Тораташка әйләндерде ... 323
«Күз нуры да кайвакытта...» ... 324
«Билгәнсең эчем-тышымны син...» ... 325
Елның изге мизгеле ... 326
«Ә бүген мин төне буе...» ... 327
«Болытлы көн нигә якты әле?..» ... 328
«Муеныңа салдым авыр чылбыр...» ... 329
«Язның беренче көнен...» ... 330
«Эзсез дә табам ич мин сине...» ... 331
«Минем хатлар самолетта бара...» ... 332
Өч канатлы кош ... 333
«Минем көнем синдә яши бугай...» ... 334
Син каргама мине ... 335
«Җилкәннәрдә әле язлар җиле...» ... 336
Янә ярлыкарга ... 337
«Арыдыңмы җилгә каршы очып?..» ... 338
Ай — гашыйклар кояшы ... 339
«Җылыта Кояш...» ... 340
Кояш нуры ни бәя? ... 341
Без бер елга ... 342
Үзгәрешләр ... 343
Кулың һаман кайнар ... 344
Көнләшү галәмәте ... 345
Батырай көйләренә *(Цикл)* ... 347
Яшьлегемнең моңлы өч хикәяте ... 356
Көтелмәгән көн *(Цикл)* ... 363
Каурый каләм *(Цикл)* ... 369
«Мин бәхетемә ышанам...» ... 384
Шатлыгым күп ... 385
Илнең җылы сүзе ... 386
Бодай кырлары өстендә ... 387
Колхоз председателе ... 388
Игенче бәхете ... 389
Казан урамнары ... 390
Чуваш җыры ... 391
Буа ягым — тау ягым ... 392
Түзеп булмаслык юксыну ... 393
«Керфектән тотып диңгездән...» ... 394
Картлар ансамбле ... 395
«Ак болытлар аръягында...» ... 396
Һаман арта ... 397
«Сизмичә дә җыр башлыйм...» ... 398
«Кем язса да — туган телен...» ... 399
Поэзия ... 400
Шул дым ... 401
«Тукай таптап тузан иткән ташлар...» ... 402
Тукай соравы ... 403
Җырлар яна ... 404
Тамгалы атом ... 405
Үз дулкынымны көтәм ... 406

«Бакча бакча булсын өчен нәрсә кирәк?..» ... 407
Яшәү гармониясе ... 408
«Күрде ул көткән штормын...» ... 409
Анда, таулар арасында ... 410
Хәтер көне ... 411
Ак сөлге ... 412
Ә Казаным белә сугышны ... 414
Бабам сүзе ... 415
Татарстан әләме ... 416
Сәйях ... 417
Җил ... 418
Киев. 1986 ел. Җәй ... 419
«Дмитрий Донской» теплоходында ... 420
Төрки телләр ... 421
Татар иле ... 422
Татар бәйрәме ... 424
Белем йортым ... 426
«Әкрен генә барам Казан урамнары буйлап...» ... 427
Кунакка чакыру ... 428
Империя таркалганда ... 429
Ачыш ... 430
«Дәүләтләрдә халыклары холкы...» ... 431
Табын ... 432
Саратов татарлары җыры ... 433
«Зәһәрләнеп исә бозлы җил...» ... 434
«... Һәм без гомер сөрәбез...» ... 435
«Безнең барлык кылганнарны...» ... 436
«Үле мәче, сынык байрак...» ... 437
Кәрван ... 438
Гаеп кояшта... ... 439
Берсенә дә... ... 439
Әй замана... ... 440
Минутлык төшенкелек ... 441
«Ничаклы каршылык яши...» ... 442
«Югарыга үрләгәндә...» ... 443
«Шигырьләрдә минем тимер, бетон...» ... 443
Китмибез! ... 444
Кан һәм каләм ... 446
«Идел өстендә көмеш Ай...» ... 447
«Эт уйната берәү кала уртасында...» ... 448
«Каләм авыр бүген...» ... 448
«Уйларымны ихлас килеш...» ... 449
Истәлекләр иләп кенә ... 450
Шигырьләрне байрак итеп... ... 451
«Сүрән көн дә якты була...» ... 452
«Әй хатын-кыз! Синең тылсымыңнан...» ... 453
Кеше кайчан ямьсез? ... 454

Литературно-художественное издание

***Харисов*** *Ренат Магсумович*
*(Ренат Харис)*

Избранные произведения

В семи томах

Том 2

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Харисов*** *Ренат Мәгъсумович*
*(Ренат Харис)*

Сайланма әсәрләр

Җиде томда

2 том

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Ф.Ш.Хасьянова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.Г.Зиннәтуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.03.2006. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Arial» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 24,36 + вкл. 0,84.
Шартлы буяу-оттиск 25,31. Нәшер-хисап табагы 12,94 + вкл.0,89 .
Тиражы 3000 д. Заказ 3-60.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru, e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.